Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты
Институт истории имени Ш.Марджани Академии наук Республики Татарстан
Sh.Marjani Institute of History of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan

# ТАТАР ХАЛКЫ ТАРИХЫ ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕ: УРТА ГАСЫРЛАР

## (фәнни-популяр басма)



Казан – 2014

УДК 93/94
ББК 63.3(2Рос=Тат)
Т 23

**Авторлары:**
*Хуҗин Ф.Ш.*, тарих фәннәре докторы; *Гибатдинов М.М.*, педагогика фәннәре кандидаты; *Рәхимҗанов Б.Р.*, тарих фәннәре кандидаты; *Мөхәмәтдинов Р.Ф.*, тарих фәннәре кандидаты; *Халитов Н.Х.*, архитектура докторы; *Миргалиев И.М.*, тарих фәннәре кандидаты; *Гыймазова Р.А.*, тарих фәннәре кандидаты; *Макаров Г.М.*, сәнгать фәннәре кандидаты; *Биктимирова Т.Ә.*, тарих фәннәре кандидаты; *Миңнуллин Ф.Г.*, филология фәннәре кандидаты; *Мөхәммәтҗанова Д.С.*; *Зиннәтуллина А.Ә.*

**Фәнни редакторы:**
*Рафаил Сибгат улы Хәкимов*,
тарих фәннәре докторы, ТР ФА академигы

**Төзүчеләре:**
*Гибатдинов М.М., Мортазина Л.Р.*

**Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте: урта гасырлар (фәнни-популяр басма).** – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2014. – 196 б.

Китапта заманча фәнни эзләнүләр һәм күпсанлы чыганаклар нигезендә татар халкының мөстәкыйль дәүләтләр булып яшәгән чоры тасвирлана. Халкыбызның рухи һәм матди мәдәнияте үсеше, мәдәниятара багланышлар сурәтләнә.

Китап киң катлам укучыларга адреслана.

ISBN

© Авторлар коллективы, 2014
© ТР ФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2014

# КЕРЕШ

Соңгы елларда милли үзаңыбыз үсү халкыбызның үткәне, данлы тарихы, күп гасырларга сузылган олы юл узып бүгенге көннәргә килеп җиткән рухи һәм мәдәни кыйммәтләре белән кызыксынуны тагын да арттырды. Борынгы бабаларыбызның яшәеше һәм көнкүреше, башка милләтләр белән бәйләнешләре, мәдәнияте, тәрбиягә, дингә карашлары, бай рухи дөньясы тарихка турыдан-туры бәйләнеше булмаган кешеләрнең дә игътибарын җәлеп итә. Чөнки, бабаларыбыз әйтмешли, «Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк». Күпгасырлык рухи һәм матди мирасыбызны барлау, аны яңача аңларга тырышу күп кенә тарихи ачышларга китерде.

Борынгы төрки халыклар чал тарихта үзләренең мәңге җуелмас шанлы эзләрен калдырганнар. Гаять зур киңлекләрне үз эченә алган Төрки каганлык дигән мәгърур дәүләтләрен булдырганнар, озак еллар буена Азия һәм Европа континентларын бер итеп яшәгәннәр. Шуңа да Азия һәм Европа тарихларын төрки-татар тарихыннан аерып алып булмый. Бу бергәлек халыкларның яшәү рәвешләрендә дә, үзара мөнәсәбәтләрендә дә чагылыш тапкан.

Бүгенге Россиядә дә төрле милләт һәм дин вәкилләре үзара тату яши. Бу дуслыкның беренче адымнары әнә шул заманнарда ук салынган. Төрки каганлык, Бөек Болгар илендә урнашкан мәдәни бәйләнешләр вакытлар узу белән тагын да ныгыган, баеган. Бүгенге четерекле заманда да шушы мирасыбызны югалтмыйча, киләчәк буыннарга илтеп җиткерәсе иде. Алар да, бабаларыбыз кебек, күпмилләтле даирәдә яшәп, үзенең милләте, аның үткәне белән кызыксынып, киләчәге өчен җан атып, «Мин – татар баласы!» дип горурланырлык булсын! Бу басма шул юлда бер ярдәмче булыр дип ышанабыз.

Тарих һәм мәдәният мәсьәләләрен бер яссылыкта, үзара бәйләнештә яктыртуны төп максат итеп алган әлеге китапта халкыбыз тарихының данлы сәхифәләре – Азиядә һәм Европада һуннар (гуннар), Төрки каганлык, Идел-Чулман Болгары, Алтын Урда дәүләте, татар ханлыклары чорларына хас булган үзенчәлекләр, халыкның яшәеше, тормыш-көнкүреше белән беррәттән, дине, мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате, музыка үсеше, архитектурасы, милли ризык, кием тарихы, тарихыбызда мәңге югалмас эзләрен калдырган мәртәбәле хатын-кызларыбыз эшчәнлеге тасвирлана.

Басма татар тарихы белән кызыксынучы киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

# АЗИЯ һӘМ ЕВРОПАДА һУННАР (ГУННАР)

**һуннар дәүләте.** Безнең эрага кадәр беренче меңьеллыкта Урта Азиядә бер-берсенә якын телләрдә сөйләшкән *төрки телле кабиләләр* халык булып формалаша. Кытайлар аларны хунну яисә сюнну дип атыйлар. Төрки телле кабиләләрнең киләчәк буыннары булып татарлар, чуашлар, башкортлар һәм Россиянең башка күп кенә халыклары тора.

һуннарның күпчелеге терлекчелек, калган өлеше игенчелек белән шөгыльләнә. Терлекчеләр, ат һәм сарык көтүләре тотып, күчмә, ә игенчеләр исә утрак тормыш алып баралар.

Безнең эрага кадәр өченче гасыр ахырында һуннарның үз дәүләте барлыкка килә. Дәүләтнең хакиме (*Шаньюй*) булып көчле армия төзегән кырыс һәм хәйләкәр Маодунь тора. Аның кул астында дистәләрчә мең җайдакчылар хезмәт итә. Бер генә һун да, үлем җәзасыннан куркып, хәрби бурычларын үтәүдән баш тарта алмый. һуннарның атлы гаскәрләре сугышта дошманнары өстенә ук ташкыны яудыра. Җанга үтәрлек сызгыра торган уклар дошманнар арасында каушау һәм курку тудыра.



*һун җайдагы. Борынгы кытай рәсеме.*



*Коеп ясалган хәрби баш киеме.*

Сугышчан дәүләт үзенең чикләрен киңәйтә. Төрле рудаларга бай Байкал буе һәм Алтай алды таулыкларын кулга төшерү һуннар өчен әһәмиятле табыш була. Бу җирләрдә һуннар тимер ятмаларын эшкәртә башлыйлар. Биредә тимерчеләр, металл коючылар, хәрби корал ясаучылар бистәләре барлыкка килә. Соңыннан һун шәһәрләре һәм ныгытмалары, игенчеләр биләмәләре калкып чыга.

һуннарның зур шәһәрләрендә гыйбадәтханәләр, сарай-резиденцияләр, башка төрле җәмәгать биналары була. Күп кенә торак биналары төтен чыгару каналлары аша ягып җылытыла. Биредә яшәүче һөнәрчеләр гаҗәеп зур осталык белән тимердән, чуеннан, бронза һәм сөяктән төрле-төрле әйберләр ясыйлар.

Һуннарның иң куркыныч дошманы булып Кытай тора. Җиңүгә йә бу, йә теге як ирешкәли. Кытайларның һуннарга ясак түләгән чаклары, шулай ук һуннарның да Кытай кул астында калган вакытлары була.

**Азиядән – Европага.** Ниһаять, кытайлар аларга җимергеч һөҗүм ясыйлар. Безнең эраның I гасырында һуннарның бер өлеше Көнбатышка китә, аларны *гуннар* дип атыйлар. Аларга буйсындырылып яисә ирекле рәвештә башка күчмә һәм ярымкүчмә кабиләләр кушыла.

375 елда гуннар Идел һәм Дон аша кичеп чыгалар. Аннан аларның юллары Көнбатыш Европага юнәлә. Биредә гуннар күп илләргә походлар ясаган көчле кабиләләр берләшмәсенең башында торалар. Аттила юлбашчылык иткәндә, гуннар иң зур куәткә ирешәләр. Ләкин 453 елда ул үлгәч, гуннар арасында каршылыклар килеп чыга һәм аларның берләшмәсе таркала.

Азиядән Европага күчә бару юлында гуннар бик күп кабиләләрне яшәгән җирләреннән куып чыгаралар. Халыкларның Бөек күчешенә этәргеч ясала. Бу гомуми ташкынга татар халкының ерак бабалары – *болгарлар* һәм *суарлар* да эләгә.

Гуннар белән бергә хәрәкәт иткән кабиләләрнең бер өлеше безнең җирләрдә төпләнеп калалар. Алар арасында гуннар үзләре дә була. Татарстанның Аксубай районы Татар Сөнчәләе авылы янында археологлар ике тоткалы зур бронза казаннар, үтә матур бизәнү әйберләре табалар. Тикшеренүләр бу казаннарның гуннарныкы булуын күрсәтә.

**Гуннар татарларның турыдан-туры бабалары түгелләр. Әмма аларның Көнбатышка күчешләре Урта Идел буе һәм аның халыклары тарихында үзләренең шанлы эзен калдыра.**





*Гуннарның бронза казаннары.*

## Ашын нәселенең килеп чыгышы (миф)

Һуннар йортыннан булган Ашын нәселе Көнбатыш диңгезе (Каспий, Азов) буенда барган яу вакытында җиңелә һәм тулысынча тар-мар ителә. Дошманнар бердәнбер исән калган ун яшьлек малайның аяк-кулын чабып өзәләр һәм бер күзен чыгарып, сазлыкка ташлыйлар. Үлемгә дучар ителгән бу баланы ана бүре табып ала һәм тәрбияләп үстерә. Тагын ун ел узгач, дошманнар белән сугыш вакытында бу егет тә һәлак була. Ә ана бүре таулар белән әйләндереп алынган далага кереп яшеренә һәм шунда дөньяга ун ир бала китерә. Әнә шул балалар ун төрки кабиләгә нигез салганнар да инде.

## ТӨРКИ КАГАНЛЫК

VI гасырда Көньяк Алтайда «түрек», «төркәтләр» («төрки йорт») исемнәре астында зур булмаган халык төркеме пәйда була. Алар үзләрен һуннар токымнары дип саныйлар.

Башта төркиләр, Алтай алды таулыкларында тимер табу һәм эретү белән шөгыльләнеп, утрак тормыш алып баралар. Шул ук вакытта алар монгол телле жужаннарга (хәзерге монгол теленә якын телдә сөйләшүче күчмә кабиләләр) буйсыналар. *Бумын каган* идарә





*Билге каган таҗы.*

*Бумын каган. Кытай рәсеме. VI гасыр.*

*Көбәле төрки сугышчылар. Реконструкция.*



иткәндә, төркиләр көчәеп китәләр һәм жужаннар белән исәпләшми башлыйлар. 551 елда Бумын жужаннарның төп көчләрен тар-мар итә, үзенә борынгы төрки халыкларның дәүләт башлыгы дәрәҗәсен – ил-каган титулын ала. Яңа дәүләт – *Төрки каганлык* барлыкка килә.

Бумын каган токымнары төрки биләмәләрне киңәйтәләр. Өзлексез сугышлар алып бара-бара, күрше кабиләләрне кысрыклыйлар, аларның байлыкларын тартып алалар. Әсирләр исәбенә гаскәрләре тулылана. Берара Кытай императоры да каганлыкка салым түли. Халыклардан ясак җыеп, төркиләр күп җирләрдә үз хакимлекләрен ныгыталар.

Каганлыкка нигез салынуга егерме ел да узмый, аның биләмәләре Төньяк Кытайдан алып Кара диңгез буйларына кадәр сузыла. Төрле телдә сөйләшүче кабиләләр яшәгән әлеге зур җир мәйданнарын бергә туплап идарә итү җиңел булмый. 588 елда дәүләт икегә – Көнбатыш һәм Көнчыгыш каганлыкларга таркала. Тагын йөз елдан алар үзләре дә таркалуга дучар булалар. Ярты гасыр узгач, Көнчыгыш Төрки каганлык кабат торгызыла.

Төрки каганлыкның тарихы сугышлардан гына тормый. Үзләренең биләмәләрендә төркиләр сәүдә үсешенә йогынты ясыйлар. Алар беренчеләрдән булып язуга нигезләнгән мәдәният булдыралар. Рун язмаларының гаять күркәм үрнәкләре төрки гаскәр башлыклары Күлтәгин, Төньюкук һәм Билге каганнарга куелган кабер ташларындагы язмалар төсендә сакланып калган. Бу язуларда идарәчеләр һәм гаскәр башлыкларының тормышлары һәм батырлыклары хакында әйтелгән.

Төрки каганлыкта шәһәр төзелеше, архитектура һәм сәнгать төрләре тагын да ныграк үсеш ала. Тарихи чыганаклардан төркиләрнең юллар һәм почта станцияләре төзү белән шөгыльләнүләре билгеле.

Төрки каганлык Урта Азия һәм Европа халыклары тарихында әһәмиятле роль уйный. Каганлык җирлегендә хәзерге төрки халыкларның нигезләре салына.

**Кимәк каганлыгы.** Кимәк каганлыгы – 657 елда Төрки каганлык таркалганнан соң, кимәк кабиләләреннән оешкан борынгы төрки дәүләт. 840 елда Уйгур каганаты таркалганнан соң, әлеге дәүләтнең кайбер кабиләләре (эймур, баяндур, татар) шулай ук кимәк берләшмәсенә кушыла. VIII–IX гасырларда кимәк кабиләләре Урта Иртыштан алып Җоңгарга кадәр булган киң территориядә җәелеп, көнбатышта Көньяк Урал һәм Сырдәрья елгасына хәтле барып җитәләр. Бу чор кимәкләрнең дәүләтчелеге зур үсеш кичергән дәвер булып санала.

Кимәк хакименең йогынтысы бик зур була. IX гасыр ахыры – X гасыр башларыннан ул төрки ханнарының иң югары титулын – каган исемен йөртә башлый. Каганның идарәсе Кимәкия (Имекия) шәһәрендә урнашып, тимер капкалы ныклы диварлар белән әйләндерелеп алынган була. Биредә аның күпсанлы гаскәре һәм казнасы туплана.

Кимәк каганлыгы берничә өлкәгә бүленгән, һәрберсенең башында идарәче торган. Өлкә башлыклары кимәк каганына буйсынган булсалар да, тора-бара мөстәкыйльлеккә ирешеп, дәүләтнең югары хакимиятен яулап алырга омтылганнар. Аларның яшәү урыннары диварлар белән әйләндерелеп алынган шәһәрләр, югарылыкта урнашкан ныгытмалар булган.

Кимәкләрнең төп һөнәрләре терлекчелек булган. Алар ат, сарык, кәҗә, сыер, үгез һәм дөя асраганнар. Хуҗалыкта төп урынны сарык һәм ат үрчетү алып торган. Атларның елгырлыгы һәм чыдамлыгы зур мәйданлы җирләрне үзләштерергә мөмкинлек биргән. Атлар җирле табигать шартларына һәм ел әйләнәсендә көтүлек җирләрендә яшәүгә яхшы яраклашкан, халыкны сөт һәм ит белән тәэмин иткән. Сугыш һәм ау вакытларында да атлар файдаланылган.

Утрак тормышлы кабиләләр игенчелек белән шөгыльләнгән. Уңдырышлы җирләрдә бодай һәм арпа чәчкәннәр, сугарыла торган басуларда дөге үстергәннәр.

Зур үсеш алган кәсепләрнең берсе булып терлекчелек продукциясен эшкәртү саналган. Тиредән төрле аяк киемнәре, савыт-саба, ук кынылары, ат дирбиясе, капчыклар ясаганнар; киездән кием теккәннәр, тирмәләрне каплаганнар. Кием тегүдә шулай ук кыргый хайван һәм кыйммәтле мехлы җәнлек тиреләре кулланылган. Кимәкләр арасында балчыктан әйбер ясау да киң таралыш алган. Моннан тыш алар тимер, көмеш, алтын, бакыр һәм кыйммәтле ташлар табу белән шөгыльләнгәннәр, алтын һәм көмештән зиннәтле бизәнү әйберләре ясаганнар.

IX–X гасыр башларында кимәклар арасында борынгы төркиләр өчен уртак булган дини ышанулар киң таралган, шулардан Тәңре һәм ата-баба культлары төп урынны алып торган. Кимәкләрнең кайбер төркемнәре манихейлык динен тоткан. Кимәк элитасы арасында ис-

лам дине дә таралган булуы мөмкин. Кимәкләрнең үз язулары булган, алар борынгы төрки алфавитка нигезләнеп камыш каурыйлар белән язганнар.

X гасыр ахыры – XI гасыр башларында кимәк дәүләте таркала. Төп сәбәп кыпчак ханнарының үз дәүләтчелекләрен төзү омтылышлары аркасында каганның югары хакимияте көчсезләнү белән бәйле була. XI гасырда Үзәк Азиядән күпләп күчмә кабиләләр күченә башлау да дәүләтнең таркалуына этәргеч ясый. Кимәк дәүләтчелегенең варислары кыпчаклар була.

## БӨЕК БОЛГАР ИЛЕ

Гуннарның Көнбатышка күчеш чорында ук Кара диңгез һәм Азов буе далаларына, башка төрки телле кабиләләр белән беррәттән, болгарлар да килә. Соңыннан биредә Төрки каганлык биләмәләре була.

Болгарлар аның составында буйсындырылган хәлдә (вассаллар) булалар. 632 елда *Кубрат хан* җитәкчелегендә алар бәйсезлеккә ирешәләр. Мөстәкыйль Бөек Болгар дәүләте барлыкка килә.

Бөек Болгарның башкаласы Тамань ярымутравындагы өлешчә торгызылган антик шәһәр Фанәгүр (Фанагория) була. Биредә һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре алга китә. Әмма болгарларның төп шөгыле булып күчмә терлекчелек санала.



*«Кубрат хан хәзинәсе»ннән алтын әйберләр.*



*Болгар сугышчысы.*

Бөек Болгар дәүләтенең тарихы кыска була. Кубратның уллары аның «берберегездән ераклашмагыз һәм үзара дус булып, килешеп яшәгез» дигән васыятен бозалар. Аталары үлгәч, алар хакимият өчен көрәш башлыйлар һәм җирләрне үзара бүләләр. Дәүләт таркала.

Болгарларны үзләренә буйсындыру максатыннан, аларны сугышчан күршеләр борчый башлый. Кубратның Аспарух исемле улы үзенең кешеләрен Дунай ярларына алып китәргә мәҗбүр була. Биредә болгарлар, славяннарны буйсындырып, 681 елда яңа дәүләт – Дунай Болгариясен төзиләр.


Болгарларның күпчелек өлеше Кубратның икенче улы Батбай белән бергә үзләренең төп җирләрендә кала. Тиздән алар Кырым ярымутравын, Днепр алды далалары һәм урман яссылыкларын яулап ала. Нәкъ менә бу далаларда, Полтава шәһәре тирәсендәге Перещепино авылы янында алтын һәм көмеш савыт-саба, кыйммәтле корал һәм бизәнү әйберләреннән торган хәзинә табыла. Бу хәзинәне «Кубрат хан хәзинәсе» дип атауның сәбәбе, бәлки, алар арасында Бөек Болгарга нигез салучының исеме уелган кашлы йөзекләрнең табылуындадыр.

**Бөек Болгар – хәзерге татарларның борынгы бабаларыннан берсе булган болгарларның беренче мөстәкыйль дәүләте. Ул озак дәверләр яшәми, кирәгенчә ныгып өлгерә алмый һәм шуңа да тарих барышына әллә ни артык йогынты ясамый.**

## ХӘЗӘР КАГАНЛЫГЫ

**Хәзәр иле һәм гарәп яулары.** Болгарларның көнчыгыш күршеләре булып төрки телле хәзәрләр тора. Аларны шулай ук гуннар ташкыны үзенә ияртә, һәм алар Каспий буена, хәзерге Дагыстан

территориясенә килеп утыралар. Хәзәрләр дә төрки каганлыкка буйсынган булалар, ә ул таркалгач, үз дәүләтләрен – Хәзәр каганлыгын төзиләр.




*Хәзәр каганлыгы чоры сугышчылары. Реконструкция.*

Хәзәр каганлыгы үзенең иң югары куәтенә VIII–X гасыр башларында ирешә. Хәтта Византиянең дә хәзәрләргә бүләкләр бирергә һәм алар белән туганлашырга омтылган вакытлары була. Берникадәр вакыт аларга Днепр буе славяннары – поляннар, северяннар, вятичлар, радимичлар – салым түләп торалар. Үзенең чәчәк ату чорында каганлыкның биләмәләре Түбән Иделдән алып северяннар һәм радимичлар җирләренә, Днепрга кадәр сузыла.

VIII гасырның беренче яртысыннан гарәпләрнең яулап алу сугышлары башлана. Аларның юлы Хәзәр каганлыгы аша да уза. Озакка сузылган хәзәр-гарәп сугышлары башлана. 737 елда хәлифә гаскәрләре хәзәрләр җиренә җимергеч һөҗүм ясый. Каганлыкның башкаласы *Сәмәндәр* яулап алына, күп шәһәрләр һәм авыллар яндырыла, талана. Хәзәр илендә ислам дине тарала.

Каган үз гаскәре белән Дон һәм Түбән Идел буйларына юнәлә. Бирегә илнең күпчелек халкы да күченә. Хәзәрләр Бөек Болгар таркалганнан калган болгар җирләрен яулап алалар. Болгарларның бер өлеше, торган җирләрен ташлап, Идел буйлап өскә менә. VIII гасырның урталарында алар хәзерге Татарстан территориясенә килеп җитәләр.

**Итил. Хәзәрләрдә хуҗалык һәм мәдәният үсеше.** Түбән Иделгә күчерелгән хәзәрләрнең башкаласы хәзер инде *Итил* дип атала башлый (бу урыннан ерак түгел хәзерге Әстерхан шәһәре урнашкан).



*Хәзәр ныгытмасы Саркел. В.Флеров һәм О.Федоров реконструкциясе.*

VIII–IX гасырларда Көнчыгыш Европада аңа тиң шәһәрләр булмый. Итил каласы елганың ике яры буйлап берничә километрга сузыла. Җәй көне ул бакчаларга күмелә һәм йөзем җимеше агачларының яшел хәтфәсе белән каплана. Шәһәрдә сарайлар, синагогалар, мәчетләр, чиркәүләр, славяннарның мәҗүси гыйбадәт урыннары (*капищелар*) күп була. Итил халкы, хәзәрләрнең башка биләмәләрендәге кебек үк, төрле диннәр тота һәм төрле кабиләләрдән тора.

Каганлыкның башкаласы һөнәрчелек һәм халыкара сәүдә үзәгенә әйләнә. Товарлар шулкадәр күп була ки, хәтта аларны урнаштыру өчен Итилнең бер өлешен бирәләр. Алар Рус җирләреннән, Болгария һәм Грециядән, Каспий диңгезенең көньяк ярларыннан һәм Кавказдан китерелә. Читтән килгән сәүдәгәрләр, үз товарларын сату өчен, каганлыкның бүтән шәһәрләренә дә барып җитәләр. Сату-алу эшендә акча вазыйфасын хәзәрләрнең металл акчалары – *дирһәмнәр* үти.

Хәзәрләр игенчелек, терлекчелекне яхшы беләләр. Алар тары, арпа, бодай, киндер чәчәләр, яшелчә үстерәләр, йөзем эшкәртәләр. Далаларда һәм болыннарда көр үгез, сыер, сарык, ат көтүләре йөри.

Каганлыкта *рун язуы* киң таралыш ала. Бу язманы Көнчыгыш Европага Төрки каганлык халыклары алып килә. Рун язмалары хәзәрләрнең балчыктан ясалган чүлмәкләрендә, җиз һәм көмеш савытларда, сөяк эшләнмәләрдә сакланып калган. Кызганычка каршы, аларның күбесе әле укылмаган.

X гасыр ахырында Хәзәр каганлыгы яшәүдән туктый. Әмма «хәзәрле» исеме тиз генә юкка чыкмый. Рус чыганакларында бу атама әле өч йөз ел узганнан соң да Мәскәү кенәзләренең төрле хезмәтчеләрен санаганда очрый.

**Хәзәр каганлыгы үзенең чәчәк ату чорында көчле, алга киткән дәүләт була. Евразиянең борынгы төркиләре тарихында ул үзенең эзен калдыра.**

# ТӘҢРЕЧЕЛЕК – БОРЫНГЫ ТӨРКИ БАБАЛАРЫБЫЗ ДИНЕ

X гасыр башларыннан алып бүгенге көнгә кадәр татарлар арасында иң таралган дин булып гарәпләрдән килгән ислам дине санала. Башлангыч чорда төркиләр, табигатьнең илаһи көчләренә ялварып, үзләренә сәламәтлек һәм уңыш кына теләгән булсалар, тора-бара аларның диннәре катлаулыланып, тирәнәеп, дәүләт идеологиясе дәрәҗәсенә күтәрелә. Шул вакытларда күп аллалыкка нигезләнгән мәҗүсилектән бер аллалык, ягъни тәңречелек диненә күчәләр. Тәңречелекнең инану системасы, аның дәүләт хакимияте белән бәйләнешы һәм бу диннең әхлак кагыйдәләренә тукталып үтик.

**Инану системасы.** Борынгы төркиләрнең ышануларынча, илаһи көчләр 17 илаһтан торган һәм алар арасында иң куәтлесе Тәңре дип аталган баш илаһ булган. Башка илаһлар аңа буйсынганнар.

Тәңре Җир йөзен һәм күкне, җирдәге һәм күктәге бөтен нәрсәләрне, Галәмне, яшәешне дөньяга китергән көч булып саналган. Ул – игелек алласы да, кешене яратучы һәм аны яклаучы да. Төркиләр дөньяны түбәндәгечә күз алдына китергәннәр: бөтен дөнья өч өлештән тора. Берсе – җир һәм судан өстә урнашкан «яктылык-игелек» өлеше, ягъни һава, күк, кояш, ай һәм йолдызлар. Икенчесе – җир астындагы «караңгылык-яманлык» өлеше. Өченчесе – әлеге яктылык һәм караңгылык арасындагы җир йөзе һәм су. Дөньяның бу өч өлеше төрле катларга бүленә. Җир асты – җиде, ә җир йөзе белән җир өсте – ун, ягъни барлык Галәм унҗиде каттан гыйбарәт.

Тәңредән тыш тагын: Җир-Су алиһәсе, Умай алиһә һәм Әрлек



*Камның дәрәҗә билгесе булган таяк очындагы бизәк.*



*Борынгы төркиләрнең күчмә киләү урыны (алтарь).*

илаһы, Җир, Су, Ут, Кояш, Ай, Йолдызлар, Һава, Болыт, Җил, Давыл, Күк күкрәү-Яшен, Яңгыр, Салават күпере илаһлары да булган. Илаһлар үз гамәлләрен фәкать Тәңре рөхсәте белән, аның белән киңәшләшеп кенә башкара алган.Тәңре күктә булганга, аны Күк Тәңресе дип атаганнар. Һәр илаһның үз ияләре булган. Мәсәлән, Чишмә иясе, Тау иясе, Йорт иясе һ.б. Ияләрдән түбәнрәк рухәрвахлар урнашкан.

Борынгы төркиләр карашынча, Тәңре кешегә дә, хайванга да охшамаган, аны күреп булмый. Ул – Галәмдәге иң зур рухи көч.

Тәңре Галәмне барлыкка китергәннән соң, иң элек «кеше» дип аталган бер җан иясен яраткан һәм аңа акыл, бәхетле һәм рәхәт яшәргә мөмкинлек биргән. Ләкин ул «кеше» үзенең Тәңре тарафыннан яратылганын, Тәңрегә бурычлы булганын оныткан. Үзен Тәңре белән бертигез куеп, аның көндәше итеп саный башлаган, Тәңрегә каршы баш күтәргән. Шул сәбәпле, Тәңре аңа «Әрлек» дигән исем кушып, золым һәм караңгылык дөньясына – җир астына сөргән. Аннан соң Тәңре яңадан тугыз җан иясен яраткан, тора-бара шулардан төрки һ.б. халыклар барлыкка килгән. Төркиләр үзләрен «Күк яки Тәңре уллары» дип атаганнар.

Кешенең тууына һәм үлүенә төркиләр болай караганнар: иң әүвәл Тәңре күктән җиргә «кот» (яшәү көче) җибәрә, кот баланың төп яшәү көченә әйләнә һәм аңа гомер буе куәт биреп тора. Тәңре котны үзенә кире алу белән, кеше үлә һәм аның коты яңадан күккә кайта. Бу ышануны татар телендәге «Котым очты» дигән гыйбарә дә раслый.

Үз тормышында игелек-яхшылыклар гына кылган, әхлаклы булып яшәгән затларның рухлары, алар үлгәннән соң, күкнең өченче катында урнашкан оҗмахта гомер итәләр дип санаганнар. Җәннәттәге бабаларыбызның рухлары үз нәселләренең киләчәк буыннарына ярдәм итә һәм игелек күрсәтә алалар дип ышанганнар.

Яманлык кылган кешеләрнең рухлары, үзләре үлгәннән соң, Әрлек идарә иткән «караңгылык һәм яманлык» дөньясына җибәрелгән. Әрлек һәм җир асты рухлары «яктылык» дөньясына, җир өстендәге кешеләргә зыян китерергә тырышканнар. Шуңа күрә яктылык-игелек һәм яманлык-караңгылык рухлары арасында кеше күңелен яулар өчен мәңгелек көрәш бара. Кешенең бурычы исә – Тәңре ихтыярын күздә тотып яшәүдән һәм җир асты рухларының тәэсиреннән, аларның явыз котыртуларыннан үз-үзен саклап калу.

Тәңредән соң кодрәте буенча икенче урында торган илаһи көч – Җир-Су алиһәсе. Ул дөньяның урта өлешендә, ягъни җир йөзендә яши. «Җир-Су» сүзенең ике мәгънәсе бар. Берсе – бөек алиһәнең исеме, икенчесе – төркиләрнең туган җире, аларның ватаны. Җир-Су алиһәсе төркиләрнең җирләрен саклый, табигать, җирдәге һәм судагы барлык җан ияләре аның карамагында яши дип саналган. Җир-Су алиһәсе бер үк вакытта уңыш алиһәсе дә булып исәпләнә. Аның хөрмәтенә язын һәм көзен корбан чалганнар. Җир-Су һәм Әрлектән тыш тагын бик әһәмиятле бер алиһә – Умай алиһә бар. Ул күктә яши. Бу игелекле алиһәнең төп вазыйфасы – төркиләргә илаһи көч бирү. Умай – Тәңренең иң яраткан хатыны булып саналган. Умай күктән җиргә таба нурлар җибәрә. Бу нурлар, кеше тәненә үтеп кереп, анда кеше үлгәнчегә кадәр чаткылар булып яналар. Бу чаткылар кешегә яшәү көче, энергия бирә. Умай ул – кешене Галәм белән бәйләп торучы илаһи бер көч. Бу көч кешегә бөек эшләр башкарыр өчен бирелә. Әгәр кешедә бу чаткылар сүнә икән, ул үлә. Умай төркиләрне саклап торучы, аларга сугышларда җиңүгә ирешергә ярдәм итүче алиһә булып та саналган.

Рухларны борынгы төркиләр өч төркемгә бүлгәннәр: игелек, яманлык һәм мәхәббәт рухлары. Алар кош, хайван яисә кеше

*Борынгы ата-бабаларга ихтирам.*





Күлтәгин.



Кам.

сурәтендә булганнар. Тәңрегә мөрәҗәгать итү яисә җир астының яман рухларыннан котылу өчен, кешегә бер арадашчы кирәк булган. Бу арадашчы ролен төркиләрдә «кам» дип аталган махсус рухани үтәгән.

Ә менә Җир-Су алиһәсенә һәр кеше турыдан-туры үзе генә мөрәҗәгать итә алган, чөнки бу алиһә кешегә иң якын торган илаһи бер көч булып саналган. Кешенең көн саен кирәк булган нәрсәләр, ягъни ризык, су, кием һәм йорт кирәк-яраклары белән тәэмин ителүе нәкъ менә шушы Җир-Су алиһәсеннән торган. Шуңа күрә кешеләр аңа бик еш ялварганнар.

**Төрки дәүләтләрдә хакимият һәм тәңречелек.** Төрки дәүләтләрнең башлыклары «каган» яисә «хан» дип аталган һәм аларга хакимиятне Тәңре тапшырган дип саналган. Ләкин каган гадел булмаса, бабаларның гореф-гадәтләрен бозып идарә итә башласа, Тәңре хакимиятне аның кулыннан алып, бу затка үлем дә җибәрә алган. Тәңре тарафыннан каганнарга бирелгән дөнья белән идарә итү хокукының максаты – илдә иминлек, тәртип һәм гаделлек урнаштыру. Каганнар исә Тәңре яки Җир-Су белән турыдан-туры үзләре яисә камнар аша аралашкан.

Каганнарның илаһи көчләр белән элемтәсен VIII гасырның башына караган Күлтәгин исемле гаскәр башлыгына багышланган таш язмасыннан күрергә мөмкин. Анда болай дип язылган: «Төркиләрнең Күге һәм Изге Җир-Суы: «Бетмәсен төрки халык, халык булып калсын!» – дип әйткән. Күк (ягъни Тәңре) үз биеклегеннән этием Илтәреш каган һәм әнием Илбелгә хатын белән җитәкчелек итеп, аларга халык белән идарә итү өчен хакимиятлек бирде».

**Тәңречелекнең әхлак нигезләре.** Борынгы төркиләр тормышта кеше ике юлның берсен сайлый ала дип санаганнар. Берсе – яшәгәндә игелекләр кылып, күккә омтылып, үлгәннән соң, күктә яшәү юлы. Икенчесе – явызлык кылып, үлгәннән соң, җир астына сөрелү һәм анда мәңгелек газапка дучар ителү. Шуңа күрә кеше оҗмахка әләгергә омтылган, ә моңа ирешү өчен, ул игелек кылырга, әхлакка таянып яшәргә тиеш була.

Тәңречелектә ата-бабаларга ихтирам аеруча әһәмияткә ия. Борынгы төркиләр карашынча, исән кешеләр белән күптән вафат булган ата-бабалар арасында тыгыз бер рухи бәйләнеш бар. Алар үлгән бабаларының рухлары белән камнар аша аралашып, алардан ярдәм көтәләр.

Тәңречелек – борынгы төрки халыкларда аеруча киң таралган диннәрнең берсе. Бу дин буенча кеше табигать белән берлектә яши. Тәңречелекнең әхлакый кагыйдәләре кешедән тугры, намуслы һәм башкалар алдында җаваплы булып яшәүне таләп итә. Каганнар исә гадел булырга һәм халыкка карата кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш булалар.

**Тәңречелекнең нигезендә кешенең үз җирен, ватанын ярату һәм ата-бабаларына ихтирам хисе ята. Тәңречелек – безнең бай тарихи һәм мәдәни мирасыбызның бер өлеше.**

## Җир ничек яралган (легенда)

Бик борынгы заманнарда, әле Җир дә, кеше дә булмаган вакытларда, Җир шары гел судан гына торган, ди. Кая гына бакма, бар җирдә дәрья-су булган, давыллар уйнаган, дулкыннар күккә бәйләнгән.

Дәрьяда мәһабәт кошлар – үрдәкләр йөзеп йөргән, имеш. Алар су төбенә төшеп азык эзлиләр икән. Тәңре Җирне ятратмакчы булган. Шунда бер үрдәк су төбенә чумган да томшыгына азык алырга теләгән. Томшыгын тирәнгәрәк батырганмы, ул су төбеннән бик күп ләм-балчык алып чыккан. Бу ләм шулкадәр күп булган ди, хәтта әлеге үрдәкнең томшыгыннан коелып, су өстенә Җир-утрау булып өелеп калган. Имеш, әнә шуннан инде коры җир, Җир шары барлыкка килгән дә ди.

# ТӨРКИ-ТАТАРЛАРДА ГАИЛӘ

Кешелек тарихында гаиләнең бик күп формалары һәм төрләре билгеле. Төрки халыкларның традицион гаилә тормышы да озын тарихи юл уза.

Палеолит чорында зур-зур көтүләр булып яшәгән кешеләрдә, эре хайваннарны аулау өчен, бергәләп эш итү ихтыяҗы туган. Бу исә аучылар төркемнәрен үзара якынайткан. Шулай итеп, ыруглар барлыкка килгән. Әкренләп ыруг эчендә бәйләнешләр табигый кардәшлеккә нигезләнә башлаган.

Ыруглык җәмгыятендә кешеләр арасында тигезлек хөкем сөргән. Бергә ауга йөргәннәр, тапкан малларын үзара бүлешкәннәр. Ыруглар борынгы кешеләрнең көтүсыман төркемнәреннән бер урында яшәүләре белән аерылып торганнар. Балалар барысы да аналары белән бергә яшәгәннәр, нәсел исәбе дә ана ягыннан алып барылган. Ыруг тормышында ананың роле гаять зур булган.

Ирләрнең төп кәсебе аучылык булган. Ирләре ауда чагында, йортта хуҗалыкны алып бару һәм бала тәрбияләү хатын-кыз өстенә төшкән. Шунлыктан гаиләдә тоткан урыннарына, хезмәтләренә бәйле рәвештә ыругтагы ир-ат һәм хатын-кызлар арасындагы тигезлек акрынлап бетә барган, хуҗалык һәм җәмәгать тормышында җитәкче рольне хатын-кыз уйный башлаган.

Терлекчелек, игенчелек үсү һәм тимердән ясалган эш коралларыннан киңрәк файдалана башлау нәтиҗәсендә, хуҗалыкта төп роль ир кешегә күчә, матди байлыклар белән тәэмин итүдә дә ирләр төп көчкә әйләнә. Хатын-кызларга йорт эшләре кала. Ыруг башы итеп бары тик ирләр генә куела, зур патриархаль гаиләләр барлыкка килә. Хуҗалыкның күмәк формалары үскән шартларда, халыкның сан ягыннан артуы аерым ыруглык төркемнәренең зуррак берлекләргә, кабиләләргә берләшүенә китерә. Кабиләләр күп санлы елга үзәннәрендә аучылык, балык тоту, иген игү, терлек асрау белән шөгыльләнәләр. Аерым гаиләләрнең хуҗалык ягыннан мөстәкыйльлеге арта. Бай гаиләләр аерылып чыга, хосусый милек барлыкка килә. Бу исә ыруглык мөнәсәбәтләренең таркалуына китерә. Кабиләләр һәм гаиләләрнең башында ирләр торса да, хатын-кызларның җәмгыятьтә тоткан аерым урыны әле соңгырак тарихи чорларда да чагылыш таба.

Моңа охшаш этаплар борынгы төркиләр тарихында да булган. Төркиләргә дә уртак хуҗалык алып барган берничә буын якын туганнарны берләштергән зур патриархаль гаиләләр (гадәттә, аның



*Гаилә.
Рәссам
М.Чевалков.*

башында ир кеше торган) хас булган, әмма акрынлап алардан 5–6 кешедән торган кечерәк гаиләләр бүленеп чыга башлаган.

Гадәттә, һәр гаилә үз йортында яшәргә тиеш булган: үсеп җиткән егетләр тиздән аерым яши башлаганнар. Өйләнергә җыенган егетнең атасы яшьләргә туй вакытында ук яңа тирмә һәм мөстәкыйль хуҗалык алып бару өчен кирәкле милек, мал-туар биргән. Ата йортын – «улуг өй», өйләнгән улыныкын – «кече өй» дип атаганнар. Яңа учакка утны ата нигезендәге учактан алып тергезгәннәр. Бүген дә татарлар гаилә коруны «өйләнү» (үз йортыңны кору, үз өйле булу) дип юкка гына атамыйлар.



*Хатын-кызлар киеме.
Балбаллар буенча
реконструкция.*

Патриархаль мөнәсәбәткә нигезләнгән гаиләдә ата кешенең дәрәҗәсе югары булган. Төркиләр өчен гаилә – шул ук дәүләт. Гаилә башында торган ир гаять зур хокукларга ия булган. Аның алдында шулай ук зур бурычлар да торган. Гаилә башлыгын төркиләр хәтта «өй каганы» дип тә атаганнар. Дәүләт каганы, илне һәм халыкны саклап, аның иминлеген тәэмин иткән кебек, гаилә башы да өйдәгеләрнең иминлеген саклап, аларның мул тормышын кайгыртырга тиеш булган.

**Гаиләдә ананың роле.** Ирләрнең дәрәҗәсе никадәр югары булмасын, төркиләр хатын-кызларга, аларның хокукларына да зур хөрмәт белән караганнар. Хатын-кыз үз йортында тулы хокуклы хуҗабикә булган. Сугышлар вакытында йортны, гаиләне тәэмин итү тулысынча хатын-кызлар җилкәсенә төшкән. Шундый ук вазыйфаларны алар тыныч тормыш шартларында да үтәгәннәр.

Йорт эшләре хатын-кызлар вазыйфасына кергән. Моңа җавап йөзеннән, ирләр хатыннарына карата йомшак мөгамәлә һәм игелеклелек күрсәтергә тиеш булганнар.

Хатын-кызлар гаиләдә генә түгел, дәүләт эшләрендә дә катнашканнар. Хәтта чит мәмләкәтләрдән килгән илчеләрне дә хан үз хатыныннан башка кабул итмәгән, ханнарның фәрманнарын ханбикә дә раслаган. 846 елда уйгур ханы Арыслан Кытай илчесен кабул иткәндә, аның хатыны да катнашкан. Әлеге традиция соңгы чорларда да дәвам иткән. «Болгар патшасының хатыны тантаналы мәҗлесләрдә ире белән янәшә утыра, аларның гореф-гадәтләре шундый», – дип яза Ибне Фадлан үзенең сәяхәтнамәсендә.

Хатын-кызлар иҗтимагый һәм дини тормышта да җитди вазыйфалар башкарганнар (алар арасында дини йолалар белән җитәкчелек итүчеләр дә булган).

Төркиләр ишле гаиләдә яшәүне зур бәхеткә санаганнар. Яшь балалар ак сакаллы бабаларыннан тәрбия алып үскәннәр. «Әгәр берәүнең баласы туса, баланы атасыннан элек бабасы үзенә ала», – дип яза Ибне Фадлан Болгар иле турында. Төркиләр балаларын



*Әбисе белән оныгы. Фарсы миниатюрасы.*

тормыш тәҗрибәсе туплаган аксакалларга тәрбиягә биргәннәр, аларны «сөт аталары», «аталыклар» дип олылаганнар.

Гаиләдә балалар булмау зур бәхетсезлек саналган. Чөнки балалар булмагач, буыннан-буынга тапшырылып килгән туганлык мөнәсәбәтләре өзелгән һәм бөтен нәсел, ыруг юкка чыккан.

Олыларга хөрмәт, кечеләргә ярдәм күрсәтү, бердәмлек (бер халык, бердәм ил булып яшәү) төркиләрнең төп кануны булган.

Зур гаиләдә, бергә яшәү сәбәпле, туганлык мөнәсәбәтләре гаять көчле булган. Туганнар – төркиләрнең таянычы, терәге. Бөтен төркиләр бер-берсен туганнар дип санаганнар.

Гаиләдә балалар күп булса, ыруг, кабилә дә көчле була. Көчле ыруг белән бөтен кавем дә исәпләшкән. Шуңа күрә һәр ир кеше – яхшы ул һәм ата, батыр сугышчы – гаиләсенә, ыруг, кавеменә таяныч булырга тиеш булган. Батыр сугышта һәлак булса, аның гаиләсенә туганнары ярдәм иткән. Шуңа күрә далада ятимнәр, ялгыз картлар булмаган.

Туганлык мөнәсәбәтләре арасында ана ягы туганнары иң якыннары саналган. Төркиләрнең мондый мәкальләре дә булган: «Ата ягыннан бертуганнар ачуланып сугышканда, ана ягыннан бертуганнар бер-берсенә ярдәм итәләр». Күкрәк сөте имезеп үстергән ананың балалары алдында абруе зур була. Ана сүзеннән чыгу зур гөнаһ саналган. Тирмәгә кергәндә, яхшы угыл юкка гына башта анасын, аннары гына атасын сәламләмәгән.

Борынгы төрки халыкларда түбәндәге туганлык атамалары кулланышта булган.

Ата, кан – ата;
Ана, өр – ана;
Огул – угыл, ул;
Кыз – кыз, кызым;
Келин – килен;
Күдегү, күбек – кияү;
Каин ата – иренең атасы;
Каин ана – иренең әнисе;
Ага, эджи – абый, абзый;
Йенге – җиңги, абыйсының хатыны;
Апа – түтәй;
Йезне – җизни, апасының ире;
Апушка, эр – ир;
Катын – хатын;
Каин ага – хатын яки ирнең абыйсы;
Каин ини – иренең энесе;

Сингиль – сеңел, үзеннән кечерәк кыз бала;
Каин сингиль – каен сеңел – иренең сеңлесе;
Абага – әтисе ягыннан абый;
Тагай – әнисе ягыннан абый;
Балдыз – хатынының сеңлесе.

**Ислам дине һәм гаилә.** Ислам дине кабул ителү белән, гаилә мөнәсәбәтләре дә камилләшә барган. Ислам дине бөтен кешелекне бер ата һәм бер ана – Адәм белән Хаува балалары дип карый. Ир белән хатын мөнәсәбәтләре, гаилә кору шәригать кануннарына нигезләнә башлый. Ата-ана балаларына үзләренең һөнәрләрен өйрәтеп калдыра. Һөнәри осталыгына карап, нәселгә исем (балта остасы, тимерче, чүлмәкче, күнче, тегүче һ.б.) бирелә. Шуңа бәйле гыйбарәләрне бүгенге телдә дә очратырга мөмкин: «Ата күргән ук ата белер, Ана күргән тун кисә белер».

Гаиләдә ананың абруе үскәннән-үсә барган. «Җәннәт аналарның аяк астында» диелгән бер хәдистә. Ана гаиләдә сәламәт мохит тудырган, баласына яхшы тәрбия биреп, хәләл ризыклар ашатып, динле, ана телен хөрмәт итүче, үз милләте өчен файдалы итеп үстергән.

Еллар дәвамында гаилә тормышында төрле гореф-гадәтләр урнаша барган, кайберләре, үзгәрешләр кичереп, хәзерге көнгә кадәр килеп җиткән.

Гаиләдә сау-сәламәт бала туу зур шатлык булган. Бала тугач та, озакка сузмыйча, исем кушканнар. Матур яңгырашлы һәм яхшы мәгънәле исемне төркиләрдә ата кеше үзе сайлаган. Бала туган



*Гаилә тормышы. Фарсы миниатюрасы.*

шатлыктан бәби туе үткәргәннәр, балага бүләкләр биргәннәр. Нәсел дәвамчысы булган ир баланы сөннәткә утырткач, мөселманнар зур мәҗлес уздырганнар, көрәш, ат чабышы, уктан ату һ.б. уеннар оештырганнар.

Үсеп җиткәч, ир баланы өйләндерү, кыз баланы кияүгә бирү шулай ук ата-ананың изге бурычы саналган. Борынгылар яшь егетләргә кызларны башка ыругтан, башка кабиләдән дә ала торган булганнар. Ханнар һәм аксөякләр дә, дәүләт мәнфәгатьләрен кайгыртып, башка мәмләкәтләргә кыз биргәннәр, улларын өйләндергәннәр. Егет, кыз алу өчен, билгеле бер күләмдә калым түләргә тиеш булган. Байлык читкә китмәсен өчен, соңрак кызны үзләре яшәгән төбәктән сайлый башлаганнар. Ата-ана, балаларын ярәшкәндә, килен яисә кияүнең нәселен тикшереп, үзара киңәшләшеп эш иткән. Мөгаен, шуңа күрәдер, төрки халыкларда гаилә нык, таза булган. Олы улларны никахландырып, «башка чыгарганнар», аның гаиләсенә аерым яшәү урыны төзеп биргәннәр. Гадәт буенча, гаиләдәге төпчек малай ата-ана йортында яшәп калган. Ата-ана картайган көнгә кадәр балалары, оныклары белән яшәгән.

## Йосыф Баласагунлы «Котадгу белек» (Бәхеткә илтүче белем). XI гасыр

«Хатыннарны әхлаклы гаиләдән генә алыгыз. Үз гаиләңнән югарырак торган гаиләдән булмасын. Андый гаиләдән алынган хатын тәкәббер була. Йөзнең матурлыгына артык зур әһәмият бирмәгез. Артык чибәрлекнең хәтәр булуы мөмкин. Әхлаклылык һәм холык күркәмлеге мөһимрәк була. Хатын алганда байлык эзләмә. ... Бала туса – аны өйдә тәрбияләргә яхшырак... Хатыннарның урыны өйдә. Әмма аларга барлык кирәкләрен бирегез, муллык һәм иминлеген тәэмин итегез. ...

Өйдәгеләрне аш-су белән тәэмин ит. Аларга көч җитәрлек эшне генә куш. Аларны җәберләмә. Алар да адәм баласы икәнен беркайчан да онытма. Җәберләсәң – сиңа тәмугъ җәзасы булыр. ... Юмарт бул, гаиләңне мул итеп аш-су белән тәэмин ит. Әмма керемнәреңә карап чыгымнар ясa».

## Сак-сок бәете (өзекләр)

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе,
Сак белән Сокның бәетен ишетәсе.

Әнкәй орышты тимер ук өчен,
Әнкәй орышты бигрәк юк өчен.

Самавыр куйды, чәйләр эчерде,
Эчеп бетергәч, каргап очырды. [...]

Әткәй калдырды, өйдә торсын, дип,
Әнкәй каргады, Сак-Сок булсын, дип.

Төшкәндер безгә әнкәй каргышы,
Үзебез туганчы, тәкъдир язмышы.

Әнкәй каргагач, Сак-Сок булдык без,
Бу дөньялардан гыйбрәт алдык без.

Су буйларында бик күп йөрдек без,
Сак-Сок булгачтын, дөнья гиздек без. [...]

Урыныбыз урман, икебез туган,
Кавышу юк безгә, әнкәй каргаган. [...]

Әнкәй җылыйдыр, ник каргадым, дип,
Сак-Сок йөридер, харап булдык, дип.

Болай булдык без: каргыш тәдбире,
Елама, әнкәй, – Ходай тәкъдире. [...]

## ТӨРКИ-ТАТАРЛАРДА АШАМЛЫКЛАР

Татар милли ризыклары – чәкчәк, кабартма, кыстыбый һ.б. бик борынгы заманнардан ук килгән ризыклар. Төрки-татарлар арасында нинди ашамлыклар киң кулланылган соң?

**Табигать, хуҗалык итү үзенчәлекләре һәм ризык.** Билгеле булганча, борынгы халыкның төп кәсебе аучылык булган. Кыргый хайваннарны күмәкләшеп аулаганнар. Зур учак ягып, итне шунда кыздырганнар. Хәзерге көндә учак өстендә итне кыздыру (шашлык ясау) – борынгыдан калган күренеш. Татар халык ашлары төрки кабиләләрнең этник үзенчәлекләрен саклап калган.

Милли ашларның формалашуына табигый тирәлек җитди йогынты ясаган. Илнең ике географик зона – урманлы Төньяк һәм далалы Көньяк кушылган җирдә, шулай ук ике зур елга – Идел һәм Чулман бассейнында урнашуы да табигый азыклар алмашуга, сәүдәнең иртә



*Икмәк сатучы. Фарсы миниатюрасы.*

үсеш алуына булышлык иткән. Болар барысы да халык ашларының төрләрен шактый баеткан.


Борынгы бабаларыбыз, нигездә, авыл хуҗалыгы, игенчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнә. Гарәп географы Ибне Рөста X гасыр башында ук: «Болгарлар – игенче халык, төрле бөртекле ашлык: бодай, арпа, борчак, тары үстерәләр», – дип язган.

**Халыкның борынгы ризыклары.** Ашлыкны урак һәм чалгылар белән җыйганнар, тегермән ташы ярдәмендә тарттырганнар, онга яки ярмага әйләндергәннәр.

Шулай ук бөртекле ашлыкны бөтен килеш куыру традициясе дә борынгы заманнарга барып тоташа. Куырылган бөртекле ашлыкны киледә төйгәннәр яки таш тегермәндә тартканнар. Вак ярмадан талкан әзерләгәннәр. Аны, ерак юлга чыкканда, үзләре белән алганнар, суга яки сөткә изеп ашаганнар. Каймакны әкрен генә кайнатып, аннан ботка-боламык ясаганнар.

Кыргый хайваннарны кулга ияләштереп, халык терлекчелек белән шөгыльләнә башлаган. Татарлар эре мөгезле, нәселле терлек тоткан. Чыдам, нык атларны арбаларга җиккәннәр. Яшь тайларны ит өчен, сугым малы итеп асраганнар. Бия сөтеннән шифалы эчемлек – кымыз ясаганнар.

**Икмәк – изге ризык.** Борынгы заманнарда икмәкне җәймә рәвешендә учакта пешерә торган булганнар. Хәзерге көндә дә киң кулланышта булган кыстыбый иң борынгы һәм гади ашамлыкларның берсе санала. Аны кайбер урыннарда «күзикмәк» дип тә атыйлар.



*Кыстыбый пешерү.*
*Фарсы миниатюрасы.*

Кыстыбыйны төче камырдан әзерләнгән юка җаймә эченә тары боткасы салып ясаганнар. Соңрак кыстыбый эченә бәрәңге боламыгы да сала башлаганнар.

Татар ашлары арасында әче камырдан пешерелгән ризыклар аерым бер урын алып тора. Аларга, барыннан да элек, ипи керә. Ипи өчен әче камырны урманнарда үскән колмак үләненнән ясалган чүпрә салып әзерләгәннәр. Хәзерге көндә дә иписез көндәлек аш та, бәйрәм табыны да узмый, икмәк ул – изге ризык. Электән үк халыкның «ипидер» дип ант итү гадәте дә булган. Табында икмәкне гаиләнең иң өлкән кешесе кискән. Балаларны кече яшьтән үк ипинең һәр валчыгын җыярга, кадерләргә өйрәткәннәр.

**Камыр ашлары.** Ипидән тыш, әче камырдан төрле ашамлыклар әзерләнгән. Алар арасында иң таралганы – кабартма. Кабартманы янып торган мич алдында, кайнап торган майда арыш оныннан пешергәннәр.

Төче камырдан табада коймак та пешергәннәр. Халыкның яраткан борынгы ашамлыкларыннан тагын берсе – камыр эченә симез ит (сарык, сыер, каз, үрдәк) һәм ярма салып пешергән бәлеш. Бәлешне зур итеп тә, кечкенә итеп тә әзерләгәннәр. Өчпочмак та – күптәнге татар ашамлыгы, аның эченә элегрәк симез ит белән суган гына салганнар, соңрак, бәрәңге үстерә башлагач, бәрәңге кушканнар.

**Эчемлекләр.** Урманнарда кыргый умарта кортлары күп булган, алар агач куышлыгына бал җыйганнар. Халык җәенә бер-ике тапкыр шул балны җыеп алган. Балдан тәмле эчемлек әзерләгәннәр (набиз һәм суджув), шулай ук җиләк-җимешләрне дә балга салып саклаганнар. Җир җиләге, карлыган, мүк җиләге һәм башка җиләкләрне җыеп киптергәннәр, кайсыларыннан как койганнар. Җир җиләге, мәтрүшкә һәм башка үләннәрне чәй урынына файдаланганнар.

Чәй татарларга Һиндстан, Кытай һәм башка илләр белән сату-алу аша килеп кергән. Чәйгә сөт салып эчү гадәте татарларда хәзер дә дәвам итә. Урманда чикләвек күп булган, кыргый алмагачлар үскән. Баллы алма, алмалы сары май чәй янына куела торган ризык булган.

**Ислам дине һәм туклану.** Идел буе болгарлары 922 елда ислам динен кабул иткәннән соң, ашау-эчүдә аерым үзенчәлекләр барлыкка килә (хәләл һәм хәрам, яраган һәм ярамаган ризыклар). Мөселманнар шәригать кануннары буенча суелган мал итен генә ашаганнар. Җәен, көзен яңа суелган ит ашасалар, кыш көне туңдырган ит пешергәннәр, шулай ук итне озак саклар өчен ыслап, каклап, киптереп тә куя торган булганнар.

Һәр хуҗалыкта диярлек кәҗә, сарык асраганнар. Сарыкны ите, йоны, тиресе өчен күпләп үстергәннәр, ә кәҗәне бигрәк тә сөте өчен тотканнар: аның сөте шифалы саналган. Дуңгыз ите хәрам ризык булганлыктан, мөселманнар дуңгыз үрчетмәгәннәр.

Сыер сөте шулай ук иң кирәкле һәм файдалы ризыклардан саналган. Сөттән сөт өсте, эремчек, каймак, май, сыр, катык ясаганнар. Катыкка салкын чишмә суы кушып ясалган әйрән – борыңгыдан килгән эчемлек. Эремчекне киптереп, корт, кызыл эремчек, ак майны кайнатып, сары май әзерләгәннәр.

Кырда үскән үсемлекләрне (суган, сарымсак, кабак һ.б.) торабара яшелчә бакчаларында да үстерә башлаганнар. Кабак белән тары ярмасыннан пешерелгән ботка – бик борынгы ризыкларның берсе, аны хәзерге көндә дә әзерлиләр.

Борынгы халыкның көнкүрешенә балчыктан ясалган савыт-сабалар килеп кергәч, аш-су әзерләү тагын да камилләшкән. Татарларга итне майда кыздыру хас булмаган. Шулпалы кайнар аш, токмачлы аш, итле өйрә татарларның иң яратып әзерли торган ризыгы булган. Тутырманы да шушы ук ашамлыклар кебек күптән әзерләгәннәр. Аны терлек эчәгесенә чапкан яисә вак итеп тураган бавыр белән тары яисә дөге ярмасы тутырып ясаганнар. Су буйларында яшәгән халык балык тоту белән дә шөгыльләнгән, әмма балык ашлары милли ризык булып кереп китмәгән.

Уңайлы табигать шартлары татар халкына һәртөрле ашамлыклар, эчемлекләр әзерләргә мөмкинлек биргән. Безнең өчен гадәти булган ашамлыклар – өчпочмак, токмачлы аш, итле шулпа, итле бәлеш, чәкчәк, кабартма һ.б. ризыкларның үз тарихлары бар.

**Милли ризыкларыбыз, бик борынгы заманнарда ук барлыкка килеп, буыннан-буынга тапшырыла барып, елдан-ел камилләшеп, безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәр.**


# БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Дунай елгасы буена Аспарух белән болгарларның бер өлеше генә килеп җитә. Калган өлеше үзләренә яңа ватан таба. Аларның яңа ватаны – Идел һәм Чулман арасы була.

Урта Иделгә беренче болгарлар VII гасыр ахырында – VIII гасыр башында килә. Хәзәрләрнең Бөек Болгарны тар-мар итүе аларны шундый ерак сәфәргә чыгарга мәҗбүр итә. Болгарлар үзләре белән безнең якларга ярым күчмә тормыш гадәтләрен алып киләләр. Гомумән, алар терлекчелек, көтүчелек белән шөгыльләнәләр.

Йөз елдан соң, 737 елда, хәзәрләр гарәпләр тарафыннан зур җиңелүгә дучар ителәләр. Хәзәрләр кулы астында калган Азов буе болгарлары, каты кысрыклаудан сакланыр өчен, зур төркемнәр белән яңадан Урта Идел буена китәләр.

IX–X гасырлар чигендә Хәзәр каганлыгында дәүләт дине булып яһүд дине (иудаизм) формалаша. Болгарлар арасында исә ислам дине таралган була. Яһүд диненә каршы булган болгарлар элегрәк салынган юл буйлап Урта Идел киңлекләренә күченеп китәләр.




*Болгар дәүләтенең картасы.*

Болгарларның безнең якларга соңгы күчешләре төрки телле бәҗәнәкләрнең (печенеглар) Хәзәр каганлыгына көчле һөҗүме белән бәйле. Бу вакыйга IX гасырның азагы – X гасыр башында була.

Урта Идел буена болгарлар килгәнче, биредә төрки, фин-угыр кабиләләре – хәзерге мари, удмурт һәм мордва халыкларының борынгы бабалары яши. Күпмедер вакыт Идел-Урал киңлекләрендә борынгы венгрлар да гомер сөрә, соңрак алар Урта Дунай буйларына күчеп китәләр.



*Болгар кешесе. VIII–IX гасырлар. Реконструкция.*

**Болгар дәүләте барлыкка килү.** Тиздән болгарлар җирле халык арасында өстенлекне яулап алалар. Алар актив рәвештә җирне сабан белән сөреп эшкәртә башлыйлар һәм башка яңа һөнәрләр үзләштерәләр. Бу хәл болгарлар арасында милек буенча тигезсезлекнең үсүен тизләтә.

Болгарда хәрби-кабилә аксөякләренең көчле хәрби дружинасы була. Алар күрше җирләргә яу чабалар, халыктан салым җыярга да ярдәм итәләр.

Хәзәрләр белән көрәштә дә болгарлар дружинага таяналар. Чөнки алар кайчандыр Хәзәр каганлыгына бәйлелеккә төшкән булалар һәм хәзер мөстәкыйльлек яулап алырга ашкыналар. Болар барысы да Идел болгарларының дәүләтчелеге формалашуын дәлилли.

Болгар дәүләте формалашуның соңгы этабы X гасыр башына туры килә. Ул вакытта Идел һәм Чулман буйларында, безнең төбәктә шәһәрләр һәм ныгытмалар төзелә. Беренче болгар тәңкәләре барлыкка килә. Чит дәүләтләр белән элемтәләр ныгый.

Хәзәрләргә каршы көрәштә ярдәм эзләп, болгарлар үзләренә Багдад хәлифе әл-Мөхтәдир илчелеген чакыралар. Илчелекнең маҗаралы юлы илченең сәркатибе Әхмәд ибне Фадлан язмаларында тәфсилләп язылган. Каганлык ислам динен тарату белән кызыксынган гарәпләрнең сәүдә юлларында торган. Болгарлар гарәплардән



*Багдад хәлифәсе илчелеге.*
*Рәссам Р.Заһидуллин.*

ярдәм алалар һәм рәсми рәвештә яңа дин кабул итәләр. 922 елда ислам Идел болгарларының дәүләт диненә әверелә. 965 елда, рус кенәзе Святослав хәзәрләрне тармар иткәннән соң, болгарлар каганлыкка буйсынудан туктыйлар.

**Болгар иленең территориясе һәм халкы.** Идел-Чулман Болгары зур җирләрне биләп торган. XII гасырга илнең чикләре тагын да киңәйгән. Төньякта алар – Казан елгасына, ә көньякта Иделнең Самара янындагы борылышына кадәр килеп җитәләр. Болгар дәүләтенең көнбатыш чикләре – мордва җирләрендәге Сура елгасы, көнчыгыш чикләре Зәй елгасы була. Болгарларның күршеләре борынгы мари, удмурт, мордва һәм башка кабиләләр була.

Болгарлар Иделнең ике ягында да яшиләр; шулай ук Чулманнан төньяктагы җирләр дә аларныкы булган. Төп җирләр һәм Биләр, Болгар, Суар, Җүкәтау кебек зур шәһәрләр Иделнең сул як, дистәләгән шәһәрләр, авыллар һәм алар арасында данлыклы Ашлы шәһәре Иделнең уң як ярына урнаша. Чулман алды җирләрендә халык сирәк урнашкан була. Мондагы шәһәрләр арасында иң билгелесе – Кашан һәм Чаллы (Балык Бистәсе районындагы Котлы Бөкәш авылы янында). XI гасыр башында Казансу елгасы буенда, хәрби ныгытма һәм сәүдә үзәге буларак, киләчәктә безнең республика башкаласы булачак Казан барлыкка килә.

Илнең халкы төрле кабиләләрдән тора. Болгар кабиләләреннән тыш суарлар, барсиллар, бәрәнҗәрләр, шулай ук эсәгелләр һәм биләрләр дә булган. X гасырның икенче яртысында алардан бердәм болгар халкы барлыкка килә. Илнең бар халкы өчен бердәм атама булып *болгар* исеме тора.

**Болгар илендә идарә**. Идел-Чулман Болгары элеккеге феодаль дәүләтләр кебек идарә ителә. Дәүләт башында торган хөкемдар Болгарда *әмир* дип атала. Иң элек аны *илтәбәр* – җитәкче, дәүләт башлыгы дип йөртәләр.

Илнең беренче әмире Алмышның исеме беренче болгар тәңкәләрендә дә бар. Ул Бохарага һәм Багдадка болгар илчеләрен җибәрә һәм үзендә дә Багдад хәлифәсе илчеләрен кабул итә. Исламга күчкәч, ул үзен мөселманча Җәгъфәр бине Габдуллаһ дип йөртә башлый. Яңа дин кабул итү илтәбәрнең дәрәҗәсен тагын да күтәрә. Аның 50 меңлек гаскәре дә була.

Әмиргә дәүләтнең бөтен өлкәләрендәге җирле хакимнәр буйсына. Алар барысы иң югары аксөякләр катламын тәшкил итә. Хакимлек итүче катламга шулай ук хәрби дружина җитәкчеләре, бәкләр, югары дин башлыклары керә.

Аксөякләр кул астында игенчеләр, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр була. Алар дәүләт файдасына феодаль йөкләмәләр үтиләр, ләкин феодалларга бәйле булмыйлар.

**Шулай итеп, Болгар иле Көнчыгыш Европадагы иң кодрәтле һәм бай илләрнең берсенә әверелә.**

## Болгар каласының корылуы турында риваять

Нух пәйгамбәрнең өч улы булган. Аның бер улы Яфәс атлы икән. Яфәснең Газый, Терек, Алып исемле өч улы булган. Яфәснең уллары берсеннән-берсе матур, зифа буйлы батыр егетләр булып үскәннәр.

Төрек кардәше Алып белән елга янына барып урнашкан.

Алып бик батыр кеше булган. Ул, чынлап тотынса, кечерәк тауларны да аудара икән, сыңар кулы белән ат-сыерларны күтәрә ала икән. Болар күчеп килеп утырган җирнең урыны сазламык һәм кап-кара урман булган. Шуның өчен йөргән чакта Алыпның чабатасына, яңгырлы вакытта юеш балчык сыланып, корыда тузан тулып, аңа йөрергә уңайсызлый икән. Шуңа күрә Алып әледән-әле утырып, чабатасына ияргән балчыкларны кагып йөргән. Менә шуннан юл буйларында, тигез җир өсләренә түмгәкләр, кечерәк таулар хасыйл булган икән. Биктимер авылыннан Матак авылына барган чакта Олы күл буендагы түгәрәк кечкенә таулар шул Алыпның чабатасын кагуыннан хасыйл булган таулар икән, ди.

Менә шушы Алып батыр беркөннеауга, сунарга чыккан. Ул чакта урманнар бик калын һәм очсыз-кырыйсыз зур булганга, ауда озак йөри торгач, юл сабкан – адашкан, агасы Төрек янына кайта алмаган. Алып, урман эчендә күп йөри торгач, бер су янына барып чыккан. Ул су буенда аның белән бер телдә сөйләшә торган, ләкин Алыпка ят булган кешеләр тора икән. Тел бер булгач, Алып белән бу кешеләр үзара аңлашканнар. Шуннан соң Алып, үзенең кардәше Төрек янына кайта алмагач, бу кешеләр белән бергә яши башлаган. Алар белән тәмам үзләшеп киткән. Ул инде шул кешеләрнең арасыннан үзенә бер кыз сайлап өйләнгән дә.

Алып батырның ике ир баласы туган. Ул бу балаларга ничек дип тә ат куша алмаган.

Бу чакларда тормыш җәйләүдә, киез өйдә икән.

Менә бер көн һава алмашып киткән. Көн болытлаган, һава салкынайган. Алыпның киез өй эчендә бишектә ята торган балаларыннан берсе өйнең салкынлыгыннан бик нык еларга керешкән. Бу бала елаганда һаман кулларын болгый-болгый елый икән. Алып, баланың елаганын күреп, аны юатырга тырышкан, бишеген тирбәткән, бишек тирбәткәндә җырлый торган җырлар җырлаган. Шулай да бу бала елаудан туктамаган, һаман кулын болгый-болгый елаган. Бу бала озак елагач, Алыпның күңеленә бер исәп төшкән. Бу бала тикмәгә болай еламаска кирәк, бу инде артык озакка китте, аның болай елавында нәрсә булса да бер хикмәт бардыр дип, Алып уйланырга керешкән. Күп уйлый торгач, Алыпның күңеленә: бу баланың елавы аңарга ат кушылмаганнан булырга кирәк, ат кушсаң, бәлки, ул елавыннан туктар, дигән фикер килгән. Ул шуннан соң бу балага ат кушарга булган. Алып үзенең хатыны белән киңәшкән дә, бала елаган чагында кулларын болгап елаганлыктан, аңа Болгар дигән ат кушкан.

Балаларының Болгар атлы булуы Алыпка һәм хатынына бик ошаган. Алар икенче балаларын да бер ат белән атамакчы булганнар. Болар ирле-хатынлы икәүләп бу турыда уйлашканнар, сөйләшкәннәр. Байтак вакыт уздырганнар.

Актыгында икенче балаларына Бортас кушмакчы булганнар. Шулай итеп, боларның икенче балалары Бортас булган.

Алыпның бу балалары үзе шикелле батыр булып үскәннәр. Алар да шул җирдә аталары белән бергә гомер иткәннәр. Бу балалар, зураеп үсеп җиткәч, икесе ике урында кала корып яши башлаганнар.

Болгар корган кала, «Болгар» исеме белән дан тотып, ничә йөз еллар атаклы күп ханнар яшәгән кала булып киткән. Менә инде шул Болгар хәзерге Идел буенда хәрабәсе генә калган Болгар шәһәре икән, ди.

Бортас корган кала да, бара-бара зураеп, Бортас шәһәре исеме белән дан тоткан, ди. Бу ике калада яшәгән кешеләрнең балалары күбәеп, күп еллар үткәч, бер токымнан ике төрле халык: берсе – болгар, берсе – бортас барлыкка килгән. Боларның һәр икесенең башта телләре бертөсле булган. Әмма күп еллар үтә-үтә, телләре дә бераз үзгәреп киткән.

## Айдархан һәм сәхабәләр (риваять)

Болгар шәһәре элек бик зур булган, зур-зур кибетләр буеннан-буена тезелеп киткән. Аның башында Айдархан дигән гайрәтле патша торган. Айдарханның егерме яшькә җиткән Туйбикә атлы кызы бар икән. Ул авырый икән. Мөхәммәд пәйгамбәр өч сәхабәне (якын көрәштәшләрен) янына чакырып алган. Аларның берсе – Зөбәер бине Тәлка, икенчесе – Зөбәер бине Җәдга, өченчесе – Габдрахман. Шуларга таяк биргән, чалмасын салып биргән, кара савыты биргән:

– Менә Шәһре Болгар йортына юнәлегез, урамнарында йөрегез, без табибларбыз диегез, – дигән.

Болар Болгар йортына килеп җитәләр, урамда йөри башлыйлар. Айдарханның вәзире дә урамда йөри икән. Ул сәхабәләрне күрә дә яннарына килә. Сорый алардан:

– Сез кемнәр, каян килдегез?

– Без менә Мәккә-Мәдинәдән килдек.

– Нәрсә, сату итәргәме?

– Юк, без сатучылар түгел, без табиблар, – диләр болар.

Тегеләрне калдырып, вәзир патша янына китә. Айдарханнан сөенче ала бу:

– Безнең шәһәргә өч сәхабә килгән, дәва итеп йөрибез, дип әйтәләр, – ди.

Айдар патша әйтә:

– Алып кайт үзләрен, – ди.

Вәзир сәхабәләрне алып кайта сарайга. Айдархан патша сорый болардан:

– Сез каян килдегез? – дип.

– Без Мәккә-Мәдинәдән им итү, дәва итү өчен килдек, – диләр алар.

– Минә минем егерме яшьлек кызым бар, авырый, шешеп-шешеп чыккан.

– Дәва бар, – диләр сәхабәләр, – хәзер каен себеркесе кирәк булыр.

– Ә-ә, каен себеркесе бездә күп, – ди патша.

– Юк, – диләр алар, – безнең таяктан үскән себерке кирәк.

Бер урынга таяк кадап куялар. Габдрахман сәхабә намаз укып тора, таяк утырткан җирдән су чыга, күз алдында каен себеркесе үсә. Айдархан патша бу эшкә хәйран кала. Себеркене бирәләр патшага.

Минә кызны мунчага алып киләләр. Аны җәймә белән кәнизәкләре күтәреп керә. Туйбикәне чабындыралар, юындыралар. Туйбикә үзе киенә.

– Мин, – ди, – үзем генә чыгам, – ди. Аякка баса, тәмам терелә бу.

Кыз әнисенең бүлмәсенә керә. Әнисе бик аптырый, Айдархан патша янына кереп китә, кызның терелүе турында хәбәр бирә. Хәзер Айдархан сәхабәләргә әйтә:

– Кызымны бирәм берегезгә, – ди.

Кызны Коръәнхафиз Тәлкага бирергә була. Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәргә хат язалар. «Ал», – ди пәйгамбәр җавабында. Кызына да, атасына да:

– Иманга килегез, – диләр.

– Бөтен шәһәрне иманга китерәм, – ди патша. Ул бөтен шәһәрне мөселман итә.

Туйбикә белән сәхабә Тәлка егерме биш ел бергә торалар. Ә теге тылсымлы таяк утырткан җирдән чыккан коены халык изге кое итеп саный, Туйбикә коесы дип йөртә. Аның суы бик чиста, бик тәмле була. Хәзер ул кое юк инде.


# БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ ХУҖАЛЫГЫ

**Авыл хуҗалыгы.** Болгарларның төп кәсепләре авыл хуҗалыгы, һөнәрчелек һәм сәүдә була. Күпчелек авыл халкы игенчелек һәм терлекчелек белән шөгыльләнә. Гарәп географы Ибне Рөста X гасыр башында болай яза: «Болгарлар – игенче халык һәм төрле бөртекле икмәк: бодай, арпа, тары һәм башкаларны эшкәртәләр». Болардан тыш, алар борай, ясмык, борчак чәчәләр. Руслардан үзләштерелгән арыш чәчүлекләре аз урын ала. Икмәкне урак һәм чалгылар белән җыялар. Зур тегермән ташы ярдәмендә ашлык тарттыралар (онга яки ярмага әйләндерәләр). Тегермән ташларын атлар яки үгезләр хәрәкәткә китерә.

Болгарлар җирне сабан белән сөрәләр. Археологлар тарафыннан табылган сабан төрәннәре шул турыда сөйли. Уңдырышлы кара җирләрдә игенчелек яхшы уңыш китерә. Икмәк күп була. Болгарлар ачлык елларында хәтта рус кенәзлекләренә ярдәм күрсәтәләр. Рус елъязмаларында ике тапкыр шундый ярдәм турында искә алына.

Болгарлар үзләренең традицион һөнәрләрен – терлекчелекне дә онытмыйлар. Алар мал-туарның эре, нәселлеләрен тоталар, шуңа күрә сөт һәм иткә мохтаҗлык кичермиләр. Чыдам, нык атларны арбаларга, көчле үгезләрне сабаннарга җигәләр.

Болгарлар сугыш һәм чабыш атлары да үрчетәләр. Һәр хуҗалыкта диярлек кәҗә һәм сарык асрыйлар, йорт кошларыннан тавык тоталар. Урманнарга бай булган урыннарда ауга йөриләр. Аларны бигрәк тә кыйммәтле мехлы җәнлекләр – кеш, тиен, төлке кызыксындыра. Урманнарда шулай ук кыргый умарта кортлары күп була, алар агач куышлыгында бал җыялар. Болгарлар җәенә бер-ике тапкыр шул балдан набиз һәм суджув кебек үзләре яраткан эчемлекләр



*Болгар игенчеләренең хезмәт кораллары.*



*Археологик казылмаларда табылган чәчүлек орлык бөртекләре.*

ясыйлар. Балыкка бай булган елгаларда мәрсин, чөгә, сазан, җәен балыкларын тоталар.

**Һөнәрчелек.** Шәһәр халкы һөнәрчелек һәм сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Болгарда һөнәрчелек киң колач алган була. Биләрдә чүлмәк ясаучыларның остаханәләре генә дә 3 гектар мәйданны били. Нинди генә һөнәрчеләр булмый монда: металл коючылар һәм тимерчеләр, зәркәнчеләр һәм сөяк әйберләр эшләүчеләр, күнчеләр һәм чүлмәкчеләр... Металл коючылар мичләрдә тимер, бакыр һәм бронза эретәләр. Тимерчеләр әзер әйберләрдән җир сөрүчегә, сугышчыга яисә хуҗабикәләргә кирәкле булган бөтен нәрсәләрне дә чүкиләр. Бакырчылар бронза һәм бакырдан искиткеч савыт-сабалар эшлиләр.

Зәркәнчеләр алтыннан озын нечкә җепләр сузып чыгарырга өйрәнәләр. Аннан соң алар чыбык-җепләрдән орнамент үрәләр, ә аның өстенә вак алтын яки көмеш шарчыклар ябыштыралар. Искиткеч матур зәркән әйберләр килеп чыга. Еш кына казу эшләре вакытында археологлар йөзекләр, алкалар, беләзекләр һәм көмеш чигә асылмалары эзләп табалар. Болар болгар хатыннарының иң яраткан бизәнү әйберләре була.

Йорт хайваннары сөякләреннән, мамонт тешләреннән сөяк кисүчеләр төрле вак-төякләр – тараклар, тартмачыклар һәм башка әйберләр ясыйлар.

Эшкәртелгән хайван тиресеннән күнчеләр аяк киеме, каешлар, ук кыналары, ат дирбияләре ясыйлар. Рус елъязмаларындагы сүзләргә караганда, барлык болгар сугышчылары да күн итектән йөри.

Чүлмәкчеләр төрле балчык савыт-саба, балалар өчен уенчыклар ясый. Соңрак Болгар дәүләтендә пыяла савыт-сабалар да барлыкка килә. Түгәрәк



*Казылмаларда табылган аучыларның сөяк ук очлары, балыкчы ыргаклары.*



*Тимерчеләрнең хезмәт кораллары.*

диск формасындагы тәрәзә пыялалары җитештерү дә җайга салына.

**Сәүдә.** Оста Болгар һөнәрчеләренең даны еракларга тарала. Балчык савытлар, «болгари» күннәр, зәркән әйберләре күп илләрдә билгеле була.

Болгарларның данын сәүдәгәрләр дә арттыра. Аларны шәһәр базарларында һәм елына ике тапкыр уздырыла торган халыкара ярминкәләрдә очратырга мөмкин була. Товарларның күп һәм төрле булуы сәбәпле, базарларда һәм ярминкәләрдә халык кайнап тора. Анда сугышчылар үзләренә кылычлар һәм көбә киемнәр, зәркәнчеләр үзләре ясыйсы әйберләргә Балтыйк буеннан китерелгән гәрәбә, күнчеләр – кәҗә тиреләрен карыйлар. Бай кешеләр кыйммәтле мехлар, әрмән келәмнәре, Византия парчасын сайлыйлар. Бал һәм чикләвек сатып алучылар да күп була. Коллар үзенә аерым бер товар санала.



*Биләрдә табылган ябалак сурәте төшерелгән җәя пластинасы.*

Илнең географик урыны уңайлы булу сәүдә үсешенә булышлык итә. Идел һәм Чулман елгалары Көнчыгыш Европаның иң зур сәүдә су юлларыннан санала. Болгар җирендә күп санлы кәрван юллары очра-



*Үрдәк сыны коелган алтын чигә алкасы.*



*Көмеш муенса. Болгар. X гасыр.*

ша. Аларның берсе Киевка, башкалары Итилгә, Харәземгә, Багдадка бара. Зур шәһәрләрдә читтән килгән сәүдәгәрләр өчен кәрвансарайлар – кунып чыгу һәм товарлар саклау өчен махсус урыннары булган кунакханәләр төзелә. Дәүләт башлыклары сәүдә үсешенә зур ярдәм итә. Чөнки сәүдә дәүләткә зур табыш алып килгән; читтән кертелгән товарларның уннан бер өлеше дәүләт файдасына түләтелгән.

**Идел-Чулман Болгары Урта гасырларда Көнчыгыш Европаның иң зур дәүләтләреннән санала. Хуҗалыгы шактый алга киткән ил була.**

## БАЙ ШӘҺӘРЛӘР ПАТШАЛЫГЫ

Болгар дәүләте шәһәрләр иле буларак дан тота. XIII гасыр сәяхәтчеләренең берсе, Венгрия монахы Юлиан: «Болгар дәүләте – бай шәһәрләре белән бөек һәм куәтле, көчле патшалык», – дип яза. Биләр, Болгар, Суар, Алабуга һәм Җүкәтау шәһәрләре чит мәмләкәтләргә дә билгеле була.

Урта гасырлар Европасындагы иң зур шәһәрләрнең берсе булып Биләр санала. Үзенең территориясе буенча ул Париждан бер ярым тапкыр, Рим һәм Киевтан ике мәртәбә зуррак була. Рус елъязмаларында аны Бөек шәһәр дип атыйлар. Республикабызның Алексеевск районы Биләр авылы янында бу шәһәрнең калдыклары сакланып калган.

Биләр дәүләтнең башкаласы була. Анда хакимнәр һәм галимнәр, шагыйрьләр һәм дин белгечләре яши. Һәм, Урта гасырларның теләсә кайсы башкаласындагы кебек, аның да төп халкын һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр тәшкил итә.

Болгар иленең башкаласы туфрак өемнәре (валлар) һәм манаралы киң диварлар белән әйләндереп алынган була. Саклану корылмалары Биләрне эчке һәм тышкы шәһәргә аера. Эчке шәһәрдә кирпеч һәм таш биналар күп була. Андый йортларга аксөякләр һәм байлар – дәүләт башлыгына якын кешеләр, югары руханилар, эре феодаллар һәм сәүдәгәрләр хуҗа булалар. Кирмәннең уртасында әмир сарае, аның белән янәшәдә ак таштан Җәмигъ мәчете торган.

Тышкы шәһәр эчке шәһәрдән бик нык аерылып тора. Мондагы гади бүрәнә өйләрдә һөнәрчеләр һәм вак сәүдәгәрләр яши. Биредә һөнәрчеләрнең остаханәләре, металл коючылар һәм тимерчеләр, шулай ук чүлмәкчеләр бистә-бистә булып урнашалар.

Эчке шәһәргә алып керүче капка янында зур кәрвансарай урнашкан була. Читтән килгән сәүдәгәрләр монда үзләренең товарларын куеп торудан тыш, озын юл алдыннан, мунча кереп, ял итеп тә алганнар.

*Болгар* шәһәрендә сәүдәгәрләр гаять күп була. Иделдәге әлегә зур булмаган бу шәһәр сәүдә юллары чатында урнашкан, мондагы күп санлы базарларга ел әйләнәсе бөтен дөньядан сәүдәгәрләр агыла һәм сату-алу эше гөрләп бара.

Биләрдән соң зурлыгы ягыннан икенче урында торган Суар шәһәре шулай ук көчле ныгытмаларга ия була. Тышкы туфрак өемнәре өстенә очлы башлы баганалардан ясалган калын агач дивар утыртыла. Дивар артында тирән сулы чокыр казыла. Аның төбеннән очланган казыклар чыгып тора. Эчке өемнәр өстенә имән диварлар һәм манаралар торгызыла. Шәһәргә куркыныч янаганда, саклаучылар шул манараларга менәләр. Алар дошманга ук, сөңге яудыралар, таш һәм бүрәнәләр ыргыталар, кайнар су һәм кайнар сумала агызалар.

Суарда да кирпечтән салынган йортлар күп була. Шәһәр уртасында алып барылган казу эшләре вакытында археологлар шундый йорт калдыкларының берсенә юлыгалар. Ул гөмбәз түбәле ике катлы бина була. Кояш яктысы йорт эченә сарылы-яшелле түгәрәк пыялалар аша үтеп керә. Биләрдәге байлар йортларындагы сыман, мичнең җылы һавасы идән астыннан үткәрелгән махсус торбалар аша уза.

Гади шәһәр кешеләре, һөнәрчеләр үзләренә агачтан бер катлы йортлар төзиләр һәм шәһәрнең үзәк өлешеннән ерак яшиләр. Сәүдәгәрләр, киресенчә, шәһәр үзәгенә якынрак урнашалар, чөнки монда базар урыны була.

Ә Иделнең сул як ярындагы Болгар шәһәрләре арасында иң әһәмиятлесе – Ашлы. Ул дәүләтнең иң эре бер сәүдә-һөнәр үзәге булып санала. Ашлы шәһәре калдыклары республиканың Тәтеш районындагы Богдашкино авылы янында табыла.

Җүкәтау да Болгар иленең данлыклы шәһәре була. Ул Чулман елгасы ярында (хәзерге Чистай шәһәренең көнбатыш чигендә) урнашкан. Аның урта өлеше өч катлы диварлар белән ныгытылган һәм Чулман елгасының биек ярына утырган була. Каршы якта, үзәнлектә, һөнәрчелек бистәләре урнаша.

X–XI гасырлар чигендә Идел белән Казансу елгасы кушылган урында Казан дип аталган кечкенә крепость – кирмән барлыкка килә. Тиздән ул, шәһәргә әйләнеп, халыкара сәүдә үзәгенә әверелә. Археологик табылдыкларга караганда, Казан Көнбатыш Европа, Урта Азия, Рус, Якын Көнчыгыш илләре белән сәүдә итә.



*Биләрдәге кәрвансарай хәрабәләре.*

Болгар җирендә илледән артык һөнәр, сәүдә, мәдәният үзәкләре булган кечкенә шәһәрләр дә билгеле. Алар арасында иң танылганы – Алабуга шәһәре. Бу шәһәрчекнең үзәгендә, Чулманның уң як ярында, кирмән була. Аның таштан салынган ныгытма-манарасы хәзерге көнгә кадәр сакланган.

## Шәһәр нигә Казан дип аталган? (риваять)

Казан бәкләреннән берәүнең хезмәтчесе булган. Шул хезмәтче казан алып елгага төшкән. Елганың яры бик текә, су алыр өчен уңайсыз була. Ул шундый уңайсыз җирдән су алам дип азапланганда, кулындагы бакыр казанын су төбенә төшереп җибәргән.

Менә шуннан соң бу елга Казан дип аталган икән. Казан елгасы буена корылган шәһәр дә, шул ук исем белән, Казан дип аталган.

## Казан кайнаган урын (риваять)

Бер заманда хан кала корырга булган. «Кайда кала корырга?» – дип кешеләре белән киңәшкән. Берсе әйткән:

– Арбага казан куйыйк, казанга су салыйк, астына ут ягыйк, атларны чаптырып куыйк. Казан кайда кайнап чыкса, шунда кала корырбыз, – дигән.

Шулай иткәннәр дә. Казан хәзерге Казан шәһәре урнашкан урында кайнап чыккан. Шунда кала корганнар да.

## Минем шәһәрем этләргә әләгер (риваять)

Казансуның текә ярында урнашкан Иске Казанда ханның килене булган. Бер көнне ул елгага суга барган. Тулы чиләкләре белән тауга күтәрелгәндә, егылган да суын түккән. Ул шунда ачуланып әйткән: «Тапканнар шәһәр төзергә урынын». Бу турыда ханга җиткергәннәр. Хан киленен чакырып сораган: «Шәһәрне кайда төзергә соң? Әйт миңа!» Моңа килене җавап биргән: «Балыкчыларны ятьмә белән Казансу буйлап җибәр. Шәһәрне алтын балык эләккән җирдә төзергә кирәк».

Хан балыкчыларны җибәргән. Алар бик озак бара торгач, ниһаять, бер алтын балык тотканнар. Ханга бу турыда әйткәннәр. Хан урынны карарга киткән. Хәзер Казан урнашкан урын элек начар булган, чокырлар, баткаклыклардан торган. Өйгә кайткач, килененә әйткән: «Мондый урында ничек шәһәр салырга соң?»

Килене яңадан балыкчыларны ятьмәләре белән җибәрергә кушкан. Хан җибәргән. Балыкчылар янә дә алтын балыкны шул ук урында тотканнар. Бу турыда ханга әйткәннәр. Хан әйткән: «Димәк, Ходай шулай язгандыр! Шәһәрне шунда төзи башларбыз».

Хәзер Кремль урнашкан җирдә еланнар мыжлап торган тирән чокыр булган. Хан килененә әйткән: «Анда еланнар бик күп. Аларны ничектер юк итәргә кирәк, югыйсә алар кешеләрне чагар. Нишләргә икән?» Килене әйткән: «Кышын чокырны салам белән күмәргә, ә язын, еланнар уянгач, саламны яндырырга кирәк. Еланнар янып бетәр». Хан шулай эшләгән дә. Язын саламны еланнары белән яндырганнар, ләкин барысын да түгел. Карт еланнар тирә-якка шуышканнар. Хан, аларны үтерергә дип, батырларын җибәргән. Баһадирлар бөтен еланнарны кырып бетергәннәр, иң карты гына исән калган. Ул үзенә ташланган батырны алтыга өзгәләп ташлаган да каядыр качкан. Бу урында Алты Кутар исемле авыл төзегәннәр.

Еланнарны кырып бетергәч, шәһәр төзи башлаганнар. Хан мәчет төзергә кушкан. Ул эшчеләргә әйткән: «Нигез салганда, сезнең яныгызга кем беренче булып килсә, җиргә шуны терелэй күмегез!»

Төзүчеләр янына хан малае килгән. Алар аны җиргә терелəй күмəргə батырчылык итмəгəннəр, аның урынына эт күмгəннəр. Бу турыда белгəч, хан: «Димəк, минем шəһəрем этлəргə əлəгер», – дигəн.

## БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНЕҢ БАШКА ХАЛЫКЛАР ҺӘМ ИЛЛӘР БЕЛӘН БӘЙЛӘНЕШЕ

**Болгарлар һəм фин-угыр халыклары.** Идел-Чулман Болгары күп иллəр һəм халыклар белəн тыгыз бəйлəнешлəр урнаштыра.

Бəрəнҗəр, барсил, билəр, савир, əсəгел һ.б. кабилəлəрдəн гыйбарəт булган болгарлар, беренче чиратта, үзлəренең якын күршелəре булган фин-угыр халыклары – удмурт, мари, мордваларның борынгы бабалары белəн сəүдə мөнəсəбəтлəрен җайга салалар. Алар, удмурт җирлəрендə аслар һəм бик əйбəт тиеннəр күп булганга, еш кына Ару иленə кыйммəтле җəнлек тирелəре артыннан килгəлилəр. Якын күршелəре белəн сəүдə итү өчен, болгарлар елга буйларында махсус факториялəр – чит җирлəрдə сəүдə бистəлəре ачалар.

Болгарлар, кыйммəтле җəнлек тирелəре эзлəп, хəтта Чулман буйларына һəм Ерак Себергə кадəр барып җиткəннəр. Хəзерге ханты һəм мансиларның борынгы бабалары белəн товар алмашу яисə «телсез» сəүдə алып барылган. Мондый сəүдə вакытында алар, бер-берсен күрмичə, бары бер əйберне икенчесенə генə алыштыралар.

Болгарда башка дин тоткан фин-угыр һ.б. халыкларны дини яктан көчлəү, эзəрлеклəүлəр булмаган, бу халыкларның милли гореф-гадəтлəре, уңай традициялəре хөрмəт ителгəн. Шулай да болгарлар мəҗүси күршелəренə, рухи яктан бəрəкəтле йогынты ясап, көчлəп такмыйча гына ислам диненең асылын төшендергəннəр. Нəтиҗəдə бу халыкларның шактый өлеше ислам динен үз телəге белəн кабул иткəн, төркилəшүгə юл тоткан, болгарлар белəн диндəш буларак үзара тагын да якынайганнар. Фин-угыр халыклары төрки җырларны, болгарлар исə фин-угыр халыклары җырларын бик телəп, яратып башкарганнар, күршелəренең кубыз, сорнай кебек музыка уен кораллларыннан да файдаланганнар.

XII–XIII гасырларда ук Болгар дəүлəтендə яшəүче халыклар арасында үзенчəлекле икетеллелек туа: болгарлар җирле фин-угыр теллəрен уңышлы үзлəштерəлəр, ə фин-угыр халыклары болгар телен əйбəт белəлəр. Бу тугандаш халыклар телендə болгар-татар теленең нигезен тəшкил иткəн меңлəгəн сүзлəрнең хəзерге көнгə кадəр сак-

лануы шул хакта сөйли. Мари телендә, бигрәк тә аның көнчыгыш шивәсендә, өч меңләп, удмурт телендә ике меңләп төрки-татар сүзе бүгенге көндә дә киң кулланыла.

**Болгар иле һәм Рус дәүләте.** Болгар-рус мөнәсәбәтләрендә сәүдә иң мөһим урында тора. Ике ил арасындагы шартнамәләрдә сәүдә мөнәсәбәтләрен киңәйтү турында ассызыклап әйтелә. Руслар мал-туар, тире һәм икмәк, савыт-саба, хайван кыяфәтендә ясалган бронза йозаклар саталар. Рус иленнән мехлар, пыяла муенсалар, беләзекләр, савыт-саба, тимер йозаклар һәм ачкычлар, сөяктән һәм балчыктан ясалган вак-төяк әйберләр кертелә.

Үзара сугышлар да килеп чыккалый. Бәрелешләр, гадәттә, солых килешүләре төзү белән тәмамлана. 985 елгы килешү буенча, болгарлар белән руслар «*таш йөзә башлаганчы, ә колмак батканчы, ягъни мәңгегә*» тынычлыкта яшәргә вәгъдә бирәләр. Тагын бер әһәмиятле килешү Болгар дәүләте һәм Владимир-Суздаль кенәзлеге арасында 1229 елда төзелә. Шул вакытта алар уртак бәла – монголлар һөҗүме – каршында дуслык мөнәсәбәтләрен ныгыталар. Ике як та әсирләр алмашу, үз территорияләре буенча сәүдәгәрләрнең ирекле күчеп йөрүе турында килешү төзиләр.

Идел-Чулман Болгары һәм Рус дәүләте арасындагы бәйләнешләр, әлбәттә, сәүдә мөнәсәбәтләре белән генә чикләнми. Тарихта шундый мәгълүматлар да сакланган: рус кенәзләре Владимир һәм Андрей Боголюбский, еш кына күршеләренә һөҗүм итеп торуларына



*Биләр казылмаларыннан балтика гәрәбәсе.*



*Болгардагы казылмалар арасында табылган рус әйберләре.*



*Биләр казылмаларыннан Иран касәсе.*

карамастан, үзләренә болгар кызларын кәләш итеп алалар.

**Болгар һәм Шәрык илләре**. Ислам динен кабул иткәннән соң, Болгар дәүләтенең Көнчыгыш илләр белән бәйләнеше көчәя. Болгар дәүләте Ислам дөньясының бер өлешенә әверелә. Болгар әмирләре мөселман дәүләтләренең башлыклары белән үзара мөнәсәбәтләрне ныгыталар, бүләкләр алмашалар. Сәүдә бәйләнешләре бик киң җәелә. Халык Мәккәгә барып хаҗ кыла башлый.

Көньякта Болгар дәүләтенең төп сәүдә партнеры Хәзәр каганлыгы була. Хәзәрләргә бәйлелектән чыккач, болгарларны һәм хәзәрләрне үзара сәүдә мөнәсәбәтләре генә бәйли.

Болгарлар шулай ук Иран, Урта Азия, Византия шәһәрләре белән, Балтыйк, Скандинавия илләре, Һиндстан белән сәүдә итәләр.

Болгарларның Идел һәм Урал буе төркиләре, Урта Азия һәм Кавказ халыклары белән дә икътисади һәм мәдәни элемтәләре дәвам итә. Телләр якынлыгы, диннең һәм, гомумән, мәдәни традицияләрнең уртаклыгы бу багланышларга уңай йогынты ясый.

**Идел-Чулман Болгары һәм Көнбатыш Европа илләре.** Идел-Чулман болгарлары белән Дунай болгарлары X гасырга кадәр нык аралашып яшәгәннәр. Ике халык та төркиләрнең борынгы дине – тәңречелекне тоткан, язганда рун алфавитын кулланган. Әмма Дунай болгарларында христиан (православие), ә Идел болгарларында исә ислам дине кабул ителгәч, сәяси һәм мәдәни багланышлар сүлпәнәя.

Болгар шәһәрләрендә табылган чех акчасы, Балтыйк һәм Скандинавия илләреннән китерелгән гәрәбә, сугыш кораллары, бизәнү әйберләре сәүдә юлы белән килгән дип уйларга нигез бар.

Болгарлар ерак төбәкләрдән килгән чит халык вәкилләрен һәрчак җылы кабул итәләр, аларга икътисади һәм рухи яктан ярдәм кулы сузалар. X гасырда венгр монахы Юлиан, бер мөселман сәүдәгәренең булышчысы сыйфатында, Биләр шәһәрендә була. Ул биредә болгар кешесенә кияүгә чыккан «венгр хатынын» очрата. Аның ярдәмендә монах Чулман суы буенда мәҗүси кардәшләрен эзләп таба. Юлиан болгарлар белән дустанә мөнәсәбәттә яшәүче кабиләдәшләре турында кызыклы мәгълүматлар язып калдыра. Алар Себер якла-

рыннан чыгып, Урта Идел аша Дунай буйларына күчеп утырган мадьярларның (венгрларның) Болгар илендә төпләнеп калган бер өлеше булып чыкканнар һәм әле һаман ярым күчмә тормыш алып барганнар. Җир эшкәртмәгәннәр, әмма бик күп терлек асраганнар. Атлары, яхшы сыйфатлы сугыш кораллары күп булган, күрше кабиләләр белән бәрелешләр вакытында тиңдәшсез батырлыклар күрсәткәннәр.

**Шулай итеп, Болгар дәүләтен Идел буе, Төньяк халыклары, Борынгы Рус, Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре белән киң һәм күпкырлы элемтәләр бәйләп торган.**



*Казанда табылган Вацлав тәнкәсе.*

## Белемле кеше (риваять)

«Болгар» сүзенең мәгънәсе – белемле кеше. Эш шунда ки, безгә Бохарадан мөселман сәүдәгәрләреннән берәү килгән, ә ул тыйб (медицина) гыйлемен, шәригать законнарын яхшы белгән кеше булган. Шул чакта патша да, аның хатыны да бик каты авырып китәләр. Аларны гамәлдә йөргән барлык дарулар белән дәвалап караганнар. Әмма авырулары көчәя генә барган, алар «үлеп китмәгәек» дип курка башлаганнар. Шул чакта теге мөселман әйткән:

– Әгәр дә мин сезне дәваласам, минем динне кабул итәрсезме? – дигән.

Икесе дә:

– Әйе, – дигәннәр.

Ул боларны дәвалаган, патша белән хатыны терелгәннәр һәм ислам кабул иткәннәр. Шулай ук алар иленең халкы да ислам динен тота башлаган. Шуннан боларга зур гаскәр белән Хәзәр патшасы килеп сугыш ачкан:

– Нигә минем әмеремнән башка бу динне кабул иттегез? – дигән. Шул чакта теге мөселман әйткән:

– Курыкмагыз, «Аллаһе әкбәр» дип кычкырыгыз, – дигән.

Һәм алар: «Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр!» – дип кычкырып, Хәзәр патшасы белән сугышканнар һәм аның гаскәрен качып китәргә мәҗбүр иткәннәр.

Бу хәлдән соң Хәзәр патшасы алар белән солых төзегән, диннәрен кабул иткән һәм әйткән:

– Сугышчыларымны һәлак итеп, мине качарга мәҗбүр иткән күк атлы, алып гәүдәле ирләр күрдем, – дигән.

Дин әһеле аларга:

– Бу ирләр – Аллаһе Тәгалә гаскәре, – дигән.

Белемле кеше аларда «беләр» дип атала, шуның өчен бу илне «Беләр» дигәннәр. Шуны, гарәп теле аһәңенә яраклаштырып, «Болгар» дип йөртә башлаганнар.

## ИДЕЛ-ЧУЛМАН БОЛГАРЫ ХАЛКЫНЫҢ МӘДӘНИЯТЕ

Идел-Чулман Болгары тарафыннан ислам дине кабул ителүнең тагын бер әһәмиятле ягы була. Болгарлар өчен шул заманда Көнчыгышның алдынгы мәдәнияте булган мөселман мәдәниятенә юл ачыла. Мәгариф, әдәбият, фән үсешенә көчле этәргеч бирелә.

**Борынгы бабаларыбызның язуы.** Башта рун язуын кулланган болгарлар, исламны кабул итү белән, гарәп әлифбасына нигезләнгән язуга күчәләр.

Вакытлар үткәч, гарәп язуы киң кулланыла башлый. Аның ярдәмендә күп санлы һәйкәлләргә, зәркән эшләнмәләренә, көндәлек кулланылыштагы әйберләргә язулар төшерелә. Әлеге язмаларның күп кенә үрнәкләре каллиграфия – матур һәм төзек язу сәнгате әсәре булып тора.

Күбрәк каен тузына һәм балавыз белән каплатылган такталарга сөяктән ясалган таяклар белән язганнар. Шулай ук кәгазь дә кулланылышка кергән. Аны Сәмәркандтан кайтарганнар. Кәгазьгә язу карасы һәм каурый каләм белән язганнар.

Кульязма китапларны бик озак һәм тәфсилләп эшләгәннәр, шуңа күрә алар кыйммәт торган. Аларның һәрберсен махсус тышлыкларда кадерләп саклаганнар.

**Болгарда мәгариф һәм фән үсеше.** Гарәп язуын башлангыч дини белемле мәктәпләрдә үзләштергәннәр. Болгар шәһәрләре һәм авылларында төзелгән мәчетләр каршында башлангыч мәктәпләр эшләгән. Югары белемне болгар яшүсмерләре Урта Азия галимнәреннән алганнар.

Гарәп телен яхшы белү шул заманның күренекле Көнчыгыш галимнәре һәм шагыйрьләре хезмәтләре белән танышуга юл ача,




*Ырк битиг. Борынгы төркиләрнең юрау китабы. X гасыр.*

бу исә Болгарда әдәбият һәм төрле фәннәр үсешенә зур йогынты ясый. Болгар галимнәренең хезмәтләре, әдәби әсәрләре көнчыгыш илләрендә дә танылу таба.

Болгарлар математика һәм астрономия, химия һәм медицина, география һәм тарих өлкәсендә зур гына уңышларга ирешәләр. Мәсәлән, Биләр шәһәрлеге территориясендә археологлар химик тәҗрибәләр үткәрү өчен ясалган махсус пыяла савытлар таптылар.



*Гарәп телендәге язмалы Болгар йозагы.*



*Химик тәҗрибәләр үткәрү өчен пыяла савыт.*



*Сөяк һәм металлдан ясалган язу кораллары, балчыктан эшләнгән кара савытлары.*

Язма чыганакларда Болгар шәһәреннән еракта бер болгарның астрономик күзәтүләр алып баруы турындагы мәгълүмат сакланып калган.

Көнчыгыш илләрендә Таҗетдин әл-Болгариның «Агуланудан иң яхшы дарулар» дигән хезмәте киң тарала. Шагыйрьләр үз шигырьләрендә Болгар галиме, табиб Хаҗи Болгарига дан җырлыйлар. Болгар казые Йагкуб ибне Ногман «Болгар тарихы» дигән китап яза. Дини хезмәтләр дә киң тарала.

**Әдәбият.** Идел-Чулман Болгарында матур әдәбият һәм халык иҗатының поэтик төре зур үсеш ала. Шул чорда язылган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы («Йосыф китабы») иң бөек әсәрләрнең берсе булып тора.

Шагыйрь Кол Гали XII гасыр ахыры – XIII гасыр башында Биләрдә яши. Атаклы поэмасын да ул биредә яза. Анда ул гадел хөкемдар һәм идеаль дәүләт образын иҗат итә. Хөкемдар, аның уенча, акыллы, гадел, әхлакый яктан керсез, тел тидермәслек булырга, ә дәүләт исә халыкның тыныч, бәхетле тормышын тәэмин итәргә тиеш. Бәхетне Кол Гали тугрылыклы һәм чиста мәхәббәттән, нык һәм дус гаиләдән башка күз алдына китерә алмый.



Урта гасырлар татар поэзиясенең иң популяр әсәре булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы бүген дә укучыларда зур кызыксыну уята.

**Болгарда мәдәният югары дәрәҗәдәге үсешкә ирешә. Ул Көнчыгыш мәдәниятенең бер**

*Кол Гали һәйкәле. Авторлар А.Балашов, А.Миңнулина, Р.Нургалиева.*

**өлеше буларак үсә. Урта гасырда болгарлар Европада чәчәк аткан цивилизацияләрнең берсен төзиләр.**

## Кол Гали (XII гасыр аҳыры – XIII гасыр). Кыйссаи Йосыф

Фазлы белән халикъ аны итте барлы,
Хөкеме дөрес, гакълы камил, үзе гарьле,
Дине бөтен, гыйльме төгәл, йөзе нурлы, –
Йөзен күргән җанын фида кылыр имди. [...]
[...] Беренчедән – буе зифа, сылу үзе,
Икенчедән – күрекле һәм нурлы йөзе,
Өченчедән – теле бик саф, тугъры сүзе, –
Житмеш ике телне тәмам белер имди!
Дүртенчедән – кешелекле һәм шәфкатьле,
Бишенчедән – алып батырдай йөрәкле,
Алтынчыдан – бик күпләрдән ул куәтле,
Көч-куәте кырык ирдән артык имди.
Җиденчедән – дине бөтен, диянәтле,
Сигезенче – хыянәтсез, әманәтле,
Тугызынчы – холкы гүзәл, теле татлы,
Унынчыдан – пәйгамбәрләр нәсле имди [...].
Бу кыйссаны укыр гакълы булган кеше,
Тыңлаучының күңле эрер, агар яше,
Юкка чыгар гөнаһларының һәммәсе, –
Рәхман аңа рәхим-шәфкать кылыр имди.
[...] «Бу шаһ, шиксез, гадел ирдер,
Безнең хәлнең зәгыйфьлеген ул кыладыр, –
Гадел кеше – гарибләрне сөяр имди». [...]
Галим кеше бу нәзымны сөйләп бирсә,
Гакыллылар колак салып тыңлап торса,
[...] Гәүһәрне таш дию белән ул – таш булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен белә алмас,
Бу нәзымның кадрен ары ахмак белмәс,
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер инде.[...]

## Туйбикә мәдрәсәсе (риваять)

Шәһре Болгарда бик галим бер абыстай яшәгән. Аның исеме Туйбикә булган. Ул бик данлыклы хатын икән. Шәһре Болгарның олысы-кечесе Туйбикә абыстайны беләләр, һәрбер

эшләрендә аңар, «ана» дип, киңәш итәләр икән. Туйбикә абыстайны Шәһре Болгар ханы да олылый икән.

Туйбикә дип бу абыстай шуның өчен аталган, ди: ул туйларда була торган үпкә-сапкаларны, бозылышу, аерылышуларны бетерә, кыз белән егет арасын килештерә икән, һәркемне үгет-нәсыйхәт белән димли, дуслаштыра икән. Туй бит бер дә үпкәсез булмый, диләр, менә бу Туйбикә абыстай шул үпкәләрне бетерә икән.

Туйбикә абыстай үзе хан нәселеннән булган, ди. Шәһре Болгарда аның бик зур кызлар мәдрәсәсе булган икән. Анда төрле илләрдән бик күп кызлар, килеп, зур галим булып чыкканчы укый торган булганнар, ди. Ул мәдрәсәне «Алтмыш алты абыстай мәдрәсәсе» дип йөрткәннәр, ди. Аны «Алтмыш алты абыстай мәдрәсәсе» дип шуның өчен атаганнар, ди: бу укып йөрүче абыстайлар изге абыстайлар булганнар икән. Алар үзләре Биләр шәһәреннән Шәһре Болгарга барып сабак укыйлар икән.


Бу алтмыш алты абыстай иртә намазның сөннәтен – Биләр шәһәрендә, фарызын Шәһре Болгарда укыйлар икән. Болар сәхабәләрнең шәкертләре булганнар, ди. Боларның кулларында тимер таяклар булган, ди. Биләрдән Шәһре Болгарга сабак укып йөри-йөри, аларның кулларындагы тимер таяклары ашалып, кыскарып беткән икән. Болар Биләрдән Янбактыга, аннан Ширбәтлегә, аннан Шәһре Болгарга баралар икән.

Туйбикә абыстайның әмере белән, бу алтмыш алты абыстай, алтмыш алты якка таралып, күп халыкны хак юлга күндергәннәр, ди.

## ТОРАК һӘМ КӨНКҮРЕШ

**Күчмә халыклар тормышы.** Борынгы бабаларыбыз тормышларының күпчелек вакытын гел хәрәкәттә булып, төрле җирләргә күченеп йөреп үткәргәннәр. Аларның күчмә халыклар дип аталулары да шуның белән бәйле.

Күчмә халыклар тормышын сурәтләгән язма чыганакларда һәм тарихи әсәрләрнең кайберләрендә алар кыю, курку белмәс, бер-берсенә тугрылыклы күчмә терлекчеләр, батыр сугышчылар, икенчеләрендә исә, киресенчә, басып алучылар, вәхшиләр, башка халыкларны үзләренә буйсындыручылар итеп сурәтләнәләр.



*Тирмәне жыю.*

Төркиләрдә хуҗалыкның төп нигезен терлекчелек тәшкил иткән. Алар бик күп санда ат, үгез, дөя тотканнар, шулай ук сарык һәм кәҗә асраганнар. Терлекләр ел әйләнәсе көтүлектә йөргән. Килеп төпләнгән урыннарында хайваннарга туклану өчен үлән беткәч, кешеләр икенче җиргә күченеп киткәннәр, шулай итеп, ел әйләнәсенә ике-өч урын алыштырганнар. Мондый тормышта яшәр өчен киңлек, иркенлек кирәк булган – алар яңа җирләрне үзләштергәннәр. Даими рәвештә күчеп йөрү табигатьне саклау чарасы да булып торган. Чөнки гел бер урында торган очракта дала җирләре үзләренең уңдырышлылыгын югалта, анда үсемлекләр үсми башлый. Ә төркиләрнең күченеп йөрүләре нәтиҗәсендә, җирнең бу сыйфаты юкка чыкмый, киресенчә, кабат әйләнеп килгәндә, үләннәр куерак булып чыга.

**Борынгы төркиләрнең йортлары. Тирмәләр.** Күчмә тормышта яшәү чорында төрки бабаларыбызның тору урыннары киез тирмәләрдән гыйбарәт булган.

Тирмәнең урнашуы һәм аның эчке төзелеше бик үзенчәлекле. Тирмәне урнаштырганда, аның ишеген көнчыгышка каратып куйганнар. Болай кую тәүлекнең кайсы вакыты икәнен ачыкларга мөмкинлек биргән. Ә җылы көннәрдә ул яктылык чыганагы булып та хезмәт иткән. Чөнки тирмәләрдә тәрәзәләр булмаган һәм көндез, яктылык керсен өчен, ишекне ачып куйганнар.

Торакның эчке төзелешенә килгәндә, ул шартлы рәвештә икегә бүленгән. Ишектән кергәч, сул як – «ирләр», ә уң як – «хатын-кызлар»



*Тирмәнең эчке күренеше.*

ягы саналган. Кайбер тирмәләрдә, «ирләр» ягы белән «хатыннар» ягын аеру өчен, тукымадан чаршаулар элеп куйганнар. Көнкүреш кирәк-яраклары, сугыш кораллары һәм ирләрнең башка шәхси әйберләре үз якларында, ә савыт-саба, хатын-кызлар һәм балалар әйберләре «хатыннар» ягында булган. Ашарга яки башка сәбәп белән утырган вакытта да шушы ук бүленеш саклаган.

Тирмәнең уртасында учак якканнар. Төтене тышка чыксын өчен, тирмә түбәсенең учак турысына төннек ясаганнар. Тирмәнең идәннәренә киез көрпәләр (җәймә) һәм хайван тиреләре җәелгән, стеналары йон яки киез паласлар, келәмнәр, төрле тукымалар белән бизәлгән. Дәрәҗәле һәм хәлле гаиләләрнең тирмәләрендәге тукымалар ефәктән булган.

Тирмәнең төньягы иң дәрәҗәле урын булып саналган. Анда гаиләнең истәлекле әйберләре сакланган, өлкәннәрне һәм кадерле кунакларны шунда урнаштырганнар. Гадәттә, йорт хуҗалары, аякларын бөкләп, идәнгә утырганнар, ә кунакларга кечерәк кенә утыргычлар яки киез миндәрләр, җәймәләр бирелгән. Кайбер тирмәләрдә кечкенә генә өстәлләр дә куелган.

Тирмәдә һәм гаиләдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре дә яшәп килгән. Аларны безнең бабаларыбыз кечкенәдән үк белеп үскәннәр һәм үтәргә тырышканнар. Бу кагыйдәләрне бозу әдәпсезлек саналган, ә кайвакытта бәхетсезлек билгесе булган. Мәсәлән, тирмәгә кергәндә, бусагага басарга яки аңа утырырга ярамаган. Аңа баскан кеше дошман дип, йортка явыз ниятләр белән килгән дип саналган. Учакка су сибәргә, төкерергә, аның аркылы атлап чыгарга, утка очлы әйберләр

белән кагылырга, чүп ташларга ярамаган. Төркиләрдәге бу кагыйдәләр учакка хөрмәт тәрбияләгән. Шулай ук учактан ут алып чыгарга рөхсәт ителмәгән. Бу очракта «йорттан» бәхет китә дип уйлаганнар.



*Тукымалар белән бизәлгән йорт күренеше.*

**Утрак тормышка күчү. Җир һәм агач йортлар.** Төркиләр терлекчелек белән генә түгел, ә хуҗалыкның башка төрләре белән дә шөгыльләнә башлагач, аларның яшәү шартлары да үзгәрә. Күбесе күчмә тормыштан утрак тормышка күчә башлый. Хәзер инде аларны тирмәләр генә канәгатьләндереп калмый, яңа шартларга туры килә торган, утрак тормыш өчен җайлашкан торак кирәк була. Алар, агач яки камыш кулланып, йортлар төзи башлыйлар. Бу яңа төр йортларны җир йорт дип атыйлар. Чөнки аларны бер метр тирәнлеккә җирне казып төшеп салганнар. Өй алдыннан ишеккә таба ташлар һәм ботаклар белән ныгытылган җир баскычлар төшкән. Агачтан эшләнгән яңакка, ишекнең киңлеге бер метрга кадәр булган очракта – агач ишек, ә аннан артса, хайван тиресе яки киез япма эленгән. Ишек каршында махсус баганаларда сәндерә, өйнең ян-як стеналарына сәкеләр куелган. Җир идән булган. Ул тал чыбыкларыннан үрелгән чыпта белән капланган. Аның өстенә киез яки башка өслек ябылган. Йорт кирәк-яраклары стенадагы махсус киштәләрдә саклаган. Өйне яктыртыр өчен балчыктан эшләнгән май лампалары кулланылган. Мондый йортларны еш җилләтергә һәм еш җыештырып торырга кирәк булган. Чөнки җир идән һәм май лампалары тузан, корым чыгарган.

Гомумән алганда, безнең борынгы бабаларыбыз чисталыкны бик яратканнар. Алар йортларны гына түгел, ишегалларын һәм урамнарны да чиста итеп тотканнар. Урамда чүп ташларга, түкәргә ярамаган. Әгәр кеше түкәргә мәҗбүр булса, аны туфрак белән күмеп куярга тиеш булган.

Акрынлап йортларны имән һәм нарат бүрәнәләрдән сала башлаганнар. Идәннәр агачтан була. Байлар идәннәренә палас, ә ярлылар киез җәймә яки чыпта җәйгәннәр. Игенчелек белән шөгыльләнгән болгарлар, ашлык саклау өчен идән астында махсус баз ясаганнар. Һәрбер хуҗалыкта диярлек, ашлыкны тарттырыр өчен кул тегермәне

булган. Тегермәннән чыккан оннан ипи пешергәннәр. Алар бар эшне дә үз тырышлыклары белән эшләгәннәр, үзләре җитештергән әйберләрне кулланганнар. Ирләр икмәк үстергән, хайван караган, йорт җиһазлары, көнкүреш әйберләре ясаган, ә хатын-кызлар бала караганнар, ашарга әзерләп, кием тегеп, йорт эшләрен эшләп торганнар.



*Хәзәр чүлмәге.*

Төркиләр чорындагы өй эчен ике өлешкә бүлү болгарларда да сакланган. Ләкин ул хәзер мич турысыннан түр һәм почмак якларга бүленгән. Бу чордагы йортларның җиһазлану һәм бизәлешләре бик гади булган. Йортның төп өлешен түр як алып торган. Өйдә иң кирәкле әйбер булып сәкеләр хезмәт иткән. Алар хәзерге замандагы урындыкларны, караватларны һәм өстәлләрне алыштырганнар. Төнлә сәкедә йоклаганнар, көндез урын-җирләрне сәкенең бер почмагына җыеп куеп, шунда утырганнар һәм ашаганнар. Кайбер кешеләрдә өстәлләр дә булган. Алар кырый стенага яки ике тәрәзә арасына куелган. Ул чорда өстәлләр утырып ашар өчен түгел, ә чиста савыт-сабаны саклар өчен файдаланылган.



*Турсык. Фарсы миниатюрасы.*

Бәйрәмнәрдә кия торган киемнәрне һәм бизәнү әйберләрен агач сандыкларда саклаганнар. Алар, гадәттә, мич янына куелган. Өйгә кергән чит кешеләр шул сандык өстенә утырганнар.

Почмак якта шулай ук сәкеләр булган. Алар көндез аш-су әзерләү урыны, ә төнлә

караваt булып хезмәт иткәннәр. Өйнең бу ягы «хатыннар» ягы булып саналган. Анда йорттагы хатын-кызлар һәм балалар гына керә алган, чит-ят кешеләргә керергә рөхсәт ителмәгән. Ирләрдән бу бүлмәгә әти кеше, ә чит кешеләрдән, аерым кагыйдәләрне саклаган хәлдә, дәвалаучылар һәм Коръән укучылар гына кертелгән.

Өй эчен бизәү, матурлау һәм әйберләрне ябып кую өчен бизәкле тукымалар кулланылган. Мич өстендәге матчага озын чаршау элгәннәр. Чит кеше булганда, аны ябып куйганнар, ә өйдә гаилә әгъзалары гына булган вакытта чаршау ачык торган. Ул почмак якны ябык тоту өчен дә кулланылган.

**Савыт-саба.** Бу заман кешеләре, нигездә, агач һәм балчык савыт-сабалардан файдаланганнар, хәллерәк гаиләләрдә тимердән ясалган савыт-сабалар да булган. Болгарларның күбесе агач һәм балчык савытларны үзләре ясаган. Ләкин һөнәрчелек киң таралу белән, савыт-саба җитештерә торган остаханәләр ачылган. Монда савытларны чүлмәкче станогында балчыктан ясаганнар. Шуңа күрә алар шома һәм дөрес формалы булганнар. Мондый савытлар төрле бизәкләр белән бизәлгән. Чүлмәк ясаучыларны зур шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да очратырга мөмкин булган.

**Илтәбәр сараенда.** Дәүләт башлыгы илтәбәр ничек яшәгән соң? Ярымкүчмә тормыш алып барганда, хакимнең кыш көне яшәү өчен сарае, ә җәй торыр өчен тирмәсе булган.

Аның сарае үзенең зурлыгы һәм эчке гүзәллеге белән башкаларныкыннан нык аерылып торган. Йортта берничә бүлмә, шул исәптән, тәхет залы да булган. Бу залның түрендә грек чатмасы белән капланган күз явын алырлык хан тәхете торган. Зур тантаналар вакытында ханбикә һәм иң кадерле кунаклар тәхетнең сул ягына утырганнар. Чөнки сул як, йөрәк ягы булганлыктан, дәрәҗәле урын дип исәпләнгән. Тәхетнең уң ягына дәүләтнең кул астындагы кабилә башлыклары утырган. Алар, тәхет залына кергән вакытта, хөрмәт йөзеннән, баш киемнәрен салып һәм тезләнеп, ханны сәламләргә тиеш булганнар.

Хаким кунаклар җыйганда үтәлә торган бик кызыклы бер гадәт булган. Бәйрәмнең башында иң элек кечерәк кенә бер өстәл чыгарылган. Аны хаким алдына куйганнар, шуннан соң өстәл өстенә кыздырылган иттән төрле ризыклар куелган. Хаким аларны кисеп башта үзе авыз иткән, аннан соң туралган кисәкләрне, чират буенча, кунакларга биргән. Ул ризыкны кемгә бирә, шул кеше алдына өстәл куеп, ризыклар чыгарганнар. Хаким кулыннан ит кисәге алмаган кеше ашарга керешергә тиеш булмаган.

Мәҗлесләрдә болгарларның ашау-эчү вакыты бик озак дәвам иткән. Алар анда җырлар җырлаганнар, төрле музыка коралларында уйнаганнар, тапкыр сүзләр әйтешкәннәр, шигырьләр сөйләгәннәр.

Әгәр шәһәрдә берәр кеше бәйрәм үткәрергә уйлый икән, ул илтәбәргә билгеле бер күләмдә бал китерергә тиеш булган. Балның күләме бәйрәмгә чакырылачак кеше санына карап билгеләнгән. Бу гадәт, әлбәттә, бай кешеләргә караган.

**Шулай итеп, безнең борынгы бабаларыбыз, нинди шартларда яшәүләренә карамастан, матурлыкны, чисталыкны яратканнар. Гасырлар дәвамында үзләренең тормышларын тулыландырырга һәм камилләштерергә тырышканнар.**

## АРХИТЕКТУРА


**Иң борынгы кешеләрнең торулыклары.** *Архитектура* сүзе латин теленнән алынган, ул «биналар төзүне проектлаштыру, салу һәм нәфис итеп бизәү сәнгате» дигәнне аңлата. Төзү сәнгатенең башлангычлары борынгы дәверләргә үк барып тоташа, чөнки кешеләргә тормыш алып бару өчен сыену урыны – торак кирәк була.

Археологлар, борынгы кешеләрнең торулыкларын (яшәү урыннарын) тикшереп, төрле йорт-бина хәрабәләренә дә тап булалар. Аларны һәрьяклап өйрәнеп, безгә шул чорның архитектура сәнгате үрнәкләре турында кызыклы һәм кыйммәтле мәгълүматлар җиткерәләр.

Безнең якларда яшәгән иң борынгы кешеләрнең торулыклары Татарстанның Тәтеш, Кама Тамагы, Апас, Спас, Минзәлә һ.б. районнарында, Казан шәһәре тирәсендә табылган. Бу җирләргә моннан 40–100 мең еллар элек килеп урнашкан кешеләр үзләре аулый торган киек-җанвар, хайван көтүләре артыннан күченеп йөргәннәр. Шуңа күрә аларның даими яшәү урыннары да булмаган. Бу чор кешеләре куыш-шалашларда, мәгарәләрдә яшәгән.

Моннан 7–10 мең еллар элек яшәгән төрле кабиләләр акрынлап утрак тормышка күчә башлаганнар. Агач сапка беркетелгән таш балталарга ия булган кешеләр, ниһаять, агач йортлар салырга өйрәнгәннәр. Апас районының Кабык Күпер авылы янындагы борынгы торулыкны казыганда, археологлар шундый йортларның берсенә тап булалар. Ул – агач-бүрәнәләрдән төзелгән зур гына шалашсыман корылма. Аның түбәсен уртага куелган баганалар тотып тора.

Торакның эчендә азык әзерләү, яктырту һәм җылыту өчен ике учак ягылган.



*Борынгы аучыларның йорты. Реконструкция.*

**Хәзерге Татарстан төбәгендә яшәгән кабиләләрдә торак төзү.** Хәзерге Татарстан җирендә Волосово, Абашево, Баланово, Казан яны, Ананьино, Имәнкискә кабиләләре яшәгән вакытларда йортлар салу эше камилләшә бара. Волосово кешеләре, мәсәлән, аерым ыруг төркемнәре өчен тораклар сала башлыйлар. Аларның торулыклары турыпочмаклы берничә җир йорттан торган һәм үзара аралыклар белән тоташтырылган. Баланово кешеләре исә бүрәнәләрдән салынган йортларда яшәгәннәр. Башта алар тирән итеп нигез чокыры казыганнар һәм шуңа агач бура төшергәннәр. Шуннан соң гына өйнең өске өлешен төзеп бетергәннәр. Безнең якларда мондый ысул белән йорт салуны беренчеләрдән булып Баланово төзүчеләре керткәннәр дә инде. Башка кабиләләр кысрыклый башлагач, балановолылар үзләренең торулыкларын урлар, чокырлар, казык читәннәр белән уратып ала башлаганнар.

Казан яны кабиләләре торак төзүгә кайбер үзгәрешләр кертәләр. Йортлар салганда нигез чокырын тирән казымыйлар башлыйлар, шуңа күрә аның зур өлеше җир өстендә кала. Ул ике яклы итеп эшләнә, түбәсе ике кыеклы яисә гөмбәз рәвешендә




*Ярымҗир йорт. Реконструкция.*

була. Торак башка хуҗалык корылмаларыннан, бигрәк тә терлек абзарларыннан аерым тора. Йортлар бер яки ике рәт итеп урнаштырыла. Авылның уртасында изге урын – гыйбадәтханә дә төзелә.

Ананьино кабиләләрендә өйләрне җир өстенә салу гадәткә керә. Аларның йортлары ике төрдә була. Беренчесе – горизонталь итеп салынган йортлар. Мондый өйләр Ананьино кабиләләренең Идел буендагы авылларында очрый. Икенче төр йортларның бүрәнәләре вертикаль куелып салынган. Мондый йортларны Чулман буенда яшәгән Ананьино кешеләре төзегән. Ананьинолыларның авыл-шәһәрчекләре зур елгаларның текә ярларында, елгалар һәм тирән чокырлар белән әйләндереп алынган борыннарда урнашкан. Монда бары тик ачык кыр ягыннан гына кереп булган, әмма ул як та читән казыклар һәм икешәр метрга кадәр тирәнлектәге канаулар белән ныгытылган.

Шулай итеп, Идел-Урал төбәгендә яшәгән бик борынгы кешеләр җир, ярымҗир йортларда, бүрәнәләрдән салынган өйләрдә торганнар, төзелеш сәнгатендә үзләренең белем-күнекмәләрен һәм осталыкларын камилләштерә барганнар.

**Һуннарда бина төзү сәнгате.** Моннан 2–3 мең еллар элек Евразия далаларында яшәгән иң борынгы төрки бабаларыбыз һуннарның күпчелеге мал-туар асраучылык белән көн күргән. Күчмә тормыш алып барганлыктан, аларның әле даими яшәү урыннары да булмаган. Алар терлекләрне бер җәйләүдән икенчесенә куып йөрткәндә тиз генә сүтеп-җыела торган тирмәләрдә яшәгән. Соңгылары агач колгалардан җыелган һәм киез белән капланган йортлар булган. Аларның түбәләре конуссыман һәм ярымшар (гөмбәз) рәвешендә ясалган. Соңрак, инде утрак тормышка күчеп, авыл һәм шәһәрләрдә яши башлагач та, бабаларыбыз үткәннәрне онытып бетермәгәннәр: җәйләрен тирмәләрдә үткәрә торган булганнар.



*Борынгы төркиләр ныгытмасы. VII–IX гасырлар. Реконструкция.*

Һун бабаларыбызның бер өлеше борынгыдан ук утрак тормышта яшәгән. Археологлар Байкал күле буенда, Улан-Удэ шәһәреннән ерак булмаган Иволга елгасы янында аларның зур гына каласын казып тикшергәннәр. Ул 5 рәт ур һәм тирән канау белән әйләндереп алынган. Анда төтен каналлары, җылыткыч системалы тораклар, бөртекле ашлык саклау урыннары, азык-төлек саклана торган базлар табылган. Шулай ук башкала булып торган Лунчэнь, Дайлин кебек шәһәрләрдә дә гыйбадәтханәләр, хакимнәр торган йортлар, башка җәмәгать биналары булган.


**Болгар архитектурасы.** Бөек Болгардагы Фанәгүр, Хәзәр каганлыгындагы Бәләнҗәр, Сәмәндәр, Итил кебек шәһәрләр дә үзләренең зурлыгы, төзеклеге һәм ныклыгы белән билгеле булган. Зур һәм мәһабәт сарайлар, җәмигъ мәчетләре, мәктәп-мәдрәсәләр, таштан һәм кирпечтән эшләнгән биек һәм калын диварлар, ярымтүгәрәк манаралар бу дәүләтләрнең көч-кодрәтен, төрки чордагы архитектура сәнгатенең шактый колачлы булуын күрсәтеп тора.

Болгар кабиләләре без яшәгән төбәкләргә VIII гасыр урталарында килеп урнашалар. Баштагы чорларда аларда күчмә тормыш йолалары өстенлек итә. Болгарлар, кышын салкыннан сакланырлык агач йортларда яшәсәләр дә, җәй көне җәйләүгә чыгып, тирмәләрдә яшәүне артык күрәләр. Шуңа күрә болгарларның Идел, Чулман буйларында (шәһәрләр салганчы) яшәгән урыннарын табуы кыен.

IX гасырларда болгар кабиләләрендә ыруглар җәмгыятенә хас булган күмәк эшләү, күмәк яшәү мөнәсәбәтләре таркала башлый. Ярым күчмә тормыш белән яшәгән болгар кабиләләре ныклы утрак тормышка күчә баралар. Беренче авыллар, шәһәрләр барлыкка килә. Акрынлап архитектура үсә башлый, төзү эше колач җәя. Кирпечтән һәм ак таштан сарайлар, мәчетләр, җәмәгать мунчалары, хәтта торак йортлар да салалар. Ләкин корылмаларның күпчелек өлеше агачтан була. Шул ук вакытта балчык сылап эшләнгән һәм яртылаш җиргә иңгән өйләрдә дә көн күрәләр.

Болгар илендә хәрби ныгытмалар төзүгә аеруча зур игътибар бирелә. Шәһәр һәм кирмәннәр биек җир өемнәре һәм тирән чокырлар белән әйләндереп алына, өемнәр өстенә ике рәтле имән диваркура һәм шактый биек машлар (башнялар) эшләнгән була.

Идел һәм Чулманның биек ярларында, чик буйларында һәм кәрван юллары очрашкан урыннарда андый җирләрне һәм юлларны саклау максатында хәрби кирмәннәр – форпостлар төзелә. Казан да шулай барлыкка килә. Чик буе һәм эре шәһәрләр тирәсендә урыны-урыны белән хәтта унар чакрымнарга сузылган махсус ныгытмалар төзелеп китә.



*Аксөяк йорты. Реконструкция.*


Болгар төзүчеләре, элеккеге тәҗрибәләренә таянып һәм Византия, Иран, Урта Азия архитектура үрнәкләреннән файдаланып, зур осталыкка ирешәләр. Биналар төзегәндә болгар архитекторлары төрле математик хисаплаулар, сызымнар һәм махсус җайланмалардан файдаланалар. Андагы математик, геометрик бәйләнешләрне төзеләсе бина үлчәмнәренә күчереп, аны төгәл, матур һәм мәһабәт итеп корырга омтылалар.

Болгарда торак йортларны, нигездә, нарат бүрәнәләрдән бурап төзегәннәр. Нигезгә, гадәттә, ныграк булган имән салынган. Иген саклана торган идән астын да имәннән бурап эшләгәннәр. Йортның түшәме һәм идәне калын нарат тактадан булган, түбәсе ике кыеклы итеп эшләнгән һәм такта, камыш, салам белән ябылган.

Таш биналар салу өчен төзелеш материалы махсус таш чыгару урыннарыннан китерелгән. Таш кисәкләрен тигез итеп ватып алу һәм аларны эшкәртү өчен үткен йөзле кискечләр кулланылган. Болгарлар балчыктан кирпеч ясау һәм аны яндыру серләрен дә әйбәт белгәннәр. Таш һәм кирпечтән салынган биналар эчке һәм тышкы яктан тыгыз известьташ һәм күзәнәкле туф белән капланган, шомартып ялтыратылган. Агачка, ташка, гипска уеп төрле бизәкләр төшерү, диварларга ак, күк, зәңгәр, алтынсу-сары төстәге керамик плитәләр ябыштыру киң таралган була. Ак таштан салынган Болгар корылмалары төгәл геометрик фигура – гадәттә, сигез яки уналты кырлыга күчә торган куб формасында була. Ул гөмбәзле түбә яки чатыр белән тәмамлана.

XI йөздә инде Болгар төзүчеләренең даны ераkларга таралган. Идел-Чулман Болгарыннан Рус җирләренә дә сыйфатлы төзелеш материаллары китергәннәр. XII йөздә Болгар осталары Владимир шәһәрендә соборлар төзүдә актив катнашкан, Юрьев соборын, мәсәлән, алар төзегән.

Идел-Чулман Болгар дәүләтендә шәһәр архитектурасы мәдәнияте аеруча нык үсеш алган. X гасыр башларында болгарларның берничә генә шәһәре булса, XIII йөз башларында инде аларның саны 180гә җитә. Алар арасында хәрби ныгытмалар (крепостьлар) да, җирбиләүче бай феодалларның замоклары да күп. Зурлыгы, төзеклеге,



*Биләрдәге кәрвансарай. Реконструкция.*

матурлыгы белән таң калдырган эре шәһәрләрдән Биләр, Суар, Ашлы, Җүкәтау, Кашан, Тубылгытау һ.б.ны атап узарга мөмкин. Күпсанлы тарихи чыганакларда Биләр, Суар шәһәрләре бигрәк тә еш искә алына.

**Биләр – Олуг шәһәр.** Олуг шәһәр дип йөртелгән *Биләргә* 922 елда нигез салынган. Мәйданы ягыннан аңа тиң шәһәрләр Европада бөтенләй булмаган әле. Бистәләреннән башка гына да 620 га мәйдан биләүче Биләр борынгы Рус дәүләтендәге Чернигов, Владимир, Европаның Париж, Лондон, Азиянең Димәшкъ, Иерусалим шәһәрләреннән күпкә зур булган. Ул территориясенең зурлыгы белән Багдад, Константинополь, Сәмәрканд шәһәрләре белән тиңләшә алган. XII–XIII йөзләрдә үк инде монда 70–100 мең кеше яшәгән.

Биләр ике өлештән – эчке һәм тышкы шәһәрдән гыйбарәт булган. Эчке шәһәрдә Болгар патшасы һәм аның якын туганнары, дәүләт белән идарә итүдә катнашучы кешеләр, дин башлыклары, бай сәүдәгәрләр һәм аларның хезмәтчеләре яшәгән. Шуңа күрә монда таштан, кирпечтән салынган матур биналар да күп булган. Шунда ук Җәмигъ мәчете дә урнашкан. Ул X гасыр башларында агачтан салынган. Бераздан, шуңа кушып, таштан тагын бер бина торгызганнар. Шулай итеп, гомуми мәйданы 2300 квадрат метрлы бик зур мәчет пәйда булган. Аның бер як стенасы тыштан матур итеп ярымколонналар белән бизәлгән. Таш мәчетнең иркен, киң залы рәт-рәт колонналар белән биш өлешкә бүленгән.

Мәчет янәшәсендә генә гөмбәз түбәле ике катлы кирпеч йорт төзелгән. Аның һәр катында дүртәр бүлмә булган. Алар барысы да бер мичтән торбалар аша кайнар һава белән җылытылган. Йортның ишегалдында амбар-келәтләр, башка хуҗалык корылмалары урнашкан. Тышкы шәһәрдә күбесенчә һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр яшәгән. Аларның өйләре бүрәнәләрдән салынган. Шунда ук һөнәрчеләрнең күп санлы остаханәләре дә төзелеп киткән.



*Төзүчеләр.*
*Фарсы миниатюрасы.*

Эчке шәһәргә керә торган капка янында ерак илләрдән килгән сәүдәгәрләр өчен кәрвансарай төзелгән. Шунда ук кирпечтән зур гына мунча да салып куйганнар. Аны җылыту өчен ишегалды ягыннан ягыла торган мич булган, кайнар һава идән астыннан махсус торбалар аша йөргән.

Суар шәһәре гарәп сәяхәтчеләренә X йөзнең беренче яртысында ук билгеле була. Суарның куәтле шәһәр ныгытмалары 100 гектар чамасы җирне биләгән. Кайбер урыннарда бу ныгытмалар икешәр рәт итеп салынган. Тышкы үрләр өстендә очлы башларын югары каратып һәм бер-берсенә тезәп утыртылган имән баганалардан дивар торгызылган. Шәһәрне бөтен яктан сулы тирән чокыр уратып алган. Аның төбендә очлы казыклар тырпаеп торган. Эчке үрләр өстенә имән бүрәнәләрдән бурап эшләнгән ике катлы стеналар һәм билгеле бер ара калдырып күтәртелгән биек манаралар – башнялар төзелгән.

Шәһәрнең үзәгендә матурлыгы белән ерактан ук игътибарны җәлеп итәрлек ике катлы йорт калкып торган. Ул кызыл кирпечтән салынган. Түбәсе, нәкъ Шәрык илләрендәгечә, гөмбәзләп эшләнгән. Киң ишегалды кирпеч койма белән әйләндереп алынган. Өйнең зур ишеге ике яклап ярымколонналар белән бизәлгән. Тәрәзәләрдә – саргылт-яшел төстәге түгәрәк пыялалар. Кыш көне бина бер генә мичтән ягып җылытылган. Эссе һава йөри торган махсус каналлар, Биләр мунчасындагы кебек үк, идән астына урнаштырылганнар. Бу йортта берәр бай феодал гаиләсе яшәгәнлеге шиксез.

**Идел-Чулман Болгарында төзелеш мәдәнияте шактый югары һәм колачлы булган. X йөзләрдә үк болгар осталары таштан, кирпечтән, агачтан мәһабәт сарайлар, җәмәгать биналары, торак йортлар төзиләр, аларны нәфис итеп бизәкли беләләр, җылыту һәм суүткәргеч системаларын төзүдә гаҗәеп осталыкка ирешәләр.**

# МИЛЛИ КИЕМ ТАРИХЫ

Татарларда «Киеменә карап каршылыйлар, акылына карап озаталар» дигән әйтем бар. Моның асылында тирән мәгънә ята. Борынборыннан ук халык кием-салымга битараф булмаган, ул аны даими төстә камилләштергән һәм яшәү шартларына яраклаштырган. Шул рәвешле, һәр милләтнең үз милли киеме барлыкка килгән. Бүгенге көндә төрле милләт кешеләренең, хатын-кыз һәм ир-атның киеме бер-берсеннән әллә ни аерылып тормый. Ә элгәрерәк заманнарда кешенең киеменә карап, аның кайсы милләттән, авылданмы яисә шәһәрдәнме, баймы яисә ярлымы икәнен билгеләп булган.

Татар милли киеме дә озын тарихи үсеш юлы үткән. Кием – матди мәдәниятнең бер өлеше ул.

**Өс киеме.** Һуннар тукымадан һәм хайван тиресеннән, ефәктән тегелгән кием кигәннәр. Нигездә, кием ыштан, күлмәк яки халаттан торган. Тукымадан тегелгән күлмәкнең итәге чак кына тездән өстә, җиңнәре озын булган. Халатның итәге озын булып, тукымадан яисә тиредән ясалган билбау белән буылган. Затлы кешеләрнең билбавы җиз тәңкәләр белән бизәлгән. Ыштан һәм аяк киемнәре кәҗә тиресеннән тегелгән. Салкын вакытта кием өстеннән бизәкле япма салганнар. Һун хатын-кызлары киеме хакында мәгълүмат сакланып калмаган. Һуннар күчмә халык буларак күп вакытларын ат өстендә үткәргәннәр. Киемнәре дә шул тормыш өчен яраклаштырылган. Алар



*Болгар хатыны.*
*VIII–IX гасырлар.*
*Реконструкция.*



*Һуннарның өс киеме.*
*Б.э.к. I гасыр.*

беренчеләрдән булып ыштан кия башлаганнар. Тора-бара бу гадәт башка халыкларга да үтеп кергән.

Борынгы төрки чорда кием-салымны йортта эшләнгән йон, киндер, җитен тукымалардан, постау, күн, йорт хайваннарының тиреләреннән әзерләгәннәр. Кыргый җанварлар – төлке, сусар, кеш, кондыз тиреләре дә кулланылган. Аксөяк катлаулар парчадан, ефәк тукымалардан тегелгән киемнәр кигәннәр. Аларны сәүдәгәрләр Кытай, Урта Азия, Византиядән су юлы аша алып кайтканнар.

Ирләр киеме яшькә карап үзгәрмәгән. Башлык, халат, күлмәк, ыштан, башмаклар ел фасылына карап тегелгән. Кыш көне сырылган халат, итек, бүрек һәм мехтан эшләнгән кием кигәннәр. Өске киемнең чабулары уңнан сулга капланып, билбау белән бәйләп куелган.

Хатын-кызларның өс киеме яшь үзенчәлекләрен чагылдырган. Яшь кыз балаларның киеме һәм бизәнү әйберләре гадилеге белән аерылып торган. Кияүгә чыкканнан соң, бизәкле алка, йөзек кигәннәр, билбау бәйләгәннәр. Күлмәк, халат, аяк һәм баш киеме формалары да үзгәргән. 50–55 яше тулган хатын-кызлар яңадан гади бизәнү әйберләре кигәннәр, кыйммәтлеләрен яшь кыз туганнарына яисә кызларына бүләк итә торган булганнар.

Болгар чорында да күлмәк һәм киң атламлы ыштан ир-ат һәм хатын-кыз киеменең нигезен тәшкил иткән. Алар өстеннән кыска җиңле яки җиңсез камзул кигәннәр. Озын, киң чабулы, озын җиңле җиңелчә яки калын кафтан, чапан кулланышта булган.

Озын чабулы, җилкәдә иркен, күкрәк һәм бил өлешләрендә каптырмалы булып, сәйлән һәм көмеш җепләр белән бизәлү – бу чор киеменең төп сыйфаты.

Соңрак болгарларның өс киеме тагын да камилләшкән: билле җиңел казаки, бишмәт, туннар, җилән һәм чикмәннәр барлыкка килгән. Эчтән киелгән күлмәкнең озынлыгы үзгәргән. Ирләр күлмәге кыскарып, хатын-кыз күлмәге бала итәк хисабына озынайган. Гәүдәгә сыланып тора торган җиңсез камзул кия башлаганнар.

Димәк, татар хатын-кыз күлмәгенең бер өлеше булган бала итәк Болгар чорыннан ук килә икән.




*Билбау. Реконструкция.*

**Билбау (бил бавы).** Билбау барлык чорларда да киемнең мөһим бер өлешен тәшкил иткән һәм аңа тирән мәгънә салынган. Билгә бәйләнгән билбау, бабаларыбыз уйлавынча, өч дөньяны аерып торучы билге ролен үтәгән. Билбаудан өске өлеш – Күкне, түбәндәгесе – Җир асты дөньясын аңлаткан. Борынгы төркиләр өчен «кин» дип аталган кендек турысы бик мөһим саналган. Явыз көчләр нәкъ менә кендек аша кешегә үтеп керә дип уйлаганнар. Шулай итеп, билбау билне дә ныгыткан һәм бер үк вакытта явыз көчләрдән, авырулардан, бәла-казалардан да саклаган.

Алты яшькәчә балаларның билбавына саклагыч кыңгыраулар такканнар. Алты яше тулган балага яңа билбау бәйләгәннәр. Ир балалар бер генә төстәге, кызлар исә чуар билбау такканнар. Аңа төрле бизәкләр төшерелгән, ә уң ягына ярымтүгәрәк кесәләр беркетелгән. 14–15 яше тулган ир бала билбавына корал тагу хокукы алган. Бу – яшүсмерлектән егетлеккә чыгуны аңлаткан. Билбауга үсемлек сурәтләре белән бизәлгән көмеш тәңкәләр асылган. Аларның саны иясенең җәмгыятьтәге дәрәҗәсен күрсәткән. Зур кайгы килгән вакытта төркиләр билбауларын салып муеннарына асканнар. Сугышта һәлак булган сугышчының гәүдәсе табылмаса, аның урынына билбавын күмгәннәр.

Болгар чорында да билбау ир-ат киеменең мәҗбүри өлеше булып калган. Ул металл тәңкәләр белән бизәлгән, сырлы каптырмалы булган. Сөяктән, металлдан эшләнгән, коеп һәм челтәрләп-бөтереп ясалган төймә-сәдәпләр билбау хуҗасының җәмгыятьтә токкан урынын күрсәткән.

**Баш киеме.** Һуннарның баш киеме тире белән тукымадан тегелгән. Борынгы төркиләрнең баш киеме – очлым (шлем) формасында булган. Иң башта алар конуссыман булса, соңрак түбәнәеп гөмбәз, түбәтәй формасын алган. Күчмә халыклар (ирләр дә, хатыннар да) озын чәчләрен толымнарга үргәннәр.



*Хәзәрләрнең көмеш билбавы. X гасыр.*

*Борынгы аксөякнең чигүле аяк киеме.*
*Пазырык курганы. Б.э.к. V гасыр.*



Болгарларның баш киемнәре киездән, тиредән, йон, бәрхет һәм башка төрле тукымалардан тегелгән. Шар-конус рәвешендәге бүрек аеруча киң таралган. Шундый сырган бүрекне гаскәриләр очлым астыннан кигәннәр. Кышкы бүрекләр тиредән тегелгән һәм мех белән кырпу тотылган. Аксөякләрнең баш киеме кыйммәтле җәнлек тиреләреннән эшләнгән. Авыл халкы колакчын тире бүрекләр кигән.

Хатын-кызның баш киеме күп төрле булган. Аларда яшь үзенчәлекләре һәм иясенең иҗтимагый хәле ачык чагылган. Кызлар түгәрәк калыплы бүрекләр, йомшак ак калфакчыклар кигәннәр. Алар кайвакыт тәңкәләр белән бизәлгән. Кияүдәге хатын-кыз баш киеменең төп өлешен тукымадан эшләнгән япма (тастар һәм өрпәк) тәшкил иткән. Алар күн тасма яки җиз тәңкәләр, сәйләннәр, энҗе-мәрҗәннәр, чигә алкалары белән бизәлгән. Япма өстеннән түгәрәк шар яки конуссыман бүрек – кашпау кигәннәр.

Ислам дине таралган саен ир-атларда чәчне бөтенләй кырып алу, сакал-мыек җибәрү йоласы ныгып урнашкан. Баш киемнәреннән чалма кулланышка кергән. Чалма сәфәрдә вафат булган хуҗасына кәфенлек булып та хезмәт иткән.

Хатын-кызлар, чәчләрен турыдан ачып, ике толымга үргәннәр һәм чулпылар тагып йөргәннәр.

**Аяк киеме.** Борынгы төркиләр очлы башлы кыска кунычлы тире итекләр кигәннәр. Соңрак күннән эшләнгән үкчәсез җиңел аяк киемнәре, кәвеш башмаклар, чүәкләр барлыкка килгән. Аларны «тула оек» дип аталган постау яки киндер оеклар белән, баш-башлары чигелгән аякчу – чолгаулар белән кигәннәр.

Болгарларда, борынгы төркиләрдәге кебек үк, күннән эшләнгән бизәкле, чигүле аяк киемнәре киң таралыш тапкан. Борынгы болгарларда тире-күн һәм йон эшкәртү шулкадәр дәрәҗәдә камилләшкән ки, хәтта Европа һәм Азиянең күп халыкларында яхшы эшкәртелгән йомшак күнне, сәхтиянны «болгари» дип атау гадәткә кергән.

**Хәрби кием.** Һун гаскәрендә меңнәргә, йөзләр, уннарга бүленеш гамәлдә булган. Бу борынгы төркиләрдә дә, болгарларда да очрый. Укчылар, сөңгечеләрнең киеме җиңел, тиз хәрәкәт итәр өчен уңайлы булган. Сугышчыларның бер өлеше көбә күлмәк кигән. Көбә күлмәк – вак металл боҗраларны яисә пластиналарны бер-берсенә кертеп эшләнгән сугыш киеме. Ул очлым белән берлектә сугышчының тәнен саклаган. Көбә күлмәк өстеннән күн билбау бәйләгәннәр. Аңа сугыш кирәк-яраклары, су савыты һ.б. беркетелгән. Борынгы төрки гаскәриләре муеннарына кыршау, кулларына беләзек һәм сул колакларына алка такканнар.

Гаскәриләр ук, кылыч, сөңгеләр белән коралланганнар. Коралга аның хуҗасының рөхсәтеннән башка кагылырга, өстеннән атлап чыгарга ярамаган, «кот»ы китүдән курыкканнар. Хакимлекне белдергән укларга төшерелгән махсус билгеләр баш күтәрү яисә гаскәр туплауга өндәгән һ.б. Илчеләр исә кыйммәтле металлдан эшләнгән ук йөрткәннәр. Ул аларның вәкаләтле булуларын аңлаткан.

**Балалар киеме.** Борынгы төркиләр яңа туган баланы эшкәртелгән йомшак хайван тиреләренә яисә мамык тукымага биләгәннәр. 6 айдан күлмәк кидергәннәр. 3–4 яшьләрдән балаларның киемнәре олыларныкына охшаган булган.

Ир балалар киемендә кара һәм зәңгәр, кыз балаларныкында кызыл, зәңгәрсу, яшел төсләр урын алган. Кыз балалар 3–5 яшьтән



*Укчы киеме. VI–VII гасырлар. Реконструкция.*



*Көбәле төрки сугышчысы. Реконструкция.*

алып кияүгә чыкканга кадәр гади түгәрәксыман алкалар һәм шома йөзекләр кигәннәр. Әлеге бизәнү әйберләре балалар арасындагы җенси аерманы да күрсәтеп торган.

Кием баланың яше һәм гаиләдәге урыны хакында мәгълүмат биргән. Кияүдәге хатын-кыз бизәкләр төшерелгән йөзекләр, алкалар һәм җиз тәңкәле билбаулар таккан. Бизәнү әйберләренең күп булуы өс, баш һәм аяк киеме формасының үзгәрүе җитлеккәнлек билгесе дә булып торган.

Болгар чорында яңа туган баланы чиста ак киндер тукымага төргәннәр. Өч көнлек баланы, аяклары төз булсын өчен, тукыма белән тыгызлап бәйләгәннәр. Башлыклар ак җептән бәйләнгән яки тукымадан тегелгән.

Кызларның чәчләре үсүгә толымнарына тәңкәләрдән ясалган чулпылар такканнар. Ислам дине кергәннән соң, балигъ булган кыз балалар башларын каплаганнар, яулык бәйләгәннәр. Бәйрәмнәрдә яулык калфак яки башлык-кәтәҗи белән бергә киелгән.

**Шулай итеп, борынгы төрки һәм болгар чорында да кием тормыш өчен уңайлы, яшәү шартларына яраклаштырылган һәм зәвык белән эшләнгән булган. Һәрбер милләтнең үзенә хас, кабатланмас стиле булган.**

## БОРЫНГЫ МОНГОЛЛАР ҺӘМ ТАТАРЛАР. МОНГОЛЛАРНЫҢ ИДЕЛ-ЧУЛМАН БОЛГАРЫН ЯУЛАП АЛУЫ. ҖУЧИ ОЛЫСЫ ТӨЗЕЛҮ

**Борынгы монголлар һәм татарлар.** XIII гасырның 20 елларыннан башлап Идел-Чулман Болгарына көнчыгыш тарафтан хәвефле хәбәрләр ешая. Хәрби осталыгы белән дан казанган билгесез кабиләләр Европага таба хәрәкәт итә. Аларны әле монголлар, әле татарлар дип атыйлар.

Составында «татар» компоненты булган кабиләләр (огуз татар, токуз татар) борынгы төрки чордан ук билгеле. XI–XII гасырларда Монголия җирләрендә яшәүче бер төркем кабиләләрне дә «татар» дип йөрткәннәр.

Монголлар һәм татарлар үзара дус яшәмәгәннәр. Монгол кабиләләренең бер өлеше башында торган Темучин боерыгы буенча меңләгән татар үтерелә. Исән калган ирләр Темучин гаскәрендә

хезмәт итәргә тиеш була. Әмма ләкин «татар» атамасы тарих битләреннән юкка чыкмый.

**Монгол яулары**. Темучин, башка монгол кабиләләрен үзенә буйсындырып, бердәм Монгол дәүләтен оештыра. 1206 елда Темучинны Чыңгыз хан, ягъни Бөек хан дип игълан итәләр. Монголларның яулап алу походларына хәзерлек башлана.



*Чыңгыз хан.*

Күпмедер вакыт үтә, монголлар дөньяны буйсындырырга омтылалар. Чыңгыз хан боерыгы буенча күпсанлы гаскәрнең алдында татарлар бара. Аларны сугышка беренче булып керергә мәҗбүр итәләр. Бөтен Чыңгыз хан явын «татар» исеме белән йөртү тарала. Шуның өстенә монгол хакимлегенә эләккән барлык кабиләләр дә «татар» дип аталырга тиеш булалар.

Кавказ халыкларын буйсындырганнан соң, 1223 елның язында татар-монголлар кыпчак далаларына үтеп керәләр. Идел-Чулман Болгары чикләре дә якыная. Һәм шул ук елның көзендә монгол гаскәре илнең көньягыннан үтеп тә керә.



*Монголлар яуда. Реконструкция.*



*Болгарларның монголлар белән сугышы. Рәссам Р.Заһидуллин.*

Гаскәрләр Иделнең хәзерге Самара янындагы кискен борылыш ясаган җирендә очрашалар. Болгар сугышчыларының бер өлеше җиңелгән сыман чигенә башлый. Алар артыннан монголлар ташлана. Кинәт монголлар артыннан ук биек калкулык артында качып торган башка болгарлар килеп баса, бу исә дошман өчен көтелмәгән хәл була. Сугыш кырыннан әле генә «качкан» болгарлар кинәт кирегә борыла. Монголлар өстенә бөтен яктан уклар атыла. Бу моңарчы җиңелмәс булган Чыңгыз хан армиясенең беренче җиңелүе була.

Алты елдан соң янә болгарларның монголлар белән бәрелеше була. Җаек елгасы әлеге бәрелешнең шаһиты була. Биредә болгарларның каравыл отрядлары торган. Аяусыз сугыш башлана. Ләкин бу юлы болгарлар җиңелә. Шул рәвешле дошман гаскәренең көчен сынап карау алымы монголларның сугыш тактикасына хас күренеш була.

1232 елда монголлар тагын бер тапкыр болгарларны яулап алырга тырышып карыйлар. Ул вакытта алар Биләргә кадәр җитәләр. Шәһәрнең көчле ныгытмалары зур булмаган монгол гаскәрен кире бора. Монголларга кире далага кайтырга туры килә.

Көнбатышка хәлиткеч походка монголлар озак хәзерләнә. 1235 елның ахырына алар йөз меңлек гаскәр туплый. Гаскәр башында инде вафат булган Чыңгыз ханның оныгы Батый (Бату) тора. Гаскәр иң беренче чиратта Идел-Чулман Болгарын һәм рус кенәзлекләрен яулап алырга тиеш була.

Болгарлар монголларның үзләренә һөҗүм итәргә җыенуларын белеп алалар. Алар һөҗүмне кире кайтарырга әзерләнә: шәһәрләрен ныгыта, өстәмә гаскәрләр туплый. Биләрдә генә ун-егерме мең сугышчы исәпләнә. Ләкин монголларның көче берничә тапкыр артыграк була.



Батый хан.

1236 елның көзендә болгар җире канлы сугыш кырына әверелә. Шәһәрләр дөрләп яна, көлгә әйләнә. Басып алучылар олыны да, кечене дә кызганмый.

Рәхимсез һөҗүмнән соң беренчеләрдән булып дәүләтнең башкаласы – Бөек Биләр шәһәре бирелергә мәҗбүр ителә. Шәһәрдә яшәүчеләрнең бер өлеше үтерелә, ә икенче бер өлеше әсирлеккә алына. Халыкның барлык байлыгы, мал-мөлкәте монгол сугышчыларының табышына әверелә. Чәчәк атучы шәһәр җир йөзеннән юк ителә.

Болгар дәүләтенең башка шәһәр һәм авыллары да Биләр язмышына дучар ителә. Дистәләгән шәһәр һәм йөзләгән авылның хәтта атамалары да калмый. Кайчандыр тормыш гөрләгән җирләр бушап кала. Болгарлар куркынычсызрак булган районнарга, Чулман артына яисә Рус җирләренә качалар. Рус елъязмалары хәбәр итүенчә, алар Рус җирләрендә «үзләренә урын бирүләрен үтенәләр». Болгарларны Идел буе шәһәрләренә урнаштыралар.

Идел-Чулман Болгары мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктый. Аның халкы монгол ханнарына ясак түли башлый. Болгар әмирләре хакимлек итү өчен монголлардан ярлыклар алырга тиеш булалар.

Әмма ләкин тар-мар ителгән ил басып алучылар өчен җиңел табышка әверелми. Тарихта баш күтәргән болгарларга каршы ике зур поход булуы билгеле. Алар 1239–1240 һәм 1277–1278 елларда була. Болгар җирләрен үзләренә тулысынча буйсындыру өчен монголларга егерме елдан артыграк вакыт кирәк була.

Батыйның 1236 елгы явы нәтиҗәсендә монголлар тарафыннан яулап алынган Идел-Чулман Болгары үзенең бәйсезлеген югалта.

**Җучи Олысы төзелү.** Монголлар Болгар дәүләтеннән соң кыпчакларга, бортасларга, мордва, чуаш, чирмешләргә (мари) каршы яуларын дәвам итәләр. Озакламый Төньяк-Көнчыгыш Рус дәүләте дә җиңелүгә дучар ителә.



*Шәһәрне штурмлау. Фарсы миниатюрасы.*

Хәзер монгол гаскәрләре Үзәк һәм Көньяк Европага юл ала. Әдрән диңгез ярларында Батый Монголиянең бөек ханының үлеме турында хәбәр ала. Ул үз гаскәрләрен кире бора. Әмма ләкин Батый үз армиясе белән монгол башкаласы Каракорымга барып җитми. Ул Түбән Иделдә, кыпчак далаларында туктала. Гаскәрләренең бер өлеше белән ул биредә кала да. Аңа үзе буйсындырган җирләр белән шуннан торып идарә итү уңайлырак була.

Кыпчак далаларында яңа дәүләт оеша башлый. Аны Чыңгыз ханның олы улы – Батыйның атасы хөрмәтенә Җучи Олысы дип атыйлар. Соңрак әлеге дәүләт Алтын Урда буларак танылა.

Башта Батый хан Болгар шәһәрендә туктала. Болгар Алтын Урданың беренче башкаласына әверелә. Шул чорда шәһәр яңадан торгызыла. Анда ул акча сугу эшен торгыза. Кенәзлек итүгә ярлык алу өчен рус кенәзләре бирегә килә торган була. Озакламый Батый ханның боерыгы буенча Түбән Иделдә Җучи Олысының яңа башкаласын төзү эше башлана. Аңа Сарай дигән исем бирәләр.

Батый үз олысында мөстәкыйль хаким булырга омтыла. Аның идарәсе вакытында Алтын Урда әле һаман Монгол империясенең баш ханына бәйле була. Батый аның вассалы санала һәм аның исеменнән акча суга.

Алтын Урданың яңа ханы Бәркә (идарә иткән еллары: 1256/57 – 1266) мөстәкыйльлеккә җитди адым ясый. Ул Монгол империясе ханы исеме белән акча сугуны туктата. Әмма тәңкәләргә үз исемен әлегә куймый.

Чираттагы Алтын Урда ханы Мәнгү Тимер (идарә иткән еллары: 1266–1282) үз исеме белән акча сугарга җөрьәт итә. Бу Алтын Урданың мөстәкыйль дәүләткә әверелүен аңлата.

Алтын Урда ханнарының биләмәләре Азия һәм Европаның яртысын диярлек алып торалар. Аларның көнчыгыш чикләре – Иртыш, ә көнбатыш чикләре Днестр һәм Дунай елгаларына туры килә.



*Бунчуклар – монгол байраклары.*

Төньякта Җучи Олысы территориясе үз эченә рус җирләренең бер өлешен, болгар, мордва, чирмеш (мари) һәм удмурт җирләрен ала. Көньяктан ул Арал, Каспий, Азов диңгезләре белән чикләнә.

Җучи Олысының халкы төрле була. Түбән Идел далаларында төрки телле кыпчаклар күчмә тормыш алып бара. Кайбер халыклар, мәсәлән, болгарлар, Кырым һәм Харәзем халыклары, утрак тормышта яшиләр. Монголлар үзләре халыкның азчылыгын тәшкил итә. Аларның бер өлеше үз туган илләренә кайтып китә.

Вакытлар үтә. Төпләнеп калган монголлар җирле кыпчаклар белән кушыла. Болгарлар кыпчак далаларындагы башка төрки телле халыклар белән катнаша. Уртак мәдәният хасыйл була. Хәзерге татарларның килеп чыгышы да болгарлар һәм кыпчаклар белән бәйле.

Монголлар тарафыннан яулап алынган Көнчыгыш Европа җирләрендә Җучи Олысы төзелә. Әмма бу җирләрдә монголлар үзләре бик аз була, алар идарә итүче бер катламны гына хасыйл итәләр. Халыкның күпчелеге төрки телле була. Мәсәлән, Җучи Олысының Болгар вилаятендә шул ук болгар халкы токымнары яшәүләрен дәвам иткәннәр.

**XIII гасырның урталарында монгол яулап алулары нәтиҗәсендә үзәге Идел буенда булган Җучи Олысы (Алтын Урда) дәүләте барлыкка килә. Әлеге дәүләттә ике йөз ел дәвамында Идел болгарлары, төбәктәге башка халыклар яши. Алар татар дип атала башлый.**

# АЛТЫН УРДА ЧӘЧӘК АТУ ЧОРЫНДА

**Үзбәк хан идарәсе чоры**. Җучи Олысы урнашудан соң җиде дистә ел вакыт уза. Алтын Урда тәхетендә берничә хан алышына. 1312 елда ил белән Үзбәк хан идарә итә башлый. 30 ел идарә итү вакытында ул Алтын Урданы ныгыту һәм аның куәтен арттыру өчен күп көчен сарыф итә.

Үзбәк хан дәүләт эчендәге фетнә-чуалышларга чик куя, каты кулы белән анда тәртип урнаштыра. Ул фән, мәгариф үсешенә булышлык итә, шәһәрләр төзи.

Ислам Алтын Урданың дәүләт диненә әверелсә дә, башка диннәрне дә тоту мөмкинлеге булган. Үзбәк православие руханиларына Алтын Урданың беренче ханнары тарафыннан бирелгән барлык ташламаларны да үз көчендә калдыра. Христиан руханилары ясак түләмиләр һәм элеккеге җир биләмәләренә хуҗа булып калалар. Бу чорда православие динен мыскыл иткән өчен хәтта үлем җәзасына да дучар иткәннәр.

Үзбәк хан вакытында Алтын Урданың халыкара абруе үсә. Хан Византия императоры кызына өйләнгән була, Мисыр солтаны белән туганлык мөнәсәбәтенә керә. Каһирә мәйданнарының берсе Үзбәк исеме белән атала. Үзенең сеңелесе Кунчакны Мәскәү кенәзе Юрий Даниловичка кияүгә бирә, аның православие диненә күчүенә каршы килми.

Үзбәк идарә иткән елларда Алтын Урда чәчәк ата һәм ныгый.

**Дәүләт идарәсе**. Феодаль дәүләт булган Алтын Урданың башында Батый хан нәселе ханнары тора. Ханзадәләр (патша уллары) – хакимлек итүче династия әгъзалары – олыслар белән идарә иткәннәр. Мөһим булган административ һәм хәрби хезмәт урыннарын да алар биләгән. Башка хәрби-



*Алтын Урда ханы.*
*М.Горелик реконструкциясе.*

феодаль аксөякләр вәкилләре белән беррәттән, ханзадәләр корылтайларда (съездларда) да катнашканнар. Корылтайлар ханны тәхеткә утырту яки төшерү, сугыш игълан итү яисә солых төзү, башка дәүләтләр белән килешү төзү һәм башка әһәмиятле сорауларны хәл итү өчен чакырылган.



*Хан шәехләр белән. Шәрык миниатюрасы.*

Алтын Урда белән идарә итүдә ханга диван (дәүләт башлыгы каршындагы киңәшмә орган) ярдәм иткән. Анда төп фигура булып бәкләри бәк (бәкләр өстеннән бәк) яки бөек әмир торган. Дәүләткә буйсынган өлкәләрдә ханның вәкилләре – баскаклар (җирле идарә башлыклары) идарә иткән. Шунда ук даругачылар да билгеләнгән. Алар ясак һәм салым җыйган. Шулай ук дәүләттә дистәләгән вак вазыйфалар да булган.


Гаскәр ханның төп терәге һәм таянычы булган. Анда 300 меңнән артык кеше исәпләнгән.

XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урда тарафыннан идарә ителгән ил бердәм үзәктән идарә итү системасы булган, бер хөкемдар үзәкләштерелгән дәүләткә әверелә. Анда киң тармаклы идарә аппараты төзелә.

**Хуҗалыгы**. Җучи Олысының күчмә халыклары терлекчелек белән шөгыльләнүен дәвам итәләр. Көтүчеләр үгез, дөя, сарык, кәҗә көтүләре көткәннәр. Исәпсез-хисапсыз ат көтүләре аеруча нык сакланган. Утрак тормыш белән яшәүче өлкәләрдә гади халыкның төп шөгыле игенчелек булган. Шәһәрләрдә һөнәрчелек үсеш алган. Кара һәм төсле металл, декоратив керамика, төзелеш кирпечләре, пыяла җитештерү һәм зәркән эше югары дәрәҗәгә җиткән.

Һөнәрчеләр арасында Харәземнән, Төньяк Кавказдан, Кырымнан китерелгән тәҗрибәле осталар да аз булмаган. Әлеге осталар, шулай ук болгар төзүчеләре катнашында Сарай шәһәре торгызыла.

Әмма үзенең чәчәк атуы белән Алтын Урда беренче чиратта сәүдәгә бурычлы була. Сәүдәгәрләр үз акчаларын бик теләп Сарай дирһәмнәренә алмаштырганнар. Дирһәмнәр белән әлеге илдә һәм



*Сарай казылмаларында табылган чынаяк кирпеч.*

күрше дәүләтләрдә зур табыш белән товарлар алырга мөмкин булган. Үзбәк хан чорында сәүдәгәрләр тыныч күңел белән юлга чыкканнар. Аларны югары булмаган таможня җыемнары һич куркытмаган.

Бөек Идел Алтын Урданың төп сәүдә юлына әверелә. Ул шулай ук Бөек Ефәк юлының да зур өлешен үз карамагында тота. Әлеге ике транспорт юлы буенча тышкы сәүдә эшләре алып барылган. Аларның берсе – Алтын Урданың көньяк һәм төньяк өлкәләрен, икенчесе – Шәрык (Көнчыгыш) белән Гаребне (Көнбатышны) бәйләп торган. Алтын Урда шәһәрләре базарларында Көнбатыш Европа һәм Кавказ арты, Урта Азия һәм Фарсы, Кытай һәм Һиндстан, рус кенәзлекләре һәм Болгардан китерелгән товарлар белән сәүдә иткәннәр.

Алтын Урданың көч-куәте терлекчелек, җир эшкәртү, һөнәрчелек һәм сәүдәгә нигезләнгән була.

**Алтын Урда шәһәрләре. Алтын Урданың Болгар Олысы.** Әле Батый хан идарәсе чорында ук Алтын Урданың 110 шәһәренә нигез салынуы турында мәгълүмат бар. Алтын Урда шәһәрләренең күпчелек өлеше Идел ярларына салынган. Калганнары Урта Идел буе, Кырым һәм Харәзем өлкәләрендә урнаша. Кайберләре, бигрәк тә болгар шәһәрләре, монгол яулап алулары вакытында җимерелә. Үзбәк идарә иткән елларда алар янәдән торгызыла. Кылганнар гына йөгергән далаларда үз олысларының көчен күрсәтергә омтылган ханнар әмере буенча күп шәһәрләргә нигез салына.

Йөзләгән Алтын Урда калалары арасында иң зурысы һәм көчлесе булып өч шәһәр – Сарай, Сарай әл-Җәдид (Яңа Сарай) һәм Кырым (Солхат) санала, кечерәк шәһәрләр – Кафа (хәзерге Феодосия), Азак (хәзерге Азов) та алардан калышмаска тырыша.

Алтын Урданың беренче башкаласы булган Сарайда 75 меңгә якын кеше – татарлар, монголлар, аланнар, чиркәсләр, руслар, византиялеләр яшәгән. Аны җәяү әйләнеп чыгу өчен тулаем бер көнне сарыф итәргә кирәк булган. Шул заман кешеләре Сарайны иң матур шәһәрләрнең берсе дип санаганнар. XIV гасыр гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттутаны бигрәк тә матур базарлар, киң урамнар һәм күпсанлы мәчетләр таң калдырган.



*Кырымдагы Үзбәк хан мәчете.*

Сарай матур гына түгел, төзек шәһәр дә була. Анда сууткәргеч торбалар сузылган, канализация үткәрелгән, урамнарда фонтаннар, ә юл кырыйларындагы арыкларда чип-чиста су аккан. Биредә яшәүчеләр эчәр өчен суны әлеге фонтаннардан алганнар.

Бай йортлардагы торак бүлмәләр җылы һәм уңайлы була. Идән астыннан узучы төтенүткәргеч каналлар аша мичтән кайнар һава җибәрелеп торган. Әлеге йортлар, җәмәгать биналары һәм сарайлар кебек үк, кирпечтән төзелгән.

Гади шәһәр кешеләре мондый уңайлыкларны белмәгән. Алар агач яки яндырылмаган кирпечтән төзелгән йортларда яшәгәннәр. Коллар исә җир алачыкларда (землянкаларда) гомер кичергәннәр. Салкында алар учак яндырып җылынган.

Сарай шулай ук һөнәрчелек үзәге буларак та билгеле. Шәһәрнең бөтен бер кварталларын чүлмәкчеләр, металл эшкәртүчеләр, зәркәнчеләр алып торган. Ялтыравык йөгертелгән савытлар, төрле архитектура детальләре ясаучы остаханәләр иртәдән кичкә кадәр эшләп торган.

XIV гасыр уртасында Үзбәк хан Алтын Урданың икенче башкаласына – Сарай әл-Җәдид шәһәренә нигез сала. Аның хәрабәләреннән ерак түгел хәзерге Волгоград шәһәре урнашкан.

Сарай әл-Җәдид Алтын Урданың элеккеге башкаласы Сарайдан берни белән дә калышмый. Биредә шулай ук базарлар гөрли, арыклар буйлап чиста су ага, дистәләгән мәчетләр торгызыла.

Йөзләгән һөнәрчеләр бай катлаулар өчен зәвыклы, кыйммәтле савыт-сабалар, бизәнү әйберләре һәм көнкүреш кирәк-яраклары, хуҗалык товарлары җитештерә.

Биналар архиректурасы да үзенчәлекле була. Шәһәр байлары йортларының диварларын төрле төстәге ялтыравык йөгертелгән матур плитәләр белән каплатканнар. Плитәләргә зур яфраклар һәм чәчәкләр рәвешендәге бизәкләр төшерелгән. Ишек өстендәге аркаларны гарәпчә язулар бизәгән; аларны зәңгәр фонда ак буяу белән төшергәннәр.

Кырым ярымутравының уртасында Кырым шәһәре урнашкан була. Ул Алтын Урдада халык саны һәм байлык ягыннан өченче урында тора. Үзбәк хан идарә иткән чорда халыкара сәүдәнең үсеше ул шәһәрнең тиз арада күтәрелүенә этәргеч ясаган.

XIV гасырда Алтын Урдадагы күп кенә башка шәһәрләр дә күтәрелеш кичерә. Әмма алар барысы да, дәүләт көчсезләнү сәбәпле, XV гасырның беренче яртысында яшәүдән туктый.

Бай шәһәрләрнең күп булуы Алтын Урда цивилизациясенең зур үсешкә ирешүен күрсәтә.

**Алтын Урданың Болгар Олысы.** 1236 елда Батый хан гаскәрләре тарафыннан хәрабәләр хәленә китерелгән Болгар җиренә тормыш әкренләп кире кайта. Батый ханның талауларына Алтын Урда ханнарына зур ясак түләү өстәлә.

Шулай да Болгар иле үз яраларын әкренләп төзәтә. Иделдә – Болгар, Чулманда Җүкәтау яңадан төзелә. Яңа урында Биләр дә күтәрелә. Әмма хәзер бер шәһәрнең дә ныгытмалары булмый инде.


Борынгы шәһәрләр – Казан, Чаллы, Кирмән, Алабуга, Казансу буендагы Урмат ныгыйлар. Яулап алучылар тимәгән уңъяк Чулман төбәкләрендә яңа торак урыннары барлыкка килә.

Әлеге шәһәрләрнең төп халкын болгарлар тәшкил итә. Әмма еш кына шәһәр урамнарында кыпчакларны,



*Болгардагы Алтын Урда чоры мунчасы казылмалары.*

дәүләтнең көньяк төбәкләреннән күченеп килүчеләрне очратырга мөмкин була.



Болгардагы Кара пулат.

Шәһәрләр һәм шәһәр һөнәрчелеге белән беррәттән, авыл хуҗалыгы да яңадан торгызыла. Тора-бара Болгар Олысы Алтын Урда халкын сыйфатлы икмәк белән тәэмин итә башлый. XIV йөзнең беренче яртысында ул, Алтын Урда кебек үк, тулаем икътисади күтәрелеш чорына керә.

Болгарлар җимерелгән хуҗалыкны ярты гасыр эчендә зур көч белән яңадан торгызалар. Әмма Болгар җирендә элеккеге кебек авыллар һәм шәһәрләр күп булмый.

«Җучи Олысының алтын тәхете» – Болгар шәһәрен зурлап әнә шулай атыйлар. Монда бернинди дә арттырып әйтү юк. Чөнки Болгарда Батыйның беренче ставкасы була. Анда Урданың беренче акчаларын суга башлыйлар.

XIV гасыр башына Болгар Алтын Урданың иң зур шәһәрләренең берсенә әверелә. Анда яңа һөнәрчеләр бистәләре барлыкка килә. Ул бистәләрдә металл коючылар һәм тимерчеләр, чүлмәкчеләр һәм сөяк эшләнмәләр әзерләүчеләр, шулай ук күнчеләр яши.

Һөнәрчеләр гади генә торакларда яшәсә дә, бистәләрдәге урамнар агач белән каплатылган була. Шәһәрнең бай кешеләре үзләренә йортларны яндырылган кирпечтән төзиләр, җылытыла торган идән түшиләр.

Болгар төзүчеләре чын осталар була. Шәһәрнең үзәк мәйданында алар таштан, биек итеп Җәмигъ мәчетен салып куялар. Мәчет залына майолика (балчыктан эшләнеп яндырылган һәм ялтыравык йөгертелгән яки буяу белән буялган) плитәләр һәм чынаяк кирпечләр җәелә. Болгар кешеләре, хәрби куркыныч булганда, аның калын диварлары артында саклана да алган.

Җәмигъ мәчетеннән ерак түгел ике төрбә (бер ыру яисә бер гаилә әгъзаларын күмү өчен махсус бина) урнаша.

Хан төрбәсе белән рәттән Кече манара калкып тора. Аның түбәсенә биек, бормалы эчке таш баскычтан менәргә мөмкин була.



*Болгардагы Кече манараның бизәлеше.*

Болгар шәһәрендә берничә пулат бар. Кара пулат турында күп риваятьләр йөри. Янгыннан каралып калган диварларына ишарәләп, әлеге бинаны шулай атаганнар. Риваятьтә болай диелә: Урда кешеләре болгарлар күтәрелешен бастырганнан соң, исән калган Болгар ханы Габдулла үзенең гаиләсе һәм якыннары белән Кара пулатта яшеренә. Эзәрлекләүчеләр бина тирәли бүрәнәләр өяләр һәм ут төртәләр. Болгар ханының гүзәл кызы түбәгә чыга һәм исән кала. Аны ялкын телләре дә, тынны томалаучы кара төтен дә үтерә алмый. Янгын сүрелә төшкәч, барысы да яшь чибәркәйнең күккә ашуын күрәләр.

Галимнәр Кара пулатның нинди максатта төзелүе турында әле хәзер дә бәхәсләшәләр. Татар риваятенә караганда, анда Болгар патшалары гаеплеләргә җәза биргәннәр. Бинаның аскы, рәшәткәле тәрәзәләре шул фикергә юнәлтә. Әмма ул бинаның мавзолей яки мәчет карамагындагы мәдрәсә булуы да ихтимал.

Ак пулат – шәһәрнең икенче бер гүзәл бинасы. Ул берничә гөмбәзсыман түбәле җәмәгать мунчасы була. Елның салкын вакытында мунча җылытылган, анда даими рәвештә кайнар су да булган. Җылылык – җир асты каналы, ә кайнар һәм салкын су – балчыктан эшләнгән торбалар буйлап бирелә.

Әлеге мунчалар юыну гына түгел, аралашу һәм ял итү урыны да булган. Болгар аксөякләре анда әңгәмәләр корган, шагыйрьләрнең чыгышларын тыңлаган, шахмат һәм шашка уйнаган.

Болгар һөнәрчелек һәм архитектура гына түгел, сәүдә белән дә дан тоткан. Болгар товарларын рус кенәзлекләрендә һәм Урта Азиядә, Кытайда һәм Һиндстанда, Византиядә һәм Якын Көнчыгышта яхшы белгәннәр. Болгар шәһәре тирәсендә чит җирләрдән килгән сәүдәгәрләр дә яшәгән. Археологларның раславынча, монда әрмәннәрнең сәүдә бистәсе һәм рус сәүдәгәрләренең шактый зур бистәсе дә урнашкан булган.

**XIV гасырда, Болгар белән беррәттән, дәүләтнең башка шәһәрләре – Җүкәтау, Кашан, Кирмән дә чын мәгънәсендә чәчәк атуга ирешкән. Бу исә болгар җирләренең Алтын Урда хакимияте астында да үз үсешләрен дәвам итүе турында сөйли.**

## АЛТЫН УРДАДА МӘДӘНИЯТ, МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН ҮСЕШЕ

Мәдәният (культура) – киң төшенчә. Талантлы шәхесләр тарафыннан тудырылган матур әдәбият, музыка һәм театр сәнгате, архитектура, рәссамнәр иҗаты рухи мәдәниятебезнең аерым тармакларын тәшкил итә. Әмма халкыбызның күңел көзгесенә әверелгән авыз иҗатын (риваять-легендалар, әкиятләр, мәкальләр һәм әйтемнәр, җырлар һәм бәетләр), Галәм һәм Табигать турындагы белемнәрен, мәҗүсилек чорында туган мифологик карашларын, календарь һәм метрологияне (авырлык һәм озынлык үлчәү берәмлекләре), хәтта борынгыдан килә торган гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны,



*Ук кынысы бизәге. XIII–XIV гасырлар.*



*Алтын Урда укчысы. Реконструкция.*



*Алтын Урдада табылган Италия кувшины.*

бәйрәмнәребезне дә онытырга ярамый, чөнки болар барысы да рухи мәдәниятебезнең нигезендә яталар.

**Цивилизацияләр «очрашкан» урын.** XIV йөздә Алтын Урда мәдәниятенең үсеше өчен уңай шартлар барлыкка килә. Бу мәдәниятне тудыруда күп кенә ил һәм халык вәкилләре катнаша. Алтын Урда дәүләтендә, бигрәк тә Түбән Идел буйларында, шәһәрләр торгызу башлангач, бирегә монголлар тарафыннан буйсындырылган илләрдән күпсанлы оста һәм һөнәрчеләр, акыл ияләре, коллар китерелә. Аларның һәрберсе, җирле халыкларның традицияләрен дәвам итеп, яңа мәдәният барлыкка китерүгә үз өлешләрен кертәләр. Алтын Урда ханнары Бәркә, Үзбәк һәм Җанибәк сарай тирәсенә зур галимнәрне, шагыйрьләрне, дин белгечләрен җәлеп итәргә омтылалар. XIX гасыр татар тарихчысы Шиһабетдин Мәрҗани сүзләренә карaганда, Бәркә янында «күпсанлы ихтирамга лаеклы кешеләр һәм бөек галимнәр туплана, һәм ул алар белән бергә мәҗлесләрдә катнаша, чәй артында эштән буш сәгатьләрен үткәрә, аларның зирәк фикерләренә колак сала».

Башка халыкларның мәдәни казанышларына сәүдә элемтәләре аша да юл ачыла. Нәтиҗәдә, Алтын Урда мәдәнияте төрле мәдәниятләр кушылмасыннан гыйбарәт үзенчәлекле күренеш буларак кабул ителә. Биредә гарәп, фарсы, кытай, төрки цивилизацияләре «очрашкан». Кытай һәм Урта Азия сәнгатенә хас алымнар, мәсәлән, алтын-көмештән эшләнгән бизәнүәйберләрендә, керамик эшләнмәләргә төшерелгән сурәтләрдә ачык чагыла. Шәһәр төзелеше һәм архитектура казанышлары Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләре



*Сарайдагы Җәмигъ мәчетенә Сүриядән кайтарылган лампа.*

*Каләм савыты һәм җиз каләм, каен тузына язылган шигырь.*



һәм Идел Болгары осталары ирешкәннәргә нигезләнә.

**Алтын Урдада мәгърифәт үсеше.** Җучи Олысында башлыча төрки халыклар яшәсә дә, Батый хан идарә иткән чорда монгол теле дәүләтнең рәсми теле булып саналган. Ләкин ул тиздән үзенең әһәмиятен, тоткан урынын хәтта югары даирәләрдә дә югалта. XIII гасыр ахырларында ук хәзерге татар теленә якын булган Идел буе төрки теле Җучи Олысы халыкларының сөйләм һәм әдәби теленә генә түгел, дәүләтнең рәсми теленә дә әверелә. Төркичә-гарәпчә, төркичә-русча сүзлекләр, аеруча 1303 елда төзелгән «Кодекс куманикус» – латинча-фарсыча-кыпчакча (төркичә)-немецча сүзлек – төрки телнең абруйлы халыкара телләр дәрәҗәсенә күтәрелүен раслыйлар. Бу телдә хан ярлыклары, эш кәгазьләре, әдәби әсәрләр, гыйльми хезмәтләр языла. Мәгариф тә төрки тел кысаларында үсеш ала. Күп галимнәр һәм шагыйрьләр берничә телне белгән һәм үз әсәрләрен төрки, гарәп, фарсы телләрендә язганнар. Әмма язма мәдәният, нигездә, хәзерге татар теленә бик якын булган төрки (кыпчак) телендә үсеш алган. Аксөякләр генә түгел, күп кенә «кара



*Гарәп язулы дивар бизәге.*

халык» та (Алтын Урдада гади халыкны шулай атаганнар) укый-яза белгән. Бизәнү һәм көнкүреш әйберләрендәге күпсанлы язмалар шул хакта сөйли.

Сарай, Кырым, Болгар һәм башка шәһәрләрдә мәктәп һәм мәдрәсәләр ачыла. Язуда гарәп хәрефләре кулланылган. Алтын Урда кешеләре камыштан һәм каурыйдан ясалган каләмнәр белән кәгазьгә язганнар. Каләмнәрне сөяктән һәм бронза, җиз, корыч ише металлдан да эшләгәннәр. Балчыктан, бронзадан матур итеп ясалган кара савытлары археологик казу эшләре вакытында еш табыла.

Урда халкының күпчелегенең укый-яза белүләре аларның өйдә дә, урамда да, хәтта зиратларда да укырга тиешле, үзенә атап язылган язулы әйберләр белән һәрдаим очрашып торулары белән бәйле. Хуҗасына сәламәтлек, дан-шөһрәт, бәхет теләп, ул даими куллана торган савыт-сабаларга, беләзек-йөзекләргә, көзгеләргә, орчык башларына, йозакларга, кара савытларына язганнар. Мәчетләрнең, башка җәмәгать биналарының гөмбәзләрен, колонналарын, ишек өсләрен, зиратлардагы кабер ташларын матур итеп язылган Коръән сурәләре, Шәрык язучыларының гыйбрәтле сүзләре белән бизәгәннәр.

**Мәктәп һәм мәдрәсәләр**. Мәчетләр каршында балалар һәм яшүсмерләр өчен башлангыч уку йортлары – мәктәпләр эшләп килгән. Сарайда һәм Алтын Урданың башка эре шәһәрләрендә дәүләт хисабына яши торган махсус мәдрәсәләр – югары уку йортлары да булган. Шулар арасыннан, мәсәлән, Кырымның Солхат шәһәрендәге Үзбәк хан мәдрәсәсе матурлыгы белән генә түгел, ә уку-укыту алымнарының югары дәрәҗәдә куелышы, күп кенә дөньяви фәннәр укытылуы белән дә башкаларыннан аерылып торган.

Алтын Урданың югары уку йортларын тәмамлаган иң талантлы яшьләр, кулларына күренекле зыялылардан белем алуларын раслаучы таныклыкларын (аттестат) тотып, чит илләргә, бигрәк тә Мисыр, Сүрия һәм башка гарәп илләренең атаклы фән учакларына юл алганнар. Биредә алар мөселман дөньясында шөһрәт казанган мәшһүр галимнәр кул астында өстәмә белем алып, чын галимнәр булып, кире туган якларына әйләнеп кайтканнар.

**Фән үсеше.** Озын-озак дәверләр буена тормыш тәҗрибәсе нигезендә тупланган белемнәрнең фәннилеккә, профессиональлеккә якынлашуы Болгар илендә әле монгол яуларына кадәр үк башлана. Дәүләтнең уңышлы яшәеше, икътисади алгарышы өчен кирәк булган фәннәр үсеше Алтын Урда чорында да дәвам итә. Эчке һәм тышкы сәүдәдә, һөнәрчелектә, төзелештә, салым-налог системасында һәм хуҗалыкның башка тармакларында математик белемнәргә, химия, астрономия, геодезия, география кебек фәннәргә ихтыяҗ арта. Дәүләтнең рәсми идеологиясен барлыкка китерүдә, әлбәттә,



*Фарсы шигыре язылган чынаяк кирпеч.*

тарих һәм ислам дине белемнәренә таянганнар.

Югарыда санап кителгән фән өлкәләрендә эшләүче Алтын Урда галимнәренең исеме, кызганычка каршы, язма документларда сакланып калмаган. Әмма бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән катлаулы архитектура корылмалары, дәүләтнең акча-авырлык системасында килеп чыккан төрле үзгәрешләр (реформалар), һөнәрчелекнең пыяла ясау, кара һәм төсле металлургия тармакларындагы уңышлары турыдан-туры математикадагы, химиядәге җитди казанышлар белән бәйле.

Алтын Урда шәһәрләрен казыганда табылган почмак үлчәү приборлары – астролябия, горизонт өстеннән күк җисемнәренең биеклеген үлчәү өчен кирәкле җайланмалар – квадрантлар Ислам дөньясында иң популяр саналган астрономия фәненең үсеше турында сөйли. Шунысы кызык: Сарай шәһәрендә торып иҗат иткән атаклы шагыйрь Сәйф Сараи үзенең «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәрендә, бик гади һәм аңлаешлы итеп, егетнең кыз тирәсендә бөтерелеп йөрүен Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүе белән чагыштыра. Ә бит мәшһүр астроном Николай Коперник Галәмнең гелиоцентрик системасын (Җирнең һәм башка планеталарның Кояш тирәсендә хәрәкәтләнүен) ике гасырдан соң гына исбатлап бирә. Алтын Урдада исә бу турыда инде күптән белгәннәр һәм аны ачыш дип тә санамаганнар.

Медицина белеме үсеш кичерә. Бу чорда Борһанетдин Ибраһим Йосыф әл-Болгари трактатлары киң тарала. Шулай ук Мосулда яшәп иҗат иткән болгар табибы Таҗетдин ибне Юнысның «Зур тирйак» һ.б. медицинага караган хезмәтләре булуы билгеле.

Алтын Урда мәдәнияте тормышның төрле даирәләрендә ачык чагылыш тапкан. Әмма аның чәчәк ату чоры озакка бармый, ул бары тик XIV йөзнең беренче яртысында гына була.

## Котб (XIII – XIV гасырның уртасы).
## Хосрәү вә Ширин (1342)

[...] Кызык юктыр коелмас бер чәчәктин,
Вә максатка җитәрсең барсаң әкрен:
Каты акса, күперне су җимертә,
Син акрын түз – мәкер бар һәр җиңелдә.
Буразнага игенче салса орлык,
Күңелгә ул сала шунда сабырлык.
Ашыккан тиз арыр, йөгреп юл алмас,
Кем акрын сөрсә юл, барыр вә талмас.
Кем алтмыш батман ансат күтәрелсә,
Бик артык йөкләсәң дә аңа нәрсә?
Югары тот башыңны, салма юкка,
Көяз хистән дә төшмә сарылыкка.
Сабыр итсәң, бәхет-дәүләт кылыр кяр,
Сагынып ул, синең өчен булыр зар.
[...] Әгәр төшсә бер эш – фикреңне тупла.
Хаталык ихтималын да онытма.
Чаманы бел һәр囑 эштә, кемлегеңне,
Чигенергә әзер тот үз чигеңне.
Таты булмас, әгәр аш булса тозсыз,
Кызык булмас, шулай ук булса шыр тоз.
Югалтма һич тә син чама хисеңне,
Кара һәр эштә хәлне һәм көчеңне.
Ятагыңа карап суз син аякны,
Югыйсә дөнья тиз орыр таякны.
Лаф орма төп һөнәреңнән чыгып та:
Ни белсен чыптачы алтынчылыкта?
Мәкаль бардыр һөнәрмәннәр телендә:
Шикәрче сөйләмәс балан турында.
Нәтиҗә шул ки: ашма мәртәбәңнән,
Тыныч торган азаттыр төрле гамьнән. [...]

# АЛТЫН УРДАДА ТОРМЫШ-КӨНКҮРЕШ ҺӘМ АРХИТЕКТУРА ҮСЕШЕ

Алтын Урда дала, урман, таулар, диңгез һәм елгаларны колачлаган, эссе һәм суык һава торышы хөкем сөргән, ягъни төрле ландшафт һәм климат үзенчәлекләренә ия булган гаять зур җирләрне биләгән. Әлбәттә, географик шартлар халыкның көнкүрешенә, алып барган хуҗалык ысулларына зур тәэсир ясаган. Шулай да, Алтын Урданың үз халкы – төрки-татарлар турында сүз йөрткәндә гадәттә ике төрле көнкүрешне күздә тоталар.

Беренчесе – күчмә тормыш белән яшәү. Күчмәннәр, гадәттә, далада, зур тирмә-йортларда, терлекчелек белән көн күргәннәр, сарык, кәҗә, сыер, дөя һәм ат асраганнар. Ат көтүе дала кешесенең төп байлыгы булган. Атлары никадәр күбрәк булса, ул шулкадәр баерак саналган.

Күчмән тормышының тагын бер үзенчәлеге шунда, ул һәрвакыт ат белән бәйле булганлыктан, илнең төп гаскәр көчен дә нәкъ менә алар тәшкил иткәннәр. Алтын Урда күп илләр белән сату-алу иткән. Чыганаклардан күренгәнчә, алар атларны күбесенчә ерак Һиндстанга илтеп сатканнар.

Утрак тормышлы халыклар еш кына күчмәннәрне, кыргый хайваннарга тиңләштереп, бернинди тәртип белмәгән, кануннарга буйсынмыйча, буталчык тормышта яшәүчеләр дип уйлаганнар. Бу чыннан да шулай булганмы соң? Күчмә тормыш дала буйлап теләсә ничек,



*Татарлар далада күченә. XIX гасыр гравюрасы.*



*Турсык.*

теләсә кайда мәгънәсез күченеп йөрү түгел. Күчмәннәр ханнарның махсус әмере буенча сулыклар тирәсендә күчеп йөргәннәр. Күчену тәгәл бер маршрут буенча барган. Бу турыдагы мәгълүматлар риваятьләрдә сакланган, хан ярлыкларында да беркетелгән. Көтүлекләрнең махсус төрләре булган: җәйләү һәм кышлаулар, якын һәм ерак көтүлекләр, яшь терлекләр өчен яки кытлык елларында куллану өчен махсус хәстәрләнгән көтүлекләр һ.б.

Ыругларның кайберләре – «сул кул», кайсылары исә «уң кул» булып саналган. Шуңа карап алар көтүлек һәм җәйләү җирләренә ия булганнар (күрше ыруг җәйләүләренә керү тыелган). Сугыш вакытында да шул бүленеш сакланып калган – һәр кабиләнең хан гаскәрендә ун яки сул канатта (флангта) үз урыны булган. Алтын Урданың һәр олысы үз эчендә тәртип урнаштырган. Көтүләр җәйләүләрдән әйләнеп кайткан вакытка кышкы көтүлекләрдә җир инде ял итеп, яңа мул үлән белән капланган була. Шулай итеп, табигать цикллары белән тыгыз бәйләнештә яшәгән күчмәннәр җирне, табигатьне саклаганнар.

Дала халкы терлекчелек белән генә чикләнмәгән, төрле эшләнмәләр дә ясаган, хезмәт һәм сугыш кораллары әзерләгән, киез әйберләр, келәмнәр суккан, кием-салым, аяк киемнәре теккән, тире эшкәрткән, савыт-саба ясаган.

Күчмәннәр терлекчелектән тыш аучылык белән дә шөгыльләнгәннәр. Алар ит һәм сөт ризыклары, кыш айла-



*Ияр.*




*Бөек Ефәк юлында кәрван. Шәрык миниатюрасы.*

рында нигездә сарык ите һәм ауланган җәнлек итләре белән тукланганнар, кымыз һәм итле (өреле) шулпа эчкәннәр. Җәй көннәрендә күчмәннәрнең төп ризыгы эремчек, корт, кымыз булган. Итне нәзек итеп турап киптергәннәр һәм һәм кайнар суга салып аш пешергәннәр, кыздырган иткә исләре китмәгән. Кымыз көндәлек кулланылышта булса да, бик кадерле эчемлек саналган. Кымызның иң яхшысы «кара кымыз» дип аталган һәм бик кадерле кунакларга гына куелган.

Алтын Урда ханнары, билгеле булганча, күпчелек вакытларын шәһәрләрдә түгел, ә күчмә урдада үткәргәннәр. Бу урдалар үзләре шәһәрләрне хәтерләткәннәр, әмма бер урыннан икенчесенә күчерелеп торганнар. Күчмәннәрне утрак тормышка күчерү әкрен барган. Шәһәрләр төзелүгә карамастан, Алтын Урда күчмәннәре дала тормышларын саклап калырга тырышканнар. Бары тик дәүләт эше, сәүдә итү омтылышы гына күчмәннәрне утрак тормышка этәргән.

Тормыш-көнкүреш алып баруның икенче ысулы – ул утраклык. Утрак тормышта яшәүчеләрнең тору урыны авыл һәм шәһәрләрдә булган. Утрак тормыш күбрәк Алтын Урданың көнбатышына – Урта Идел буйларына хас булган. Әлбәттә, монда да күчмәннәр яшәгән, әмма бу территориядә шәһәрләр саны арту утрак тормышка күчүне тизләткән. Авыл халкының төп шөгыле игенчелек булган. Алтын Урда читкә зур күләмдә иген саткан. Генуя һәм Венеция кораблары Урдадан ташыган иген бөтен Европаны тәэмин итәргә җиткән. Иген ташулар туктатылганда, Европада хәтта ачлык башланган очраклар да булган.

**Шәһәрләр**. Алтын Урда шәһәрләре тарих фәнендә бер феномен буларак карала. Төп административ үзәк булып ханнар яшәгән Урда саналган. Алтын Урда шәһәрләре урта гасыр сәнәгать үзәкләре буларак танылган. Шәһәрләрдә һөнәрчелек үскән, сәүдә эше гөрләгән. Бөек географик ачышлар ясалып, диңгез-океан юллары ачылганчы,



*Көпчәкле хан тирмәсе. Реконструкция.*

мәшһүр Ефәк юлы бөтен Евразияне тәэмин иткән. Бөек Ефәк юлының төп тармаклары Алтын Урда җирләре аша үткән. Шуңа күрә бу шәһәрләр транзит сәүдәсен тәэмин итү вазыйфасын да башкарган.

**Һөнәрчелек**. Әлбәттә, һөнәрчелек дәүләт һәм халык тормышында бик зур роль уйнаган. Бигрәк тә савыт-саба, төрле кораллар, кирәк-ярак һ.б. күп төрле товарлар җитештерелгән. Шәһәрләр бик төзек һәм алдан уйланылып, билгеле бер план буенча төзелгән. Шәһәр халкы Урта гасырлар өчен бик уңай шартларда яшәгән, моны археологик чыганаклар да исбатлый. Нәтиҗәдә халыкның гомер озынлыгы арта. Әлбәттә, бу күренеш Алтын Урданың чәчәк аткан чорына карый. Шәһәр халкы, күчмәннәрдән аермалы буларак, ит һәм сөт ризыклары белән генә тукланмаган. Аларның табыннарында ипи (күбрәк арыштан) һәм бакча җимешләре дә булган.

Тагын балыкчылык бик алга киткән. Балыкчылык белән Каспий, Азак, Арал, Кара диңгезләрдә һәм Идел, Җаек, Үзи, Дон, Чулман кебек зур елгаларда шөгыльләнгәннәр.

Базарлар шәһәр үзәгенә якын җирдә урнашкан, алар янында кәрвансарайлар тезелеп киткән. Шәһәрләрдә мәчетләр күп төзелгән. XVII гасырда төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби, Сарайдагы мәчет хәрабәсен күреп соклана һәм мондый матур һәм мәһабәт бинаны бер илдә дә күргәне булмавын искәртә. Башка динне тотучыларга аерым бистәләр бүлеп бирелгән, алар монда үзләре теләгәнчә иркен яши алганнар, чиркәүләр төзегәннәр, аерым зиратлар тотканнар.

Чит ил сәяхәтчеләре Алтын Урда шәһәрләренә сокланып караганнар. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Гарәбшаһ татарларның төркиләр арасында иң матур телле һәм курку белмәс кешеләр, бик оста җайдаклар һәм төз укчылар булулары турында язып калдырган.


**Архитектура үсеше.** Бу чорда татар архитектура мәдәнияте шул территориядә яшәүче халыклар һәм яулап алучылар алып килгән кытай, монгол, уйгыр традицияләренә нигезләнеп формалаша. Болгар архитектурасы Харәзем, Кавказ, Кырым төзелеш мәдәнияте белән берлектә аның төп нигезен тәшкил иткән.

Тирмә, көймәле арба һәм чатыр – болар төркиләрнең меңьеллык күчмә торaклары. Шунда күчмә халыкларның йөзләрчә буыннары туган, яшәгән, хезмәт иткән һәм вафат булган. Төрки телләрдә «юрт» (йорт) сүзе кеше яшәгән өйне генә түгел, бөтен илне дә аңлаткан. Дәүләтнең рус елъязмаларындагы атамасы да (Алтын Урда) борынгы күчмәннәр традициясен чагылдыра: монголларда башта ханның күчмә йорты, төгәлрәк әйткәндә, Чыңгыз ханның зиннәтле бәйрәм чатыры «Алтын Урда» дип, ә соңрак Чыңгыз нәселеннән чыккан ханнарның (Чыңгызиларның) йортлары да шулай аталган.

Күчмәннәр яшәгән тирмә-йортларның сүтелә һәм сүтелми торганнары булган. Байлыгына күрә тирмәләрне ак яки кара күн белән каплый торган булганнар. Диаметры 5-6 метр булган тирмәләрне тиз арада сүтеп җыярга мөмкин булган. Аларда урта хәллеләр һәм ярлылар яшәгән. Тирмә эчендә кирәк-ярак, көнкүреш әйберләре, сугыш кораллары сакланган, стеналарга келәмнәр эленгән. Уртада ризык әзерләү һәм җылыту өчен учак янган. Тирмә эчке яктан үрелгән чыпталар, матур тасмалар, кайвакытта төрле төстәге чуклар белән бизәлгән. Идәнгә келәмнәр һәм иләнгән сарык тиреләре җәелгән. Тирмә эчтән ирләр һәм хатын-кызлар ягына бүленгән. Аларның зурлыклары да төрлечә. Гадәти тирмәләрдә 10 кеше яшәгән, ә сарай-тирмәләр күпкә зуррак булган. Мәсәлән, монголларның соңгы ханы тирмәсенә 500 ләп кеше сыйган. Туй һәм матәм йолаларын үткәрү өчен махсус ритуал тирмәләр дә корылган. Туй тирмәләре аеруча нәзакәтле итеп эшләнгән, үзенең бизәкләр күплеге һәм ачык төсләр муллыгы белән аерылып торган. Хан чатыры Кытай богдыханы (императоры) бүләк иткән алтын чатма белән тышланган була. Бәркә ханның Итил (Идел) елгасы буенда урнашкан йортында



*Үзбәк хан кызы Түрәбәк ханым төрбәсе. Үргәнеч.*



*Җучилар төрбәсе.*

Мисыр Солтаны Бәйбарс илчеләрен кабул иткән вакытта катнашкан гарәп сәяхәтчеләренең тасвирламалары хәбәр иткәнчә, Бәркә хан ак киез һәм ефәк тукымалар белән капланган зур, мәһабәт чатырда утырган. Ул кимендә 100 кеше сыйдырышлы булган. Чатыр диварлары буенча урындыклар тезелеп киткән, аларга 50 яки 60 лап әмир урнашкан.

Төркиләрнең ханнар һәм хөрмәтле кешеләр кабере өстенә мәңгелек йорт – төрбә торгызу да очраклы гына түгел. Мондый күчмә тирмәләрне хәтерләткән биналар агачтан, балчыктан яки таштан эшләнгән. Төрбәләр төрки мәдәният, ислам цивилизациясе белән катнашы булган барлык урыннарда (Мисырда, Иранда, Әфганстанда, Һиндстанда, Урта Азиядә, Кавказда, Кече Азиядә, Идел буенда, Себердә) очрыйлар.

Татар өйләре, меңьеллык утрак тормыш тәҗрибәсе булуга карамастан, XX гасырга кадәр диварлардагы тукымалары, сандыклары, өелеп куелган юрган-мендәрләре, идәндәге келәмнәре, тәбәнәк ян сәкеләре, савыт-саба шүрлекләре белән күчмә торак рәвешен саклап калганнар. Алтын Урда дәверендә татар торак йорты нәкъ менә шулай булгандыр дип фаразларга мөмкин.

**Күчмә халыкларның архитектура-декоратив (бизәү) сәнгате.** Бизәкләр һәм сюжетлы рәсем үрнәкләре күчмә тормышның барлык өлкәләрендә чагылыш тапкан. Төркиләрнең орнамент (бизәк төшерү) сәнгатендә чиксезлек һәм мәңгелек хәрәкәт мотивлары белән сугарылган. Алар һәрбер композицияне кайма белән уратып алганнар, ә тәгәрмәч һәм кояш символы композиция очында куелган. Бизәкләрдә без су һәм кылганлы дала өстендәге дулкыннарны, үрелгән үсемлек сабакларын, кар һәм минерал кристалларын, ай, кояш, йолдызлар һәм кометаларны күрәбез. Төрки-татар орнаментларының катлаулы үрелешләрендә лалә, лотос, ирис һәм башка бик күп чәчәкләр, үсемлекләр урын алган. Шулай ук бизәкләрдә хайваннар дөньясы (бөркетләр, тау кәҗәләре, барслар, еланнар) да күзәтелә.

Геометрик бизәкләр – күчмәлек сәнгатендә иң төп темаларның берсе. Аларның иксез-чиксез күптөрлелеге таң калдыра. Бу бизәкләр тукымадан, күннән, камыштан, саламнан, талдан үрелгән, ташка,

балчыкка уелган. Ислам дине йогынтысы белән алар тагын да киңрәк тарала, математик гармониягә нигезләнгән геометрик бизәкләр барлыкка килгән.

Ислам сәнгатенең мөһим өлеше булып «Аллаһ» сүзе торган. Ул каллиграфия сәнгатендә чагылган һәм арабеска сәнгате белән берлектә зәвыклы Ислам дөньясы символына әверелгән.

Күчмә төркиләрнең орнаментлары, башта гамәли-декоратив сәнгать буларак туып, Алтын Урда биналарының алгы һәм эчке якларына күчерелә. Шулай итеп, нәфис мәдәниятнең хәзерге көннәргә кадәр саклаган үзенчәлекле төрки стиле барлыкка килгән.

**Монументаль стиль.** Күчмә архитектурадан тыш, төрки традицияләр мәһабәт корылмалар төзүдә дә шактый зур үсеш алган. Таштан саклану корылмалары, мунчалар, сарайлар, мәчетләр, төрбәләр төзелгән. Аларның архитектурасында Идел буе, Урта Азия, Кавказ, Кырым, Төркия төзелеш сәнгате йогынтысы да сизелә. Татар архитектурасы да шулай ук башка илләр сәнгате үсешенә дә йогынты ясаган.

**Сәлҗүкләр стиле.** Утрак төрки-мөселман стиленең беренчесе һәм X–XIII гасырларда мөселман архитектурасында әйдәп баручы стильләрнең берсенә әйләнгән сәлҗүкләр стиле X йөздә хәзерге Төркия территориясендә барлыкка килгән.





*Мозаика үрнәкләре.*

Анда гарәп, грек, әрмән төзелеш сәнгате үзенчәлекләре һәм күчмә стиль формаларын турыдан-туры кабатлау да хас. Сәлҗүк стилендәге биналар гади геометрик фигуралардан – турыпочмаклы параллелепипедлар, цилиндрлар, конуслардан һ.б. төзелгән. Аларның гөмбәз һәм түбә-чатырлары тирмәләрне хәтерләтә. Ә мәдрәсәләр, сырхауханәләр, мәчетләр, кәрван-сарайлар ишекләренең уеп ясалган детальләре келәмнәрнең, тукы-



*Чынаяк кирпечләр.*

ма чыбылдыкларның, чуклы һәм үрелгән бизәкле пәрдәләрнең күчермәләрен хәтерләтә.

Сәлҗүк стиле урта гасырлардагы башка төрки дәүләтләр (Идел Болгары, Харәзем, Караханидлар, Газнәвиләр, Алтын Урда, мәмлүкләр Мисыры) архитектурасына да үтеп кергән.

**Урданың Болгар Олысы.** Монгол яулап алуларыннан соң, башкала Болгарга күчерелә. Казан, Иске Казан, Кашан, Җүкәтау, Тубылгытау һ.б. шәһәрләр дә акрынлап күтәрелә башлый. Болгарның оста төзүчеләре һәм һөнәрчеләре Урта гасыр Идел буе мәдәниятенең нәкъ уртасында калганнар. Ә Болгар шәһәре берникадәр вакыт Җучи Олысының мәркәзенә әверелә һәм аннан соңгы йөзьеллыкларда да үзенең әһәмиятен югалтмый. XIII–XIV йөзләргә караган корылмаларны төзү техникасында Урта Азия, Азәрбайҗан, Иран һәм Төркия осталарының йогынтысы сизелә.

Археологлар диварлар белән әйләндереп алынган һәм чатлары манаралар белән ныгытылган феодал сарайларын, зур җәмәгать мунчалары – хәммамнарны тапканнар. Эре шәһәрләрдә сүүткәргеч һәм канализация булган, юлларга, мәйданнарга таш һәм агач түшәлгән. Күп манаралы мәчетләр җирле архитектура стиленең үзенчәлегенә әверелгән. Шуларның берсе – Болгардагы әл-Җәмигъ әл-Кәбир мәчете. Калган таш мәчетләр бер яки ике манаралы гөмбәзле корылмалар рвәешендә төзелгәннәр, ә агач мәчетләрнең түбәсеннән бер манара күтәрелгән. Таш биналар манаралар, өскормалар, гөмбәзләр, очлыклар (шпильләр), төрле-төрле янкорылмалар, галереялар, балконнар белән тулыландырылган.

Гадәти кешеләр яшәгән бистәләрдә агач йортлар салынган яки күчмә тирмәләр корылган.

Урта Идел буенда Алтын Урданың яңа шәһәрләре XIII гасыр урталарында гына калка. Урданың мәркәзе булган Сарай шәһәре Актүбә елгасы ярында салынган. Аны мәдәни үсешкә ия булган башка төбәк архитекторлары – Харәзем, Иран, Болгар, Кавказ осталары төзегән. Сарай Бату шәһәре ул вакытлар өчен гаять зур, 36 кв. км. мәйданны биләгән һәм анда 100 меңнән артык кеше яшәгән. Европада зурлыгы буенча Сарайга тиң шәһәрләр булмаган. Әйтик, XIII гасырда Рим

*Болгардагы Җәмигъ мәчете һәм төрбә. Н.Халит реконструкциясе.*




халкы – 35 мең, ә XIV гасырдагы Парижда 58 мең кеше исәпләнгән.

Сарай шәһәрендә сарай, мәчет, мәдрәсә манаралары, төрбә гөмбәзләре игътибарны аеруча җәлеп иткән. Алар янәшәсендә бер катлы йортлардан торган кварталлар сузылган. Һәр мәхәллә уртасында зур булмаган мәчет һәм чәйханә эшләгән. Җәмәгать мунчалары шәһәр кешеләренең ял итү һәм аралашу урыны булган. Шәһәрдә һәм аның әйләнә-тирәсендәге манаралы диварлар белән әйләндереп алынган аксөяк утарлары зур булмаган нығытмаларны хәтерләткән. Батый хан салган Бөек Таш йорт гөмбәзе алтын булган дигән хәбәрләр дә бар. Башкалада җылылык, суүткәргеч, канализация системалары, тирә-яктагы сусаклагычлардагы су биеклеген көйләп тора торган катлаулы гидротехник корылмалар да булган. Җучи Олысының яңа мәркәзе – Сарай-Бәркә (Сарай әл-Җәдид) шәһәре дә шул ук Актүбә елгасының югарырак сул ярында урнашкан булган. Андагы Хан сарае Алтынбаш шулай ук алтын гөмбәзле булган дип яза Ибне Баттута. Яңа төзелгән шәһәрләр дә күп була: Гөлстан, Сарайчык, Ак Сарай, Ак Кирмән, Ак Мәчет, Олуг Мәчет, Аргамаклы Сарай һ.б. XIV йөздә Җучи Олысының гаять зур территориясендә төрле зурлыктагы 150 ләп шәһәр исәпләнгән. Бу вакытларга монда күрше Иран йогынтысы белән формалашкан һәм элеккеге архитектура традицияләрен үзендә туплаган үзенчәлекле Алтын Урда стиле барлыкка килгән. Шул вакытта ук кытай, монгол һ.б. мәдәни традицияләрнең элементлары да килеп кергән. Монументаль



*Болгардагы Җәмәгать мунчасы. Реконструкция.*



*Алтын Урдада хан сараеның эчке күренеше. Н.Халит реконструкциясе.*

биналар үсемлек, геометрик һәм каллиграфик бизәкләр төшерелгән аксыл-зәңгәр, алтынсу төстәге чынаяк кирпечләр белән тышланган. Бинаның эчке ягы алтын йөгертелгән мозаик һәм майолик паннолар белән бизәлгән, идәнгә чынаяк кирпеч түшәлгән. Сарайларда тантана заллары, ял итү һәм юыну бүлмәләре булган, ә ишегалдында бакчалар үскән, фонтаннар су бөркегән.

**Харәзем.** Алтын Урда чорыннан Харәзем территориясендә берничә төрбә һәм Тимер Котлыгъ хан (? – 1399) манарасы сакланып калган. Шулар арасында иң әйбәт сакланганы – Үзбәк хан (1312–1242) кызы Түрәбәк ханым төрбәсе. Үзенең матурлыгы һәм нәфислеге белән сокландырган бу корылма эчтән һәм тыштан бик бай мозаика белән бизәкләнгән, конуссыман гөмбәзенә зәңгәр чынаяк плитәләр түшәлгән. Тимер Котлыгъ манарасы – Урта Азиядәге иң биек корылма. Аның биеклеге 60 метрга җитә. Ул кирпечкә уеп төшерелгән куфи язуы һәм унсигез әйләнешле бизәкләр белән каймаланган.



*Тимер Котлыгъ манарасы, Куня-Үргәнеч.*



*Түрәбәк ханым төрбәсенең гөмбәзе.*

Алтын Урда чорында Кырым архитектурасы җирле традицияләргә нигезләнгән. Кырымның далалы җирләрендә – күчмә традицияләр (тирмәләр), ә таулы урыннарда утрак традицияләр (агач, балконлы һәм галереяле таш йортлар) өстенлек итә. Ул дәверләрдән Кырымда Бакчасарай шәһәре һәм аның тирә-юнендәге берничә таш мәчет һәм төрбә сакланып калган. Алар бик әйбәтләп тасланган ташлардан төзелгән, эчтән штукатураланган, тыштан ташларга уеп бизәкләр төшерелгән. Бизәкләү стиле гади, әмма нәфис. Төрбәгә уеп ясалган бизәкләрдә сәлҗүк стиленә хас булган алымнар, үрелгән бизәкләр сакланган.

## АЛТЫН УРДАДА ИСЛАМ һӘМ ДИНИ ВӘЗГЫЯТЬ

Алтын Урда төзелгән заманнарда ук ислам зур роль уйнаган. Бигрәк тә Бәркә хан идарә иткәндә Алтын Урда бәйсез дәүләткә әверелә һәм көннән-көн мөселманлаша бара. Алтын Урдада дин тоту иреге саклана, барлык диннәр дә бер төрле хокукка ия була. Ислам дине Алтын Урда составына кергән Урта Идел, Кавказ, Харәзем төбәкләрендә инде күптән традицион дингә әверелгән була. Шулай ук мөселман булмаган төркиләр һәм монголлар арасында ислам динен таратыр өчен дә мөселман галимнәре, шәех-суфилар күп көч куялар. Әлбәттә, Алтын Урда алып барган тышкы һәм эчке сәясәт тә ислам дине таралуга сәбәп була.

1312–1313 елларда Үзбәк хан ислам динен рәсми дәүләт дине дип игълан итә. Алтын Урда шәһәрләре ислам дөньясының танылган мәркәзләренә әверелә. Сарай, Болгар, Харәзем, Кырым, Хаҗитархан, Гөлстан һәм башка шәһәрләр нәкъ менә мөселман шәһәрләре буларак корыла. Алтын Урдада 150 дән артык шәһәр була. Ханнар бу шәһәрләргә танылган ислам галимнәрен, белгечләрне һәм укытучы-мөдәррисләрне җыйганнар. Шулай ук Алтын Урдада мәшһүр мәдрәсәләр дә эшләгән, аларның шәкертләре киләчәктә үзләрендә генә түгел,



*Манараның каллиграфик бизәлеше.*

ә ерак мөселман илләрендә дә галим булып танылганнар.

Алтын Урдада яшәгән мәшһүр ислам галимнәре арасындам Ногман әл-Харәзми, Мохтар әз-Заһиди, Котб әр-Рази, шәех әт-Тафтазани, шәех Җәләл әд-Дин, Алә әд-Дин әс-Сараи һ.б.ны атарга мөмкин.

Алтын Урда чорында язылып, бүгенге көннәргә кадәр килеп җиткән дини әсәрләр арасында Мәхмүд Болгариның «Нәхҗел-фәрадис» («Оҗмаһларга ачык юл») һәм Хисам Кятибның «Җөмҗөмә солтан» әсәрләрен атарга мөмкин.

Алтын Урдадагы Ислам галимнәре башка мөселман илләре белән тыгыз элемтәдә торган. Алар кайбер мәшһүр авторлар, танылган ислам галимнәре белән хәтта бәхәскә дә кергәннәр, аларга җавап та язганнар. Мәсәлән Рукн әд-Дин Сарайда Ибне Гарәбинең «Гакыл асылташлары» әсәренә шәрехнамәләр язган. Ә Әбүбәкер Каландар Мөхәммәд исә мәшһүр Җәлалетдин Руминың «Мәснәви»енә җавап йөзеннән «Каландар-намә» исемле әсәрен иҗат иткән.

Халык үз илен «Олуг Олыс», ягъни «Бөек дәүләт» дип атаган, шулай ук гарәпчәләштереп «Урда-и-могаззам» дип тә йөрткәннәр. Ил атамасының гарәп варианты башка мөселман илләре вәкилләре алдында әйтелгән, шуңа күрә Алтын Урда акчаларында «Урдаи-могаззам» сүзен еш очратырга була.

**Дини вәзгыять.** Билгеле булганча, Алтын Урда составында христиан җирләре дә булган, шундыйлардан без кайбер рус җирләрен, Кавказ һәм Кырымны атый алабыз. Алтын Урдада мәҗүсиләрне, христаннарны, әрмәннәрне, төрле Европа милләтләрен, буддизм, яһүд дине вәкилләрен очратырга мөмкин булган. Аларга үз диннәрен тоту иреге бирелгән. Гыйбадәтханәләре эшләгән. Мәсәлән, Сарайда православие епархиясе булган. Яһүди һәм католикларның дини оешмалары эшләгән. Аларга миссионерлык эше дә рөхсәт ителгән. Башка диннәрне кимсетүчене үлем җәзасы көткән. Әлеге сәясәт нәтиҗәсендә Алтын Урдада тынычлык хөкем сөргән.



*Әрмән кабер ташы. Алтын Урда.*

XIV гасырның урталарында инде Алтын Урданы чын мөселман дәүләте дип атарга мөмкин. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Гарәбшаһ башкала турында: «Сарай фән үзәгенә әйләнә, кыска вакытта анда шулкадәр галимнәр һәм данлыклы кешеләр, сүз осталары һәм башка зыялылар, атаклы кешеләр җыелды ки, андыйлар бөтен Мисырның зур шәһәр вә авылларында да юк иде», – дип язып калдырган. Алтын Урдада Исламның төрле мәзһәб вәкилләре яшәсә дә, төп халык хәнәфи мәзһәбендә булган. Сарай шәһәрендә Җәмигь мәчетләрнең берсе шафигый мәзһәбенә караган. Ибне Баттута, мәсәлән, хәнәфи һәм шафигый казыйларын күргән. Шигыйлар да очраган. Ислам дине халыкны тагын да ныграк туплаган, татар халкының милләт булып оешуына этәргеч ясаган.



*Несториан кабер ташы. Алтын Урда. XIV гасыр.*

Әлбәттә, ислам дине гади халык, аеруча күчмәннәр арасында тиз таралмаган, әмма, археологик чыганаклардан күренгәнчә, мөселманлашу процессы дәвам иткән. Ханнар әле XV гасырда да динне ныгыту өчен тырышканнар.

**Суфичылык.** Алтын Урдада суфичылык көчле була, чөнки ханнар исламны суфилардан кабул иткән, шул ук вакытта суфичылык бөтен ислам дөнясында киң таралган. Әлбәттә, суфичылык укыту-



*Суфи. Реконструкция.*

чыдан укучыга, мөршидтән мөридкә күчәргә тиеш. Алтын Урда суфичылык әдәбияты Әхмәд Йәсәви (XII гасыр) һәм Нәҗметдин Кубра (XII гасыр) хәзрәтләре корган тарикатьләргә, ягъни юнәлешләргә таянган.

Суфилар Алтын Урда ханнарын актив рәвештә исламга өндәгәннәр. Җузҗани әйтүенчә, Бәркә хannан тыш, Бату хан (1207–1256) да яшерен рәвештә ислам кабул итә. Туда-Мәнгү хан (? – 1287), мәсәлән, бөтенләй суфига әверелә һәм Тулабуга үсеп җиткәч, аңа үзе теләп тәхетне тапшыра. Тукта хан да (якынча 1270–1312/13) мөселманлыкны кабул итә.

Суфи һәм дәрвишләр Алтын Урда ханнары ярлыкларында еш искә алына. Алар дәүләт тарафыннан яклана.



*Диварның каллиграфик бизәлеше.*

XV гасырда Алтын Урда дәүләтенең таркалу процессы башлана һәм ул акрынлап татар ханлыкларына бүленеп бетә.

**Алтын Урда ислам диненә корылган дәүләткә әверелә, анда дин белән бергә мөселман мәдәнияте дә тарала. Бу дәүләт төрле милләт һәм дин вәкилләренең тыныч һәм тату яшәү үрнәгенә әверелә.**

# УРТА ГАСЫРЛАРДА ТАТАРЛАР ҺӘМ ЕВРАЗИЯ ХАЛЫКЛАРЫ АРАСЫНДАГЫ МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАР

Төрле телләрдә сөйләшүче кабиләләрдән торган Алтын Урда халкын башка халыклар гомумиләштереп «татарлар» дип атаганнар. Алар Европа һәм Азия халыклары белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр. Әлбәттә, бу халыкларның бер-берсенә йогынтысы гаять зур булган.

**Рус җирләре белән бәйләнешләр.** 1230–1240 еллардан соң рус кенәзлекләренең күпчелеге Чыңгызилар дәүләте кул астына эләгә. Рус кенәзләре Батый хан тарафыннан җиңелеп, мөстәкыйльлекләрен югалтсалар да, үз хакимлекләрен саклап калалар. Әмма алар үз җирләрендә хакимлек итү хокукын ханнардан сорап алырга тиеш булалар. Чөнки Монгол империясе башында торучы Чыңгыз хан һәм аның варислары иң югары хаким дип саналган. Шулай итеп рус җирләре Бату ханга буйсынган.

Бу, әлбәттә, борынгы рус шәһәрләре өчен хас булган үзидарә традициясен бетергән. Хан кулыннан алынган ярлыкка таянып, рус кенәзләре үз җирләрендә ханнар кебек үк тулы хокуклы хөкемдарлар булганнар.

Әмма идарә итү системасында яңалыклар да күзәтелә. Рус кенәзләре эшләрен күзәтеп бару өчен ханнар, империянең буйсындырылган башка җирләрендәге кебек үк, гарәп һәм фарсы түрәләрен





*Рус патшаларының тажы («Мономах башлыгы). Алтын Урда сәнгате үрнәге.*



*Иван IVнең гарәп һәм рус язмалы очлымы.*



чакырганнар. Алар рус җирләренә Гарәп хәлифәлегендә һәм Иранда кулланылган идарә итү ысулларын алып килгәннәр.

**Рус телендә төрки һәм гарәп-фарсы алынмалары.** Урта гасырларда рус теленә кереп калган күпсанлы махсус атамалар бүген дә саклана. Мәсәлән, «деньга» (тәнкә), «дефтер» (дәфтәр), «киличей» (илче), «алафа» (хезмәт хакы, бүләк) сүзләре гарәп һәм фарсы телләреннән килгән. Еш кына гарәп-фарсы сүзләре төрки телләр аркылы кергән, мәсәлән «казначей» (татар. «казначы», гарәп. «хәзинә» сүзеннән).

Шәрык илләрендәге кебек ук Рус дәүләт идарәсенең нигезендә дә казна (хәзинә) торган. Анда салым түләүчеләрнең исемнәре язылган документлар сакланган, аларны «дефтери» дип атаганнар.

Мәскәү патшасы сарае хезмәтчеләре арасында сорнайчы («сурначей») һәм думбырачы («домрачей»), ягъни сорнайда һәм думбырада уйнаучылар да искә алына.

Рус теленә татар теленнән «таможня» (салым алып, тамга төшерелә торган урын), «тьма» (төмән, ун мең), ярлык, казна, хозяин, башмак, булат һ.б. сүзләр дә үтеп кергән.

Бөтен монгол дәүләте җирләрендә, шул исәптән Рус җирләрендә дә, гади халык «ям» йөкләмәсен үтәргә тиеш булган («ям» – почта станцияләрен ямчылар, ям чабучылар («ямщиклар»), атлар, олаулар белән тәэмин итү). Алтын Урда чорында төзелгән бу система Россиядә XIX гасырга кадәр сакланып, үз вазыйфасын уңышлы үтәп килгән. Ясакны тулысынча җыю өчен, Алтын Урда вәкилләре тарафыннан 1245 елда рус җирләрендә беренче халык исәбен алу уздырылган.



*Иван IIIнең гарәп язмалы тәңкәсе.*



*Дмитрий Донскойның Туктамыш хан исеме белән суктырылган тәңкәсе.*

Рус кенәзләренең Урда белән булган мөнәсәбәтләре ярлык алу һәм ясак түләү белән генә чикләнмәгән. Алар Урданың эчке сәясәтендә актив катнашканнар. Үзләре Урдага еш йөреп, анда вакытлыча яшәгәннәр дә. Мәсәлән, Мәскәүнең бөек кенәзе Иван Калита 1332–1339 елларда Сарайга биш тапкыр сәяхәт кылган, үзенең идарә чорының яртысын ул я Урдада, я анда бару-кайту юлында уздырган.

Үзләренең ханга тугрылыклы булып калуын раслау өчен, кенәзләр үз улларын ханга «әманәт» (тугрылык әманәте; рус. аманат) итеп җибәргәннәр. Сарайда күп еллар буе яшәп, анда тәрбияләнеп, татар асксөякләре белән дуслашып, хәтта ханнар белән туганлашып та киткәннәр. Мәскәү кенәзе Юрий Данилович Үзбәк ханның сеңлесе Кунчакка өйләнә, Смоленск бөек кенәзе Фёдор да Урда ханнары белән туганлаша, ул үз кенәзлегендә бик сирәк булып, күбрәк хан сараенда яши, ханның иң якын кешесе, яраткан кияве була. Хәтта аның ике улы да Урдада туа.

Рус кенәзләре, соңрак патшаларының казначылары булып еш кына татарлар хезмәт иткәннәр. Елъязмаларда



*Болгарда табылган Алтын Урда тәңкәләре.*



*Прокудин-Горский гербы.*



*Карамзиннар гербы.*

беренче казначылар арасында Остафий Аракчеев исеме искә алына, аның татар Уракчыев нәселеннән булуы һәм нәсел тамгасын да куллануы билгеле. Урдадан чыгып, рус кенәзләренә хезмәткә кергән күп кенә татар морзалары, угланнары (уланнар), бәкләр (биләр) шактый рус аксөякләренең нәселләренә нигез салганнар (Мещерский, Юсупов, Енгалычев, Сабуров, Карамзин, Глинский, Урусовлар һ.б.). Патша Борис Годунов нәселе дә татар биенә килеп тоташа. Ул заманда нәселеңне татар биләре, «татар кенәзләре»ннән алып бару аеруча абруйлы саналган.

Әмма ханнар белән кенәзләр арасында дуслык кына хөкем сөргән дип әйтү дөрес булмас иде. Ике як та шәхси мөнәсәбәтләрне сәяси көрәштә кулланырга тырышкан. Еш кына кенәзләр үз дошманнарын хан алдында яманлап, аларны үтерткәннәр, яисә ханнан



*Юсуповлар гербы.*



*Глинскийларның татар тамгасы төшерегән гербы.*

гаскәр сорап күрше кенәзлекләргә яу чапканнар. Урдада чуалышлар башланганда хан тәхетенә дәгъва итүчеләр үзара көрәштә рус гаскәрләрен дә кулланганнар.



*Татар сырган бишмәте (рус. тегиляй) кигән рус хәрбиләре. Рәссам А.Висковатов.*

**Хәрби система**. Мәскәү дәүләтенең бөтен хәрби көчләре Урдадагы тәртипләргә карап төзелгән: атлы һәм җәяүле гаскәрнең тактикасы, стратегиясе, кораллары татар йогынтысын кичергән.

Рус кенәзләре җайдакларын чыдам һәм җитез дала атларына утыртып, төрки-татар укларыннан атарга өйрәткәннәр, сугышчылар өсләренә сырган татар бишмәтен («тегиляй») киеп, кулларына затлы булаттан ясалган кәкре кылычлар тотканнар. Беренче утлы коралларны да рус сугышчылары Шәрыктан алганнар, алар «тюфяк» һәм «мултух» дип аталганнар. Рус телендәге хәрби темага кагылышлы күпсанлы төрки-татар атамалары (атаман, караул, колчан, есаул, бунчук, булат, нагайка) Алтын Урда чорларында ук кергән. Рус гаскәрендә «Ура!» дип кычкыру традициясе дә шул чорларда башланган.




*Герберштейн рус киемендә.*

Рус теленә килеп кергән төрки-татар сүзләре хәрби өлкә белән генә чикләнми (базар, товар, таможня, алтын, безмен (бизмән), амбар, аршин (аршын), кирпич (кирпеч), тюфяк (түшәк), диван, утюг (үтүк), карандаш, каланча һ.б.).

Кием һәм тукыма исемнәре арасында дә шәркый алынмалар күп (кафтан, халат, шуба, тулуп, сарафан, армяк, башлык, калита (калта) һ.б.). Рус кенәзләре киемнәре тасвирламаларында «пояс золот с капторгами» дигән юллар очрый. 1517 һәм 1526 елларда Россиядә сәяхәт иткән Германия илчесе Сигизмунд Герберштейн русларның, бигрәк тә аксөякләренең, киемнәре татарныкына охшавы («төймәләре генә башка якка каптырыла») турында яза.



*Изге Георгий иконасы. Алтын Урда. XIV гасыр.*

Рус кенәзлекләре Алтын Урда карамагында булган чор рус әдәбиятына да йогынты ясаган. Фарсы әдәбиятындагы атаклы «Шаһнамә» әсәренең өзекләре рус әдәбиятына татар тәрҗемәсе аркылы «Еруслан Лазаревич турындагы хикәя» булып кергән, анда Рөстәм батыр маҗаралары турында сүз бара. Бу әсәр Илья Муромец турындагы хикәяләргә дә зур йогынты ясый.

**Шәрык илләре белән үзара мөнәсәбәтләр**. Әлбәттә, тел, дин һәм гореф-гадәтләр уртаклыгы Алтын Урдага шәрык илләре белән тирән мәдәни бәйләнешләр урнаштырырга ярдәм итә. Сарайда бөтен мөселман дөньясына мәгълүм танылган галимнәр Котбетдин әр–Рази, Сәид Җамалетдин, Шәех әт-Тафтазани, шулай ук җирле халыктан чыккан күренекле табиб, философ, гарәп теле белгече Мәхмүд Сараи яши. Идел буе төбәгеннән чыккан күп кенә билгеле зыялылар туган җирләреннән



*Гарәп язулы христиан кабер ташы. Алтын Урда. XIV гасыр.*



читтә дан казана: Җамалетдин Йосыф Сараи Тәбриз каласында (Иран) укыта, Шәех Әхмәд Сараи Сүрия һәм Каһирә мәдрәсәләрендә дәрес бирә, Ибн Гарәбшаһ Аксак Тимер тарафыннан Сәмәркандка чакырыла.

Мисырда Идел буеннан килүчеләр аеруча күп була, шуңа күрә дә аларның сөйләме мәмлүкләр арасында әдәби телгә әйләнә. Кыпчак шагыйре әт-Тәнбәкнең (? – 1343) шигъри җыентыгы яки әт-Тафтазаниның риторика буенча китабы төрки телле авторларның гарәп мәдәниятенә керткән зур өлеше буларак бәяләнә.

Киң далаларны, күчмә тормышны сагынып яшәгән мәмлүкләр гарәп архитетурасына төрки элементлар керткәннәр. Мисыр солтаннары Бәйбарс һәм Калавунның, үз акчаларын һәм архитекторларын җибәреп, Кырымда һәм Сарайда мәчет-мәдрәсәләр салдырганлыгы да билгеле. Татар архитектурасында фарсы, сәлҗүк, әрмән, гарәп, итальян архитектуралары йогынтысы күзәтелә.

Византия империясе җирләре нәкъ менә Алтын Урда һәм мәмлүкләр Мисыры арасында «күпер» ролен уйнаган. Христиан дине үзәге булуына карамастан, Византиянең тышкы сәясәте бу ике мөселман иленә якын булган. Алар Илханнар дәүләте (Хулагу хан варислары) белән бергәләп көрәшкәннәр. Әлбәттә, Византия һәм Урда ханнары арасында сугышлар да булган, әмма 1272 елдан соң аларның тышкы сәясәтендәге дәүләт мәнфәгатьләре еш кына уртак була.

Көчсезләнгән Византия императорлары кодрәтле ханнарга буйсынырга мәҗбүр булалар, аларга ясак түлиләр, һәм татар гаскәрләре белән бергә Балкан халыкларына каршы сугышларда катнашалар, ханнар белән туганлашып та китәләр. Нугай бәк, Тукта хан, Үзбәк хан Византия императорлары кызларына өйләнгәннәр. Бәркә хан исә үз кызын Бәйбарс солтанга кияүгә бирә. Ханнар гына түгел, гади татарлар да башка милләт кызларына өйләнгәннәр. Коллар базарында сатылып, Венециягa китерелгән татар кызлары, бай йортларында берничә ел асрауда торганнан соң, Венециянең тулы хокуклы гражданнарына әверелгәннәр.

**Алтын Урда – күпмилләтле, күпдинле дәүләт**. Сарайда яшәгән руслар өчен 1261 елда православие епископлыгы ачыла. Епископлар ханнарга рус кенәзләре арасындагы низагларны туктатырга ярдәм итәләр һәм Византия белән үзара мөнәсәбәтләрне дә ныгыталар. Барлык диннәргә дә бертигез караучы ханнар әрмән чиркәвенә дә, католикларга да Сарайда үз епископлыгын ачарга мөмкинлек бирәләр.

Урданың төрле төбәкләрендә (Болгар, Азак, Маҗар, Казан) әрмән бистәләре урнашкан. Казан каласында ул Казан ханлыгы чорында да сакланып калган. Аларның үз зиратлары, чиркәүләре дә



*Ике телле (гарәп – караим) мөһер. Алтын Урда. XV гасыр.*

булган. Кырымда әрмәннәр аеруча күп яшәгән. Алар сәүдә һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнгән, оста төзүчеләр, ташларны чокып бизәүчеләр булган. Татар шәһәрләрендә яшәгән әрмәннәр татар телен яхшы үзләштергән, мәдәнияте белән танышкан. Алтын Урда таркалганнан соң да әле алар, әрмән әлифбасын кулланып, озак еллар дәвамында төрки-татар телендә рәсми документлар, хатлар, китаплар язганнар.

Урда территориясендә (Кырым, Кавказ, Харәзем, Азак, Кубань буйларында һ.б.) яһүдләр дә яшәгән. Алар, башка милләтләр кебек үк, үз динен, гореф-гадәтләрен ирекле рәвештә тота алганнар. Урдада аларга карата бернинди кимсетү һәм чикләүләр булмаган. Алар үзләре теләгәнчә сәүдә-һөнәр белән шөгыльләнгәннәр, еш кына дәүләт хезмәтендә торганнар, табиб, хаттат, салым җыючы һ.б. вазыйфаларны үтәгәннәр. Алтын Урдада яһүд динен тотканнарның күбесе чыгышлары белән Хәзәр каганлыгы төркиләре була. Аларның токымнарын, караимнарны, бүген дә Кырым һәм Литвада табып була. Алар төрки телләрен һәм яһүд диннәрен саклап яшиләр.

**Урдада фин-угыр халыклары.** Ханнар мәҗүсиләрне дә кысрыклмаганнар. Урта Идел буйларында борынгыдан яшәгән фин-угыр

*Сүрия һәм Мисырдан Алтын Урдага китерелгән пыяла савытлар.*



халыклары үз борынгы ышануларын саклап кала алганнар. Монгол яулары вакытында Идел-Чулман Болгарының бөтен халкы кебек үк, мордва, чирмеш (мари), мажар, удмуртлар һ.б. җирле халыклар зур югалтулар кичергән. Гасырлар буе җайга салынган хуҗалык җимерелгән, сәүдә мөнәсәбәтләре өзелгән, халыкның бер өлеше кырылып, икенчесе монгол гаскәренә алынган. Әмма акрынлап Идел буйларында да тынычлык урнаша барган. Яңа дәүләт составына кергән фин-угыр халыклары да акрынлап тыныч тормышка кайта башлаганнар. Бердәм дәүләт карамагында булу җирле халыкларның мәдәнияте, икътисады, хуҗалыгы һәм сәүдәсе үсешенә этәргеч ясый. Бу чор хәзерге мордва (мукшы һәм эрзя), удмурт һәм мариларның төрле аерым кабиләләр нигезендә, бердәм халыклар булып берләшүенең мөһим бер этабына әверелә. Алтын Урданың аерым бер олысы булып яшәгән мордва халкы, үз мәдәниятен саклап, күрше халыклардан авыл хуҗалыгы һәм һөнәрчелекнең алдынгы алымнарын өйрәнә.




*Европа илләреннән Алтын Урдага китерелгән пыяла савытлар.*

**Европа халыклары белән мөнәсәбәтләр.** Европа халыклары көнчыгыштан килгән монгол яуларына зур курку белән караганнар,



*Билбау бизәкләре. Каффа, Кырым. XIV гасыр.*




*«Кодекс куманикус»ның бер бите.*

аларны грек мифларындагы җәһәннәм «Тартар»дан чыккан кыргый хайваннарга охшаган затлар итеп сурәтләгәннәр. Әмма Монгол дәүләтендә һәм Алтын Урдада булып киткән сәяхәтчеләр язмалары Европа хөкемдарларының бу дәүләтләр белән дипломатик һәм сәүдә мөнәсәбәтләре төзергә омтылуын хәбәр итә. Чөнки инде яулар чоры тәмамланып, Европа илләренең бәйсезлегенә куркыныч янамый башлагач, Европа белән Азия арасындагы сәүдә юлларын үз кулында тоткан татар иле белән хезмәттәшлек ике якка да зур табышлар китергән.

Мондый сәүдә бәйләнешләре Генуя һәм Венеция колонияләре булган Кырым ярымутравында гөрләгән. Әмма итальяннар сәүдә белән генә чикләнмәгәннәр, алар җирле халыкларның телен, гореф-гадәтләрен дә өйрәнгәннәр. Шул өйрәнүләр нәтиҗәсе булып «Кодекс куманикус» җыентыгы төзелгән. Аны Кырымда яшәгән һәм җирле халыкны өйрәнгән миссионерлар язган. Үз эченә 1300 сүзне алган латин-фарсы-кыпчак-немец сүзлегенә күбесенчә сәүдә, сату-алу өчен кирәкле төшенчәләр, мал-туар һ.б. тормыш-көнкүреш кирәк-яракларын белдергән сүзләр кергән. Моннан тыш бу китапка борынгы төрки табышмаклар, кыпчак теленә тәрҗемә ителгән христиан догалары һәм латин язучыларның шигырьләре, вәгазьләр тупланган. Әлеге хезмәт безнең көннәргә кадәр Венециядә сакланып калган.

Литва һәм Польша белән Алтын Урданың үзара мөнәсәбәтләре шактый катлаулы була. Алар Рус дәүләте җирләре өчен еш кына үзара сугышлар алып барганнар, әмма төрле сәяси союзлар төзегән чорлар да булган. Бу илләр арасында илчеләр, сәүдәгәрләр йөргән, халыклар арасында мәдәни багланышлар урнашкан. 1297 елда Аксак Тимердән җиңелгән Туктамыш, бөтен гаиләсе, яраннары, гаскәре белән Урдадан качып, Литва кенәзе Витовт тирәсенә сыенырга мәҗбүр була. Алар Трокай шәһәре янында төпләнеп калалар. Алтын

*Литва татарлары мәчете.*



Урда таркалгач, аларга башка татарлар да килеп кушыла. Дистәләгән мең Литва һәм Польша татары гасырлар буе яңа ватаннарына тугры хезмәт иткән, хәрби хезмәттә батырлыклар күрсәткән, Литва һәм Польша мәдәниятенә һәм тарихына зур өлеш керткән. Польша һәм Литва татарларыннан күпсанлы атаклы генераллар, язучылар, галимнәр һәм башка күренекле кешеләр чыккан. Шуларның берсе – күпсанлы тарихи романнар авторы, Польшаның иң атаклы язучысы, Нобель премиясе иясе Генрик Сенкевич (1846–1916).

Алтын Урда дәүләте, аның халкы, мәдәнияте күрше халыклар тарихында һәм мәдәниятендә тирән эз калдырган. Моны украин халык авыз иҗаты әсәрләрендә күрергә мөмкин. Әлеге әсәрләрдә батыр Казак Мамайга дан җырлана.

**Алтын Урда чорында сәүдә һәм сәяси мөнәсәбәтләр аркылы рус, итальян, француз, немец, инглиз телләренә дистәләгән төрки-татар сүзләре кергән. Татар һәм башка халыклар мәдәниятләре бер-берсен баетып, тулыландырып торган.**



*Польша татарлары байраклары.*
*Варшава хәрби тарих музее.*

# «Кодекс Куманикус» (XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башы)

**Табышмаклар**

Этеп-этеп ыргалмас, эчендәге чайкалмас (Ул – уру [ашлык саклау базы])

Ак көймәнең [тирмәнең] авызы юк. (Ул – йомырка).

Синдә, миндә – юк,
Сеңгир [биек] тауда – юк,
Үтәли ташта [мәгарәдә] – юк,
Кыпчакта – юк. (Ул – кош сөте диң).

Узун агач башында
Олы битив битидим [хат яздым],
Кемсән овлу килгәй дип,
Кемсән тырып сакладым. (Ул – кармак илә балык).

Биш башлы илче килер. (Ул – итәктән биш бармак багар [күренер]).

**Әйтемнәр**

Ким мәга берса, мен дә агар бергәйем; ким мәга бермәсә, мен дә агар бермәм.

Әгәр тоз-туфрак кояштан мең мең кырла ярык [тапкыр яктырак] болса иде, Тәңренең яктылыгына кара[ганда] караңгыдыр.

**Кыпчак телен тизрәк өйрәнү турында дога**

Мен сүюнүб әйтер эдим сизгә, Теңри сүзин тил билмәс, тылмач йук. Йалваруңыз Теңригә меним үчүн, Теңри маңа берсин андый көңүл, ким мен терче тагы йакшы тил үюренгәймен, сизгә йакшы Теңри сөз айткаймен, не кимесе(н) бозык үчүн.

# АЛТЫН УРДАНЫҢ ТАРКАЛУЫ һӘМ ТАТАР ХАНЛЫКЛАРЫ ОЕШУ

1342 елда Үзбәк хан үлә. Шушы вакыттан Алтын Урдада дистә елларга сузылган ызгыш-талашлар чоры башлана. Ике ел гына идарә иткән Бирдебәк хан үлгәч (1359), Алтын Урда бетүгә йөз тота. Җучиларның һәрберсе, көч туплаганнан соң, үз олысында үзе генә идарә итәргә тели.

Ханнар хакимияте дә тотрыклылыгын югалта. Үзбәк ханнан соң 15 ел Җанибәк идарә итә. Әмма ул яшерен дошманнары тарафыннан үтерелә. Аяусыз Бирдебәк хан да шундый ук язмышка дучар була.

Алтын Урдада фетнә-чуалышлар башланып китә. Бирдебәк үтерелгәннән соң, Алтын Урда төбәгендә егерме елда 25 хан алмашына. Рус елъязмачылары сүзләренчә, бу «Великая замятня» (бөек болгавыр заман) була.

Әлеге фетнә-чуалышлар Алтын Урда әмире Мамай гамәлләре нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ул ханнар исеменнән акча суга, берничә тапкыр Сарай-әл-Җәдидне яулап ала. Мамай Алтын Урданың Иделдән көнчыгышта булган өлешен буйсындыра. Идел аръягында исә Сарай башлыклары хакимлек итә.

Җучи варислары арасындагы ызгыш-талашлардан җирле феодаллар файдалана. XIV гасырның 60 нчы еллары башында Алтын Урдадан Болгар Олысы, Хаҗитархан (Әстерхан), Харәзем аерылып чыга башлый. Сарай хакимиятеннән Җүкәтау, Кашан һәм Казан читләшә.



*Җанибәк хан. Каталан Атласыннан, 1375 ел.*

Таркалган Болгар җирләре яклаучысыз кала. 60 нчы еллар башыннан аларга рус кенәзләре һөҗүм ясый башлый. Ишкәкле суднолар-ушкуйларда елга буйлап хәрәкәт итүче новгородлылар отрядлары («ушкуйниклар») да талау һөҗүмнәре оештыра. Ул отрядлар боярлар тарафыннан төньяктагы җирләрне яулап алу, Идел һәм Чулманда сәүдә-талау походлары өчен төзелә.



*Туктамыш хан. М.Горелик реконструкциясе.*

Рус кенәзлекләренең Алтын Урдага бәйлелеге кими. Мәскәү-Владимир кенәзе Дмитрий Иванович (Донской) Урдага ясак түләвен туктата. Мамайның рус кенәзлекләрен яңадан буйсындырырга омтылышлары аны Куликово кырында (1380 ел) тар-мар итү белән тәмамлана. Мамай Кафага (Феодосия) кача, шунда ук үтерелә дә.

XIV гасырның икенче яртысыннан Алтын Урда көчсезләнә башлый. Аның чәчәк ату чоры уза.

Мамайның җиңелүеннән файдаланып, Алтын Урда тәхетенә Туктамыш хан утыра. Ул күп елларга сузылган ызгыш-талашларны бетерүгә ирешә. Озакка булмаса да, Урда тагын бердәм дәүләткә әверелә. Рус дәүләте яңадан ясак түли башлый.

**Аксак Тимер яулары.** Туктамыш хан Урта Азиянең гаскәр һәм дәүләт башлыгы Тимер (Аксак Тимер) ярдәмендә Алтын Урданы берләштерүгә ирешә. Башта алар бергәләп эш итәләр. Әмма соңрак Туктамыш, аның биләмәләренә ия булырга теләп, үзенең хакименә каршы көрәш башлый. Тимер бәк исә Җучи Олысын тулысынча үзенә буйсындырырга тели.

Туктамыш һәм Тимер гаскәрләре ике тапкыр – 1391 һәм 1395 елларда – зур сугышта очраша. Икесендә дә Туктамыш җиңелә. 1395 елгы сугыштан соң Тимер отрядлары Болгар, Сарай, Әстерхан шәһәрләрен һәм Кырымдагы сәүдә үзәкләрен талый һәм җимерә. Күп шәһәрләрнең халкы үтерелә һәм коллыкка алып кителә. «Дәште [кыпчак] кешеләре фәкыйрьлеккә һәм бөлгенлеккә төште», – дип яза шул заман кешесе. Алтын Урданың икътисади үзәкләре Аксак Тимер тарафыннан җимерелгәннән соң, әле кайчан гына бик көчле булган бу дәүләт таркала башлый. Шәһәрләрнең, сәүдәнең һәм, гомумән, икътисади тормышның моннан соңгы җимерелүе нигездә Бөек ефәк юлының көньякка – Урта Азиягә һәм Иранга – Тимериләр империя-

*Аксак Тимер гаскәре.*
*Реконструкция.*



се территориясенә күченүе белән бәйле була. Халыкара сәүдә туктала, кәрван юллары эшләми башлый. Шәһәрләрдә һөнәрчелек эше кискен сүлпәнәя.

Алтын Урда үзенең бөтен мөмкинлекләрен җигеп, элеккеге көчен кире кайтарырга тырышып карый. Шадибәк хан вакытында ук татарлар элек югалткан җирләрен, шул исәптән күп кенә шәһәрләрне өлешчә торгызуга ирешәләр. Әмма шуның белән бергә меңләгән тыныч халык Аксак Тимер тарафыннан юк ителә, коллыка алына. 1395 елның азагында берничә елга сузылган коточкыч ачлык башлана. Меңләгән кеше гомерен юк иткән төрле куркыныч авырулар чыга. 1405 елда гына бераз басыла төшкән чума чире бигрәк тә куркыныч була. Моннан соң да ул әле берничә тапкырлар кабатлана.

Котылу чарасы эзләп, күпләр илдән китә. Алар арасында бөтен бер кабиләләр дә, аерым олысларда яшәүчеләр дә була. Бу вакыйгаларның шаһиты булган Ибне Гарәбшаһ түбәндәгеләрне язып калдырган: «Аларның [татарларның] күпчелеге Тимер белән китте, аңа буйсынды һәм аның тоткынлыгында булды. Исәпсез-хисапсыз икенче бер өлеше «румлыларга һәм русларга китте», ә калган өлеше «бөлгенлеккә төште».

Кайчандыр бердәм дәүләт булган территориядә бәйсез урдалар хасыйл була. Аларның башлыклары арасында хакимият һәм җир өчен көрәш башланып китә.

Аксак Тимер киткәннән соң, Алтын Урда территориясендә татар феодалларының төп ике сәяси төркеме барлыкка килә. Алар арасында хакимият өчен җитди көрәш башлана. Партияләрнең берсе дә әле аерым дәүләт төзергә тырышлык куймый. Киресенчә, һәрбер төркем илнең бөтенлеген саклау өчен тырыша. Беренче төркемнең башында – Идегәй, ә икенчесендә Туктамыш яклылар була.

Алтын Урда инде беркайчан да бердәмлеккә ирешмәс кебек тоела. Әмма шулчак Идегәй әмир йолдыз булып кабына. Башта ул Алтын Урда гаскәре башлыгы була, ә аннары Литвага качкан Туктамыш һәм Литва кенәзе Витовтның берләштерелгән көчләрен тар-мар итә. 1399 елда Идегәй Алтын Урда хөкемдары (хан түгел) булуга ирешә. Аңа Җучиның элеккеге барлык олыслары буйсына. Бу инде Алтын Урданың соңгы тапкыр берләшүе була. Ун елдан артык анда чагыштырмача тынычлык саклана.

**Татар ханлыклары оешу.** XIV гасырның икенче яртысында Алтын Урдада күп ызгыш-талашлар һәм хакимият өчен туктаусыз көрәш башлана.

Бу көрәш нәтиҗәсендә 1419 елда Идегәй үтерелә, бердәм дәүләт таркала. XV гасырның 30-60 нчы елларында Алтын Урда җирләрендә һәрберсе аерым үзәккә ия булган дүрт ханлык: Кырым, Әстерхан, Казан һәм Себер ханлыклары, шулай ук ике урда – Нугай Урдасы һәм Олуг Урда барлыкка килә. Җучи Олысының көнчыгыш өлешендә – Үзбәк һәм Казакъ ханлыклары оеша башлый.

**Алтын Урда ике гасыр дәвамында яши. Шушы чорда Болгар җирләре аның составында була. Аның җирләрендә бердәм татар этносы формалаша. Алтын Урда тарихы татар халкы тарихының әһәмиятле бер өлешенә әверелә. Алтын Урда мирасы барлык татар ханлыклары, шулай ук Урта Азиядәге үзбәкләр һәм казакъ җөзләре, күпмедер дәрәҗәдә рус кенәзлекләре өчен дә уртак була.**



*Хәрабәләр. Рәссам Р.Заһидуллин.*

## Кунак бабай риваяте

Моннан күп еллар элек Аксак Тимер Туктамыш ханга каршы сугыш ачкан. Туктамыш хан җиңелгән. Аксак Тимер әсирлеккә алган кешеләр арасында Кунак исемле бер җырчы да була. Ул заманында Туктамыш тарафыннан төрмәгә ябылуга хөкем ителгән булган. Аксак Тимер шул җырчыны үзен мактап җырларга өндәгән, хәтта үтерү белән дә куркытып караган. Әмма җырчы риза булмаган. Ул болай дип җырлаган:

Илне йоткан Туктамыш,
Мактаганым юк аны.
Син дә илне йоткан хан –
Мактый алмыйм мин сине.

Шуннан соң Аксак Тимер җырчының башын кистергән.

## «Кунак бабай җыруы»

Йөз туксан биш яшь яшәдем,
Азу тешләрем ашадым.
Күпне күреп, күпне белеп,
Гомер сөргән карт мин.
Иделдә үтте тугыз хан,
Җаекта үтте сигез хан;
Шул ханнарның барысын да
Күреп белгән карт мин.
Илне йоткан Туймас хан,
Юмарт булган Исәк хан;
Берсен сүгеп, берсен мактап
Күп җырлаган карт мин.
Энҗү дәрьяң киң дәрьядыр,
Бәнгиз дәрьяң мул дәрьядыр,
Мактыйм дисәм, телем йөрми –
Туры сүзле карт мин.
Туып-үскән, суын эчкән,
Идел белән Җаегыма,
Кайтарсагыз ни була, дип,
Башын игән карт мин.
Идел белән Җаегымда
Ярлы-ябак илкәем.
Үлә калсам, ак тәнемне
Күмәр дигән карт мин.

# Янмый торган кыз (легенда)

Үзенең дошманы – Туктамышның артыннан килгәндә Тамерлан (Аксак Тимер) Ука елгасының урта агымы буйларына килеп җитә һәм монда аның армиясен, бөтенләй тар-мар итеп, Иделгә кадәр куып китә. Шөһрәтле Болгар шәһәрен Тамерлан утка тота һәм кешеләрен кылычтан үткәрә. Җиңүчеләр дәрәҗәгә дә, картлыкка яки яшьлеккә дә карамыйча, мондагы кешеләрне һич тә кызганмыйлар, бөтенесен дә диярлек юк итәләр, калган хатын-кызлар һәм балалар әсирлеккә алына.

Болгарларда ул вакытта патшалык иткән Габдулла хан, үзенең шәһәр саклап кала алмавын аңлагач, гаиләсе һәм кайбер якыннары белән, шәһәрнең иң нык таш пулатларыннан исәпләнгән хөкем палатасына кереп бикләнә. Шәһәргә кергәч, җиңүчеләр бу бинаны бүрәнәләр һәм янучы матдәләр белән әйләндереп алалар да яндыралар. Габдулла хан һәм аның белән бергә бинага бикләнгәннәр, ханның кызыннан башкалары, барысы да һәлак булалар.

Болгарлар ханның бу кызын, үзенең акыллылыгы һәм яхшылыгы өчен, изге дип атаганнар, гадәттән тыш матурлыгы өчен аңа «хур кызы» дигән исем биргәннәр. Тәңре бу гадел кызны газаплап үтерергә ирек бирмәгән.

Хөкем палатасы янганнан соң, җиңүчеләр аның эченә керсәләр, хан кызының болгарларда изге кеше дип йөртелгән Хисаметдин исемле мулланың ак киеме итәгендә янмыйча утырып калганлыгын күрәләр. Үлгән ханның матур һәм акыллы бу кызын, аның кече энесе белән, Тамерлан үзенең пайтәхете булган Сәмәркандка алып китә...

Канлы һәлакәттән Габдулла ханның бу кызы гына исән калмый: кызның ике туганы Җалимбик һәм Алтынбик тә исән калалар... Габдулла ханның якыннары аның бу улларын Кама елгасының аръягына урлап качалар, сугыш беткәнгә кадәр алар шунда, артык куркыныч булмаган җирдә, качып торырга тиеш булалар. Ләкин, сугышлар тынса да, бу ханзадәләргә үзләренең туган шәһәрләренә әйләнеп кайтырга туры килмәгән. Биредә аларның аталарының токымы бөтенләй өзелә.

Качып котылган патша уллары бу чорга кадәр инде яшәп килгән Казанга килеп урнашалар. Шулай ук Казанга тар-мар ителгән Болгардан һәм аның тирәләреннән шактый күп кешеләр күчеп киләләр.

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ – УРТА ИДЕЛДӘ ЯҢА ДӘҮЛӘТ

Алтын Урданың таркалуы нәтиҗәсендә «Казан ханлыгы» дигән яңа дәүләт барлыкка килә.

Бу вакытта Болгар шәһәре үзенең элеккеге көчен һәм Болгар җирләре үзәге ролен бөтенләй югалта. Сәүдә итү тулысынча диярлек туктатыла.

Болгарлар төньякка таба күченергә мәҗбүр булалар.

XV гасыр башында Казанны «Яңа Болгар» (Болгар әл-Җәдид) дип атый башлыйлар. «Болгар иленә килгән күпсанлы фетнәләр һәм бәлаләр сәбәпле, аның элеккеге тыныч, мул тормышы кими башлый, әкренләп андый тормыш Казанга күчә; ул болгарларның элеккеге бөеклегенең варисына әверелә», – дип язган татар тарихчысы Ш.Мәрҗани.

XIV–XV гасырлар чигендә Алтын Урдадан аерымланган болгар билекләре арасында беренче урынны Казан билеге алып тора.

Үз биләмәләреннән куылган Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәд хан да Казанга күз сала. Ул шушы шәһәрне алырга һәм аны яңа дәүләтнең үзәгенә әверелдерергә тели. Әмма Олуг Мөхәммәд хан үз ниятләрен тормышка ашыра алганмы-юкмы – төгәл билгеле түгел.

Олуг Мөхәммәд ханның улы Мәхмүднең Казанны алуы турында күбрәк мәгълүматлар саклanган. Ул вакытта Казан белән Болгар бие Алимбәк (Галимбәк) идарә итә. Мәхмүд 1445 елда Алимбәкне үтерә һәм хөкемдарларның яңа династиясен башлап җибәрә. Рус елъязмаларының берсендә ул вакыйга турында болай диелә: «Ә патша Мамутәк [Мәхмүд] Кормыштан килде дә Казанны алды, ә Казан



*Борынгы Казан. Күзәтчеләр кире кайта. Рәссам Р.Заһидуллин.*

кенәзе Азыйны [Алимбәкне] үтерде, үзе Казанга патша булды, һәм шуннан Казан патшалыгы башланып китте».

Шулай итеп, XV йөзнең беренче яртысында Урта Иделдә яңа дәүләт – Казан ханлыгы барлыкка килә.

Казан ханлыгы башлыча элеккеге Идел-Чулман Болгар дәүләте территориясен били. Көнчыгышта аның җирләре – Агыйдел, көнбатышта Сура һәм Ветлуга елгаларына кадәр сузыла. Төньякта алар Югары Чулманнан башланып, көньякта Чирмешән тамагына кадәр җирләрне колачлый.

Идел елгасы шушы илнең үзәк районнарын ике якка – Болын һәм Тау якларына бүлә. Болын ягына – сул, тәбәнәк яр буе җирләре, Тау ягына Иделнең уң, биек ярлары буенда урнашкан җирләр керә.

Көньяк-көнчыгышта – Нугай Урдасы, көньякта Әстерхан һәм Кырым ханлыклары Казан ханлыгының күршеләре булган. Көнбатышта үсеп килүче Мәскәү дәүләте урнашкан.

Идел Болгарыннан аермалы буларак, халык Чулманнан төньяктагы җирләрдә күбрәк тупланә. Алар Казан арты, шулай ук Зөя елгасы районнарында урнашалар. Монда йөзләгән авыллар барлыкка килә.

Ханлыкның көньяк (Чулманнан көньякта урнашкан) җирләре буш кала диярлек. Алар нугайлар һөҗүме өчен ачык тора. Табигый саклану чарасы булган урманлы урыннарда гына кайбер авыллар очрый. Шул борынгы чорлардан аларның Норлат, Шәрбән, Алпар, Әлки дигән исемнәре сакланып калган.

Шәһәр тибындагы зур торак урыннар, гадәттә, елга ярлары буена салына. Лаеш, Алабуга, Тәтеш, Сембер (хәзерге Ульяновск), Сарытау (хәзерге Саратов) шундыйлардан. Күп шәһәр һәм авыллар элеккеге болгар авыллары урынын били.

Казан ханлыгының төп халкы татарлар була, аларны хәзер



*Мәхмүд хан. Баш сөяге буенча реконструкция.*



*Казан таҗы.*



*Казан ханнары тәхете. Реконструкция.*


«казанлылар» дип атый башлыйлар. Монда шулай ук чирмешләр (марилар), чуашлар, удмуртлар, мордва һәм башкортлар да яши. Моннан тыш, ханлык территориясендә элекке Җучи Олысының башка төбәкләреннән чыккан кешеләр дә аз булмаган.

Озак вакыт бергә тормыш иткән халыклар үзара катнаша. Нәтиҗәдә яңа халык – Казан татарлары яки Идел буе татарлары – барлыкка килә. «Татар» исеме исә шушы төбәкнең төп халкына икеөч гасырдан соң гына берегеп кала.

Казан ханлыгы яңа халык – Казан яки Идел буе татарларының формалашу урынына әверелә.

Казан ханлыгы феодаль дәүләт була. Аның белән Җучилар династиясеннән булган ханнар идарә итә. Аның дәүләт төзелеше дә Алтын Урданыкына охшаш булуы очраклы түгел.

Дәүләт башында хан тора. Аның эшенә «диван» дип аталган феодаллар шурасы контрольлек итә. Диван дүрт карачыдан гыйбарәт булган. Ханлыкның иң атаклы нәселләреннән булган әмирләрне шулай атаганнар. Ханнарны тәхеткә нәкъ менә карачылар чакыра торган була. Алар салымнар кертү һәм аны сарыф итүне күзәтә, гаскәр белән идарә итә, тышкы сәяси эшләрне алып бара. Дәүләт тормышының иң әһәмиятле мәсьәләләре халык җыелышлары – корылтайларда хәл ителгән.



*Хан сайлау. Рәссам Р.Заһидуллин.*

Карачылардан соң әмирләр һәм биләр (бәкләр) килгән. Әмирләр һәм биләр нигездә эре җир биләүчеләр була. Бер үк вакытта алар гаскәр башлыклары да булып тора.

Феодаль баскычта бер басмага түбәндәрәк – морзалар һәм оланнар тора. Алар әмирләр тарафыннан бирелгән, зур булмаган җир биләмәләренә ия булганнар. Моның өчен алар эре феодал, ягъни үзләренең сюзерены гаскәрендә хезмәт итәргә тиеш булганнар. Феодалларга буйсынган «кара халык» морза һәм оланнарга төрле салымнар түләргә тиеш булган.

Казан ханлыгында мөселман руханилары йогынтысы көчле була. Аларның башлыгы – сәед – Мөхәммәд пәйгамбәр нәселе вәкилләреннән генә сайлап куела алган. Сәед дәүләттә ханнан соң беренче дәрәҗәдәге кеше саналган. Хан аны каршы алырга чыга, аңа баш ия һәм, сәед ат өстендә утырганда, үзе аяк өсте килеш, аның кулын тота торган булган. Хан булмаганда, сәед хөкүмәт башлыгы вазыйфаларын башкарган. Дипломатик хат алышуларда аның исеме һәрчак алда торган.

Казан ханлыгы Алтын Урда традицияләрен дәвам итә – бу чорда да хан тәхетенә бары тик ханзадәләр генә утыра алган.

**Казан ханлыгы халкының хуҗалыгы.** Казанлылар үз хуҗалык эшчәнлекләрендә Алтын Урда традицияләрен дәвам итәләр. Җир сөрү, һөнәрчелек һәм сәүдә аларның төп шөгыльләре була.

Авылларда яшәүчеләр икмәк үстерә, терлек асрый, киек кошлар, җәнлек аулау, балык тоту белән шөгыльләнә. Уңдырышлы туфрак, куе һәм сусыл үләнле көтүлекләр, күп урманнар, мул сулы елгалар

әлеге шөгыльләр өчен яхшы шартлар тудыра.

Ел саен казанлылар бик күп бодай, арыш, арпа һәм тары җыеп ала. Шулай ук карабодай, борчак һәм ясмык уңышы да мул була. Ханлык кешеләре яшелчә һәм җиләк-җимешкә мохтаҗлык белмәгәннәр.



*Билбау каптырмалары.*

Шәһәрләрдә һәм зур авылларда һөнәрчеләр төрле-төрле эшләнмәләр ясый. Металл коючылар һәм тимерчеләр бигрәк тә дан казана. Берәүләре – чуен, тимер коя, ә икенчеләре аннан хезмәт һәм сугыш кораллары, көнкүреш әйберләре чүкеп ясый.

Сугыш кораллары ясаучы осталарга аеруча кадер күрсәткәннәр. Алар корыч пластиналар һәм боҗралар эшләп, алардан көбә кием җыя алганнар. Корал осталары мылтыклар һәм чуен туплар ясарга да өйрәнәләр. Казанлыларның үз кирмәннәрен саклау һәм сугышларга бару өчен кораллары яхшы була.

Чүлмәкчеләр дә оста һөнәрчеләр була. Алар эшләп чыгарган нәфис, матур бизәкле савыт-сабаны казанлылар да, чит ил кунаклары да бик теләп сатып ала.

Казан зәркәнчеләре алтын һәм көмеш осталары буларак дан тота. Аларның эшләнмәләреннән байлар да, гади кешеләр дә файдаланган. Һәрбер яңа хан өчен зәркәнчеләр кыйммәтле өс һәм баш киемнәре, алтын һәм көмештән төрле савытлар һәм тәлинкәләр ясыйлар. XVI гасырның беренче яртысында эшләнгән «Казан таҗы» зәркән сәнгате җәүһәренә әверелә. Ул Мәскәү Кремленың Кораллар палатасында – Россиянең иң өлкән музеенда саклана.



*Казан Кремлендә казу эшләре вакытында табылган зур хәзинәдән көмеш рус тәңкәләре.*

Сатып алучылар еш кына Казан күнчеләрен мактау сүзләре белән искә ала. Алар эшләгән зәвыклы аяк киемнәрен, акча янчыкларын, нык ат дирбияләрен күп илләрдә белгәннәр.

Казан ханлыгында шулай ук төзелеш һөнәрләре дә үсеш ала. Ташчылар хан һәм аның якыннары өчен сокландыгыч гүзәл биналар, биек манаралы мәчетләр сала белгәннәр. Башка осталар төрле төстәге чынаяк кирпечләр һәм ялтыравык йөгертелгән плитәләр ясаганнар, аларны сырлап бизәгәннәр. Бай кешеләр соравы буенча, нәфис бизәкләр һәм гарәп язулары төшереп, кабер ташлары койганнар.

Казан ханлыгы сәүдә иле буларак та танылa. Якын һәм ерак җирләрдән килгән сәүдәгәрләр аны читләтеп уза алмый. Казан Мәскәү Русе һәм Көнбатыш илләре, Кавказ һәм Урта Азия, Себер һәм Иран белән сәүдә бәйләнешләрендә тора.

Һәрбер сәүдәгәр үз товарларын күбрәк һәм тизрәк сату белән кызыксынган. Тире-мех эшләнмәләр аеруча күп табыш китергән. Һәр елны башкаладан ерак булмаган, Иделдәге Сәүдәкунак утравында атаклы Казан ярминкәсе үткәрелә. Анда күн, балавыз, тукыма, тәмләткечләр сатып алырга мөмкин була.

Ярминкәдән соң күп товар төялгән суднолар кире юлга чыга. Казан ханлыгы осталары, һөнәрчеләре, терлекче һәм игенчеләре җитештергән товарлар Мәскәүгә, Польшага, Германиягә, Франциягә юл ала.

**Казан ханлыгының алдынгы хуҗалыгы һәм киң сәүдә элемтәләре булган.**

# КАЗАН ХАНЛЫГЫ МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ МӘГАРИФЕ

Алтын Урда дәүләтенең таркалу сәбәпләре мәгълүм: аерым олыслар, күрше илләр белән бетмәс-төкәнмәс сугышлар, ханнар арасында татулык булмау, хакимият, тәхет өчен көрәш... Мондый шартларда, әлбәттә, Алтын Урда җирләрендә калкып чыккан яңа дәүләтләрнең тернәкләнеп китүе бик авырдан бара. Шуңа күрәдер инде, Казан ханлыгына озак яшәү насыйп булмаган. Бер гасырдан аз гына күбрәк вакытның да (1445–1552 еллар) шактый өлеше Мәскәү Русе белән көрәшкә, хакимияттә утыручы түрәләрнең эчке ызгыш-талашларына сарыф ителгән. Казан тәхетендә утыручы ханнарның барысы да читтән – Касыйм, Кырым, Себер, Әстерхан ханлыкларыннан чакыртылган шәхесләр. Аларның да бер өлешен хан итеп Мәскәү патшалары басымы астында «сайлаганнар». Бер генә хан да, эчке киеренкелек, ызгыш-талашлар сәбәпледер, үз акчасын сугарга өлгерми кала.

Ни генә булмасын, тормыш дәвам иткән. Гади халык – игенчеләр, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр – илнең хуҗалыгын торгызуда, матди байлыгын арттыруда тырышып эшләгәннәр. Һәрхәлдә, Казан ханлыгы икътисади куәте ягыннан шул заманнардагы күрше илләрдән һич тә калышмаган. Алай гына да түгел, Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләренең варисы булган Казан ханлыгының мәдәнияте борынгы традицияләр нигезендә югары үсешкә ирешкән, башкалабыз исә Идел-Урал һәм Себер төбәкләрендә яшәгән күпсанлы төрки-татарларның мәдәни үзәгенә әверелгән.

**Мәгърифәт**. 1517 һәм 1526 нчы елларда Рус дәүләтенә килеп, Мәскәүдә озак кына яшәп киткән Австрия илчесе Сигизмунд Герберштейн Казан татарлары турында: «Алар бүтәннәргә (Идел буенда яшәүче башка халыкларга) караганда аң-белемлерәк – иген игәләр, әйбәт өйләрдә яшиләр, сәүдә итәләр», – дип язып калдырган. Австрия дипломаты, һичшиксез, хаклы: аксөякләр һәм руханилар катлавы гына түгел, хәтта түбәнрәк



*Гарәп язуы төшерелгән җиз кувшин.*



*Ике шагыйрь. Рәссам Н.Хаҗиәхмәтов.*

катлау кешеләре дә, бигрәк тә сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр, укый-яза белгәннәр. XVI гасырның беренче яртысында Мөхәммәд Әмин ханның гаскәр башлыгы Күбәк баһадирга Насыйри атлы бакырчы ясаган бик матур җиз кувшин иң кыйммәтле музей экспонатларыннан санала. Яза белмәсә, үзе ясаган җиз кувшинга ул гарәп хәрефләре белән татар телендә шигъри юллар, фарсы телендә багышлау тексты төшерә алмас иде.

Казан ханлыгы чорыннан дистәләгән кабер ташлары сакланып калган. Алардагы чокып язылган матур, җыйнак һәм тирән мәгънәле җөмләләренең хатасыз булуы шул заман ташчыларның укый-яза белүләре һәм белемле булулары турында сөйли.

Мәчетләр каршында ачылган мәдрәсәләрдә дин гыйлемен дә, тормышта кирәк булачак фән нигезләрен дә өйрәнгәннәр. Язуда гарәп хәрефләре кулланылган. Рәсми, эш кәгазьләре, ярлыклар, китаплар – барысы да гарәп хәрефләре белән язылган. Исеме бүгенге көннәргә килеп җиткән атаклы дин әһеле, дипломат һәм шагыйрь Кол Шәриф Казан кирмәне эчендә урнашкан сигез манаралы мәчетнең имамы гына түгел, ә шул мәчет каршындагы югары уку йортының – мәдрәсәнең мөдәррисе, талантлы шәкертләрнең яраткан остазы да була. Бу шәкертләр, мәдрәсәдә укуларын тәмамлап, мәчет муллалары гына булып китмәгәннәр бит. Нәкъ менә шулар арасыннан хан канцеляриясендә эшли торган белемле сәркатипләр, китап күчерү осталары (хәттатлар), илчеләр сайлап алынган. Шәкертләрнең бер өлеше язучылар, шагыйрьләр, галимнәр булып өлгергән. Мәдрәсәләрдә белем алучы шәкертләр өчен бөтен шартлар тудырылган. Китапханәләр эшләгән. Дини һәм дөньяви фәннәргә караган китапларны сәүдә кәрваннары белән хәтта ерак Шәрык илләреннән кайтартканнар. 1552 елда Казан алынганнан соң Явыз Иван тара-

фыннан Мәскәүгә озатылган Хан китапханәсендә генә дә меңнәрчә том китаплар булган, сирәк кулъязмалар сакланган.

Казан ханлыгы чорында матур әдәбият, бигрәк тә шигъри әсәрләр иҗат ителгән, мәшһүр шагыйрьләрдән Мөхәммәдьяр, Өмми Камал, Колшәриф һ.б. иҗаты киң таныла. Казан ханлыгында «Идегәй» дастаны, шәрык язучыларының әсәрләре киң таралган була. Халык үзе дә легендалар, риваятьлар, дастаннар иҗат иткән.

Казанлылар җыр, музыка тыңларга яратканнар, гөслә, курай, кубызларда уйнаганнар.

**Сарай мәдәнияте.** Түрәләр, дәүләт хезмәткәрләренә белем бирүче укытучылар хәтта Урта Азия, Кырым кебек җирләрдән дә чакыртылган. Мөхәммәд Әмин хан, заманының мәгърифәтле кешеләреннән берсе һәм үзе дә язучы, шагыйрь буларак, сәнгать әһелләрен, акыл ияләрен якын күргән һәм аларны, заманында Алтын Урда ханнары кебек, үз тирәсенә сарайга туплаган. Үзбәк ханы Шәйбаниның Мөхәммәд Әмин ханга бүләк итеп иң яхшы җырчылар, рәссамнар, музыкантлар җибәрүе мәгълүм. Ташъязмалардагы нәфис гарәп язулары, шигъри текстлар да сәнгатьнең роле зур булу хакында сөйли. Халыкның укый-яза белүе, күчереп язу сәнгатенең абруе арту китапка, язма сүзгә игътибарны көчәйтә. Кулъязма китап сәнгате каллиграфик үрнәкләрдә, шамаилләрдә, Казан ханнары ярлыкларында да сакланып калган. Кош каурые белән язылган текстларда баш хәрефләрне алтынга буяу, китаплар өчен күн яки көмеш тартмалар әзерләү киң таралган.

Казан ханлыгы чоры сәнгате төрки һәм Алтын Урда чоры мәдәнияте нигезендә формалаша. Казан ханлыгының Төркия, Кырым, Азәрбәйҗан белән бәйләнешләре сәнгать үсешендә чагылыш таба. Элеккеге чорлар белән чагыштырганда сәнгать купшылана, баеый. Архитектурада «шәркый барокко» стиле кулланыла. Таштан яки кирпечтән бизәк ясау, күпертмә бизәкләр куллану, диварларны майолика яки мозаик плитәләр белән каплау киң тарала.



*Казан Кремлендә табылган архитектура бизәкләре.*

Казанның һөнәр осталары ак ташкан һәм яндырылган кирпечтән мәһабәт биналар салганнар. Мөхәммәдьярның хан сарайларын тасвирлаганда «бер кирпече – алтын, берсе көмеш, туфрагы ганбәр – хуш истән», дип язуы очраклы гына түгелдер. Казан татарларында таш кисеп бизәк ясау сәнгате һөнәр дәрәҗәсендә үзләштерелә. Кабер ташларына бизәкләр төшерү гадәти санала. Купшы чәчәк бәйләме рәвешендәге бизәкләр еш кына кабер ташының арткы ягына уела. Кабер ташларында Коръәннән өзекләр һәм күренекле шагыйрьләрнең әсәрләре дә урын ала.


**Шәһәр цивилизациясе.** Казан ханлыгы Идел Болгары һәм Алтын Урдадан борынгы шәһәр мәдәниятен мирас итеп ала. Урдадагы шәһәр цивилизациясе үзәкләренең берсе нәкъ менә Урта Иделдә урнаша. Казан ханлыгы төзелгәч, инде болгар чорыннан ук билгеле булган, уңайлы урыннарда янадан шәһәрләр корыла, бөлгенлеккә төшкән шәһәрләр торгызыла. Шәһәрләр, алардагы мәһабәт биналар, диварлары бизәкле йортлар, мәчет-мәдрәсәләр, китапханәләр хакында шул дәвер кешеләре язып калдырган истәлекләрдә шәһәрләрнең архитектура үрнәкләренә бай булуы турында әйтелә.

**Казан – дәүләтнең башкаласы.** XI гасыр башында төзелгән Казан ул вакытта зур булмаган хәрби кирмән һәм сәүдә урыны буларак билгеле. Йөзләрчә еллар үткәч, Казан зур шәһәргә, Урта Иделдәге зур дәүләт башкаласына әверелә.

Хан сарае урнашкан Кремль (кирмән) – Казанның төп, иң матур һәм иң яхшы ныгытылган өлеше булган. Кирмән озын һәм юан имән бүрәнәләрдән ясалган дивар белән әйләндереп алынган. Ике катлы дивар арасына ком һәм вак таш тутырылган. Кайбер урыннарда диварның калынлыгы 6 метрга кадәр җиткән, кирмән диварларында манаралар һәм капкалар булган. Төньяк манара һәм диварның шул як өлеше ак таштан эшләнгән.

Ак таштан эшләнгән дивар Хан сараен да әйләндереп алган, аңа манара аша үтеп керергә мөмкин булган. Ишегалдында – Хан сарае, сарай мәчете, Сәүдә-кунак йорты, казна саклау урыны, дәүләт архивы һәм китапханә, шунда ук – хан төрбәләре урнашкан. Анда шулай ук сакчылар һәм башка хезмәтчеләрнең йортлары, сарай һөнәрчеләренең остаханәләре, ат абзарлары һәм келәтләр тезелеп киткән.

Хан сараеннан читтә берничә мәчет эшләгән. Аларның иң матуры һәм зурысы ак таштан төзелгән Кол Шәриф мәчет-мәдрәсәсе булган. Ак таштан салынган Хан сарае, биек мәчет манаралары, мунчалар шәһәр сурәтенә милли төсмер бирә. Әйтик, Ш.Мәрҗани Казанда 8 манаралы Кол Шәриф мәчете, шулай ук мәһабәт Нургали мәчете булганлыгы турында язып калдырган. Кенәз Курбский Кремль эчендә



*Ханлык чорындагы Казан урамы. Рәссам Р.Заһидуллин.*

5 таш мәчет эшләвен язган. Француз рәссамы А. Бар, XVIII гасырда сакланып калган өлешенә нигезләнеп, ике катлы, биек сигез кырлы манарасы булган, таш катыш кирпечтән төзелгән авыл мәчетенең сурәтен тергезгән.

Хәзер Туп сарае урынында хәрби гарнизон, корал ясау остаханәләре һәм арсенал була. Кремльнең калган өлешләрендә – бер-ике катлы агач йортларда – бай феодаллар яшәгән. Шунда ук гади шәһәр халкы – кирмән сакчылары һәм аксөякләрнең хезмәтчеләре көн күргән.

Бөтендөнья мирасының иң күренекле ядкярләре (ЮНЕСКО) исемлегенә кертелгән бүгенге Казан кремле ханлык чорында салынган күп кенә архитектура корылмалары эзләрен саклый.

**Бистәләр.** Кремльгә сәүдә-һөнәрчеләр бистәләре (посад) тоташа. Ул – Казанның икенче өлеше. Посад (Кремль кебек үк) саклану диварлары белән әйләндереп алынган. Ул Кремль диварына караганда да ныграк була. Андагы манаралар һәм капкалар саны унга җитә.

Посадның төп өлешендә гади казанлылар, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр йортлары һәм хуҗалык корылмалары тезелеп киткән. Бай казанлылар исә кирпечтән төзелгән һәм ике катлы агач йортларда яшәгәннәр. Шул заман кешеләре искә алганча, «зур түрәләрнең сарайлары бик матур һәм сокланырлык» булган.

Һөнәрчеләрнең остаханәләре, тегермәннәр һәм мунчалар, гадәттә, су кырыенда урнашкан. Болак белән Кремль диварлары арасында (хәзерге Ярминкә мәйданы урынында) иртәдән кичкә кадәр Ташаяк базары гөрләгән. Анда Шәрыктан китерелгән татлы ризык-



*Казан шәһәре посадында. Рәссам Р.Заһидуллин.*

лар, Төньякның затлы җәнлек тиреләре, Европа маллары һ.б. белән сату иткәннәр.

Посад диварлары үзенә күрә шәһәрнең чик буе ролен үтәгән. Диварлар артында бистәләр урнашкан. Болак артында Күрәеш бистәсе булган, аннан алып Иделгә хәтле сузылган Патша (хан) болыны 7 чакрымга җәелеп киткән. Казанлылар бу болында төрле бәйрәмнәр, ат чабышлары, хәрби өйрәнүләр уздыра торган булганнар. Шундый ук чаралар хәзерге Ирек мәйданыннан ук башланып киткән Арча кырында да ел саен үткәрелеп килгән. Хәзерге Калинин урамы тирәсендә Әрмән бистәсе дә булган.

**Һөнәрчелек**. Казан осталарының металл, алтын, көмештән ясаган бизәнү әйберләре, савыт-сабалар, чын сәнгать әсәрләре буларак, бүген дә хаклы рәвештә соклану хисе тудыралар. Савыт-сабалар, бизәнү әйберләре алтын-көмештән, металл эретмәләрдән нәфис бизәкләр төшереп әзерләнә. Хәситәләр, каптырмалар, чулпылар, алкалар, парлы беләзекләр, кечкенә Коръән савытлары кыйммәтле ташлар белән бизәлә. Тукымаларда, бизәнү әйберләрендә дә чәчәк-үсемлек бизәкләр файдаланыла. Казан татарларының алтын җепләр белән чигү сәнгате бик югары бәяләнә. Бу әйберләрнең күбесе Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан музейларында саклана.

Казанның көнбатыш тарафында, Казансу елгасы тамагында, көймәләр, кораблар төзүче балта осталары бистәсе – Бишбалта урнашкан. Аның янәшәсендәге пристаньга, яздан алып көзен боз катканчы, хәрби һәм сәүдә кораблары килеп торган.

Шәһәрдә һәм бистәләрдә берничә дистә мең кеше яшәгән. Биек тау башына урнашкан мәгърур ныгытмасы, мәһабәт биналары булган зиннәтле хан сарае һәм күккә ашкан гүзәл мәчет манаралары шәһәргә үзенчәлекле шәрык төсмере биргән. Чит ил кешеләре Казанның матурлыгына сокланып, «гаҗәеп



*Зәркән эшләнмәләре.*



шәһәр», «Шәрык башкаласы» дип зурлаганнар.

**Казан ханлыгы татар халкы тарихында һәм мәдәниятендә гаять тирән эз калдырган. Халкыбыз шул заманнарда иҗат ителгән сәнгать әсәрләре белән хаклы рәвештә горурлана.**

## Кол Шәриф (XVI гасыр башы – 2.10.1552) иҗатыннан

Аллага, Галәмнең хуҗасына, дан булсын, шөкер сиңа!
Үзең кабул бирдең иман безгә, [...]
Безне Мөхәммәт пәйгамбәр өммәтеннән яратты ул,
Мөхәммәт пәйгамбәрне дәлил итеп безгә җибәрде ул. [...]
Кем котыла алсын ярдәмчесез,
Мөхәммәт пәйгамбәр ярдәменнән башка? [...]
«Үзе эшләмәгән гамәлләрдән ничек халыкка нәсыйхәт бирер» аятендә
Аңлатып бирде Ул: «кыямәт» дип аталган көндә,
Үзе әйтеп тә, шул гамәлләрне үзе тотмаган галимгә,

Әйтеп торыр өч йөз алтмыш бәла безгә. [...]
Без укыдык-белдек, әмма тотмадык Аллаһ нәсыйхәтеннән, –
«Ни үкенеч! Әй, булса иде!» сүзләре генә юаныч безгә.
Үзең бел дә ян инде, и Кол Шәриф,
«Белем алам» дип, бөтен гомереңне үткәреп бетердең.
Егет чакта тәүбә итү Аллаһның ярдәме (ризыгы) кебек ул,
Гөнаһларны ярлыка инде, Аллаһ, безнең.

* * *

[...] Үзендә ирлек һиммәте (тырышлыгы) булган кеше Алланың нурын күрер,
Дөньяви максат-морадларын корбан итәр ул (шул юлда), рәхәт тормышы китәр җаннан.
Әгәр нәфсесе белән сугышса, күзләреннән кан-яшь акса,
Раббем, диеп, аңа бакса, килер ләббәйкә (хупланыр) йөз-мең яктан.
Морад кирәк булса сиңа, хакыйкатьтә ян син аңа,
Гамәл кыйлып төннән төнгәчә, яхшылыктан (үзеңне камилләштерүдән) читкә чыкмыйча.
Риязәт (теләкләрне тыеп тору) билбавындагы оят җирне (битарафлыкны) сызып ташла, и Кол Шәриф,
Алла гыйшкы хәзинәсе кирәк булса, алтын-көмеш каян чыгар башкача?

## КАЗАН ХАНЛЫГЫ: МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕКТӘН ҺӘЛАКӘТКӘ ТАБА

**Тотрыклылык**. Казан ханлыгы мөстәкыйль дәүләт буларак кырык елдан артыграк яшәп кала. Шуларның баштагы егерме елы яңа ханлыкның чәчәк аткан чоры була. Бу вакытта ил белән Мәхмүд хан (Мәхмүтәк) идарә итә. Алтын Урда инде таркалган, аның варисы булган Олуг Урда Казанның бәйсезлеген чикләрлек хәлдә булмый.

Әмма күршедә генә Мәскәү дәүләте күтәрелеп килә. Алтын Урда белән көрәшеп торганда, Казанга кул сузарга аның көче җитми. Әлегә Казан ханлыгына беркемнән дә куркыныч янамый. Казан ханлыгы тыныч яшәгән чорда шәһәрләр үсә һәм сәүдә киңәя. Тик Мәхмүд хан үлү белән, барысы да үзгәрә.

**Мәскәү белән мөнәсәбәт.** 1467 елда Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III ханлыкка каршы сугыш башлый. Бу рәхимсез, канкойгыч

сугыш озакка сузылмый. Аның башлануына бушап калган Казан тәхете сәбәп була. Иван III бу тәхеткә үз тарафдары Касыймны, ә казанлылар Мәхмүднең улы Ибраһимны куярга телиләр. Бөек кенәз бу юлы үз теләгенә ирешә алмый, әмма Ибраһимга 40 ел дәвамында әсирлеккә төшкән русларны азат итәргә туры килә.

Мәскәүнең Казан ханлыгының эчке эшләренә тыкшыну сәясәте моның белән генә бетми. Ибраһим хан үлгәч, Иван III тагын бер тапкыр көчен сынап карый, әмма нияте барып чыкмый. Казан тәхетендә күрергә өметләнгән Мөхәммәд Әминне дә Мәскәүгә алырга һәм аңа Кашира шәһәрен биләмә итеп бирергә туры килә. Казан тәхетенә Ибраһимның улы Илһам утыра.



*Мөхәммәд Әмин хан. Баш сөяге буенча реконструкция.*

1487 елның июлендә Иван III яңа сугыш башлый: Казанны камап ала һәм ике ай канлы сугыштан соң шәһәрне алып, тәхеткә үз тарафдары Мөхәммәд Әминне утырта. Илһам хан кулга алына һәм Вологдага сөргенгә озатыла. Ул шунда үлә.



*Казанны алган рус гаскәре яудан кайта. XVI гасыр иконасыннан.*

Мөстәкыйльлек чорында Казан ханлыгы Урта Идел буендагы иң куәтле, алга киткән дәүләт була. Үз бәйсезлегенә каршы һөҗүмнәрне кире кайтарып кына калмый, ә бәлки үзе дә уңышлы походлар оештыра.

**Мәскәү протектораты.** 1487 елда Казанның Рус дәүләтеннән вассал бәйлелек чоры башлана.

Иван III үзенә «Болгар кенәзе» дигән титулны ала. Яңа хан Мәскәүгә каршы сугышмаска, киресенчә, башка ханнар белән көрәшүдә кенәзгә ярдәм итәргә һәм ханлыкта булган рус кешеләре мәнфәгатьләрен кайгыртырга йөкләмә ала. Казанлылар үзләренә яңа ханны бары тик бөек кенәз ризалыгы белән генә сайлый.

Мәскәүгә бәйле булу Казан халкы арасында ризасызлык тудыра. Мөхәммәд Әминнең халыкка салган зур салымнары бу ризасызлыкны тагын да көчәйтеп җибәрә. 1496 елда аңа каршы фетнә күтәрелә һәм тәхеткә Себер ханы Мамык чакырыла. Фетнәчеләр ярдәме белән Мамык Казанны бик җиңел генә ала һәм бушаган тәхеткә менеп утыра. Мөхәммәд Әмин якыннары белән Мәскәүгә киткән була инде.

Мамук хан тәхеттә озак утырмый. Ил белән идарә итәргә булдыксызлыгы һәм халыкны аяусыз талаулары өчен казанлылар үзләре үк аны бер елдан куып җибәрәләр.

Иван III нең ризалыгы белән хакимияткә Ибраһим ханның кече улы, Мөхәммәд Әминнең энесе Габделлатыйф килә. Тик ул Кырымда тәрбияләнеп, русларның гореф-гадәтләрен кабул итә алмый. Тиздән Габделлатыйф Мәскәүгә каршы сәясәт алып бара башлый. Казанның Иван яклы кайбер түрәләренә бу ошап бетми. Нәтиҗәдә, Иван III кушуы буенча Габделлатыйф тәхеттән төшерелә һәм 1502 елда сөргенгә җибәрелә.

Иван III тарафыннан Казан шәһәренә яңадан Мөхәммәд Әмин җибәрелә һәм ул икенче мәртәбә Казан тәхетенә утыра. Казаннан яңадан куылудан курыккан Мөхәммәд Әмин Мәскәү йогынтысыннан котылырга тырыша һәм яңа сугыш башлап җибәрергә ниятли.

1505 елның июнендә узган ярминкә вакытында казанлылар бөек рус кенәзе илчелегенә һәм рус сәүдәгәрләренә һөҗүм итәләр. Аларның күбесе үтерелә һәм талана. Тиздән Мөхәммәд Әмин Мәскәүгә каршы яу белән китә. Түбән Новгород шәһәре камалышта кала, Ока елгасы буендагы рус җирләре талана.

Сугыш казанлылар файдасына булса да, 1507 елда Мөхәммәд Әмин Мәскәүнең яңа хакиме Василий III кә солых тәкъдим итә. Солых «элеккеге заманнардагы дуслык нигезендә» төзелә. Ун елга сузылган тынычлык вакытында Казан ханлыгы яңадан ныгый, көчле дәүләткә әверелә.

1518 елда Мөхәммәд Әмин үлә һәм Василий III тәхеткә Шаһгалине җибәрә. Әмма аңа да озак идарә итәргә туры килми. Зур салымнар, сәүдәгәрләрне кысу, талау, бөек кенәзгә яраргa тырышуы өчен ул бәреп төшерелә. Тәхеткә Кырым ханының улы Сәхибгәрәй чакырыла.

Ниһаять, 30 елга сузылган Мәскәү протектораты чоры тәмамлана. Бу чорның ахырында Кырым белән якынаю тарафдарлары өстенлек ала.

**Гәрәйләр чоры.** Сәхибгәрәй үзенең идарәсен Казандагы Мәскәү илчесен һәм рус сәүдәгәрләрен үтертүдән башлый. Моны ишеткән Василий III Казанга гаскәр җибәрә. Әмма гаскәр Казанга килеп җитми, көз җиткәч, кире борыла. Сәхибгәрәй, русларның Казанны тынычлыкта калдырмаячакларын аңлап, Кырым ханы белән бергә үзе Мәскәүгә яу чаба һәм аны камап ала. Мондый шартларда Василий III солых төзергә һәм «борынгы заманнар тәртибе буенча» ясак түләп торырга риза була.

Өч елдан соң Сәхибгәрәй тәхетне үзенең япь-яшь туганы Сафагәрәйгә тапшыра. Казан өчен иң тынгысыз чор башлана.

Сафагәрәйнең тоткан сәясәте каршылыклы була: кайвакытларда ул мөстәкыйль булырга омтыла, ә кайчакта Кырымга борыла. Өч тапкыр Мәскәүгә яу чаба. Аның идарәсе чорында Василий III рус сәүдәгәрләренә Казан ярминкәсендә сату итүне тыя, ә Явыз Иван өч тапкыр сугыш башлап җибәрә.



*Сафагәрәй хан.*
*Рәссам Р.Заһидуллин.*




*Сәхибгәрәй хан.*
*Рәссам Ю.Никитин.*

Сафагәрәйне ике тапкыр тәхеттән төшерәләр. Кырым һәм Нугай гаскәрләре ярдәмендә ул тәхетенә яңадан кайтарыла.

Казан түрәләре үзләрен кысулары һәм Кырымга таянганы өчен Сафагәрәйне дошман күрәләр һәм ханны төшерү турында яшерен сөйләшүләр алып бара башлыйлар. Икенче яктан аларның Мәскәү тарафдарлары Җангали һәм аның абыйсы Шаһгалине дә хан итеп таныйсылары килми. Мәскәү ярдәмендә хакимияткә килгән Җангали өч елдан соң үтерелә, ә Шаһгали тәхеттә бары бер генә ай утырып кала.

Кырымлыларның идарә итүе Казан ханлыгына тынычлык та, куркынычсызлык та алып килми. Казан тәхете өчен көрәш яңадан көчәеп китә.

**Казан ханлыгының һәлакәте.** 1549 елда Сафагәрәй хан вафат була, тәхет варисы булып аның өч яшьлек улы Үтәмешгәрәй билгеләнә. Балигъ булмаган яшь хан исеменнән әнисе Сөембикә идарә итә башлый. Нугай далаларында туып үскән акыллы һәм гүзәл ханбикәне казанлылар яратып кабул итә. Әмма Казанда кырымлылар йогынтысы көчле булганлыктан, Сөембикә үзе теләгәнчә идарә итә алмый.



*Сөембикә һәм Үтәмешгәрәй.*

Казан дәүләтен үзенә буйсындырудан өметен өзмәгән Иван IV сугышка ныклап әзерләнә. 1551 елның язында Зөя елгасының Иделгә коя торган урынында Зөя (Свияжск) ныгытмасы салына. Крепостька якын Тау ягы җирләре рус патшасы кулына күчә. Күрше чуаш, мордва, мари халыклары да аңа буйсыналар. Казанга килә торган су юллары ябыла.

Казан халкы хафага кала, алар зур куркыныч якынаюын сизеп борчылалар. Казанны саклаучы Кырым гаскәренең шәһәрдән китүе хәлне тагын да кискенләштереп җибәрә. Иван IV яклы шә-



XVI гасырның беренче яртысында Казан сугышчысы. С.Герберштейн китабыннан.



Татар сугышчысы. XVI гасырның уртасы. Реконструкция.

һәр түрәләре Сөембикә белән улын тәхеттән төшерәләр һәм икесен бергә русларга бирергә карар кылалар. Казан тәхетенә яңадан Шаһгали утыра.

Әмма Иван IV Тау ягы җирләрен казанлыларга кире кайтарудан баш тарта. Аның максаты Казан ханлыгын үзенә тулаем буйсындыру икәне һәркемгә ачык аңлашыла. Шаһгалигә өмет өзелә, аны элек тә яратмаган халык аңа үз дошманына караган кебек карый. 1552 елның мартында Шаһгали Казан кирмәненең зур тупларын, башка коралларны Зөя каласына күчерә һәм, дарыны ярамаслык хәлгә китереп, үзе дә Казан тәхетен ташлап китә.

Шушы хәлләрдән соң Казан халкы тәхеткә Әстерхан ханзадәсе Ядегәр Мөхәммәдне чакырып утырта. 1552 елның язында ул Казанга килә һәм Мәскәүнең дошманы булырга ант итә. Бу вакытта хәлиткеч сугышларның котылгысыз икәне һәркемгә ачык була инде.

1552 елның августында Иван IV 60 меңлек (кайбер тарихчылар фаразлавы буенча 150 меңлек) коточкыч зур гаскәре белән Казан шәһәре янына килә. Казанны камап алган көчләр арасында Шаһгалинең атлы гаскәре дә була. Казанлыларның саны ике тапкыр кимрәк була. Әмма алар бар көчләре белән шәһәрне сакларга тырышалар.

Канкойгыч сугыш айдан артык бара. «Казан тарихында» әйтелгәнчә, «һәр ике як үз-үзләрен аямыйча, батырларча сугыша... Бер як өчен Казанны алу мөһим булса, икенчеләре шәһәрне бирмәс өчен үзләрен аямыйлар». Шәһәргә биек күчмә агач манаралардан туплар, ут, ядрәләр ява.



*Казанны алу. Рәссам И.Фәйзуллин.*

Казанны саклаучыларның саны сирәгәйгәннән-сирәгәя бара. Арча ягыннан уңышлы һөҗүм ясап торган Япанча бинең дә атлы гаскәре тар-мар ителә. Казанлылар ягында сугышкан мари, чуаш гаскәрләре дә җиңелүгә дучар була. Шәһәрне саклаучылар су ала торган чишмә шартлатыла, алар сусыз кала.

2 октябрь көнне кирмәнне штурмлау башлана. Ләкин аңа кадәр бик көчле ике шартлау була. Кремль диварлары берничә урында җимерелә. Рус сугышчыларына Кремль эченә юл ачыла. Моңарчы күрелмәгән хәлиткеч сугыш башлана. Көчләр тигез булмаса да, казанлылар зур гайрәт белән дошман өстенә ташланып, үзләрен аямыйча сугышалар, диварлардан дошманнар өстенә бүрәнәләр ташлыйлар, янып торган дегет агызалар. Соңгы сугыш Хан сарае тирәсендә була.

Ядегәр хан әсир итеп алына. Шәһәрне саклаучыларның бик азы гына Кремль эченнән исән килеш чыга ала. Шәһәр җиңелә. Ул еллардагы гадәт буенча, Иван IV җиңүчеләргә аны таларга рөхсәт бирә. Мәчет һәм мәдрәсәләрдә, өйләрдә исән калган барлык җан иясе үтерелә. Урамнарда өем-өем үлекләр ята, тирә-як авыллардагы хатын-кызлар һәм балалар әсир итеп алына.

Казан ханлыгы яшәүдән туктый. Аның җирләре Мәскәү дәүләтенә кушыла. Иван IV үзен «Казан патшасы» дип атый башлый.

**Казан ханлыгының йөз елдан артыграк яшәү дәвере татар халкы тарихында гына түгел, ә бәлки Урта Идел буенда яшәгән барлык халыклар тормышында гаять әһәмиятле чор була.**

## Патша хәйләсе (риваять)

Иван Грозный Сөембикә белән сугышып, бик күп көчен бетергән, ләкин каланы ала алмаган. Шуннан соң ул хәйләгә керешә: «Миңа үгез тиресе хәтле генә җир бирегез, мин башка сугышмас идем», – ди. Сөембикә уйлап-уйлап тора да: «Нәрсә ул үгез тиресе хәтле җир, алыгыз, сугышмагыз гына», – ди.

Шуннан Иван Грозный кешеләре Идел буена зур гына бер үгезне китереп куялар да, тиресен тунап, бер-берсенә ялгап, озын бау ясыйлар да, шул бау белән зур гына җир мәйданын әйләндереп алалар. «Нигә аның кадәр җир алдыгыз?» – дип, Сөембикә ачулангач: «Без үгез тиресе кадәр генә җир алдык», – диләр. Шул урында хәзерге Зөя каласын – сугыш каласын салалар. Сөембикә бу эшкә каршылык күрсәтә алмый.

# ОЛУГ УРДА, ӘСТЕРХАН ХАНЛЫГЫ, НУГАЙ УРДАСЫ

**Алтын Урданың төп варисы.** Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән дәүләтләр арасында аның Идел ярындагы элеккеге башкаласы Сарай-әл-Җәдид урнашкан Олуг Урда төп дәүләт булып саналган. Тикмәгә генә аны «Тәхет иле» дип атамаганнар. Ул чордагы татар ханлыклары арасында бары тик Олуг Урда гына әле кайчандыр искиткеч куәткә ия булган Алтын Урда традицияләрен саклап кала алган. Олуг Урда Алтын Урда варисы, аның турыдан-туры дәвамчысы була. Калган барлык татар ханлыклары аннан аерылып чыгалар. Ул Идел һәм Днепр елгалары арасындагы җирләрне, Түбән Идел һәм Төньяк Кавказ далаларын биләп тора. XV гасырның 40 елларына инде Олуг Урда карамагында Идел һәм Днепр арасында булган җирләр генә кала.

Казан ханлыгыннан аермалы буларак, Олуг Урдада яшәүчеләрнең күпчелеген күчмә халыклар тәшкил иткән. Алар бик аз күләмдә генә игенчелек белән, нигездә күчмә терлекчелек белән шөгыль-

ләнгәннәр. Казандагы кебек үк, Олуг Урданың да башында Чыңгыз хан нәселе дәвамчылары – Җучилар торган. Дәүләт эчке төзелеше белән дә Алтын Урдага бик нык охшаган була. Ул ярымхәрби дәүләт була. Олуг Урда белән идарә итүдә Мангыт нәселе зур роль уйный. XV гасырның икенче яртысында Олуг Урданың Көнчыгыш Европа тормышына да йогынтысы зур була. Әмма ләкин хакимнәрнең үзара көрәшләре, ызгыш-талашлары аның үзен эчтән таркаткан.

Олуг Урданың беренче ханы Мәхмүд (1459–1465 елларда хакимлек итә) була. Мәхмүднең 1465 елда Рус дәүләтенә каршы оештырган уңышсыз явыннан соң хакимияткә 1460 елда агасы Әхмәт килә. Ул хакимлек итә башлауга ук, үзенә буйсынуларын таләп итеп, башка татар ханнарына һәм Мәскәү кенәзенә илчеләр җибәрә.

Әхмәт хан чорында (1465–1481 еллар) Олуг Урданың көче арта, Польша-Литва дәүләте белән килешү төзелә, Госманлы империясе белән дуслык мөнәсәбәтләре урнаша. 1476 елда Әхмәт хан Урданың элеккеге Алтын Урда чорындагы территорияләрен торгызуга юнәлтелгән эшчәнлеген башлап җибәрә: шул ук елда Кырым ханлыгын яулап ала, анда үзенең остазы Җанибәкне (агасы Мәхмүднең улын) билгеләп куя, соңрак икенче бер туганнан туганын – Әстерхан ханын үзенә буйсындыра. Әмма көтмәгәндә Кырым ханы Хаҗигәрәй (? – 1480) һөҗүменә дучар була, бу исә аның планнарын тулысынча җимерә. Алтын Урда дәүләтен элеккеге чикләрендә торгызырга омтылган Әхмәт хан яңа барлыкка килгән татар ханлыкларына һәм рус олысына каршы актив хәрби-сәяси көрәш башлый. Озакламый Мәскәү кенәзе Иван III һәм Кырым ханы Миңлегәрәй (? – 1515) аңа каршы көрәштә көчләрен берләштерәләр.

1480 елда Әхмәт үзенә ясак түләүдән баш тарткан рус дәүләтенә һөҗүмгә күтәрелә. Әмма сугыш булмый кала, чөнки ике армия дә үз илләренә таба кире борыла. Бу вакыйга 1480 елгы «Угра буендагы капма-каршы тору» дигән исем белән тарихка кереп кала һәм Россия тарихының мөһим вакыйгаларыннан берсе санала.

Әхмәтнең дошманы – бөек Мәскәү кенәзе Иван III – үзенең улы һәм барлык гаскәре белән Мәскәүгә кире борылып кайта. Мәскәү халкы гаскәрне зур алкышлар белән каршы ала.



*Хаҗигәрәй хан. Рәссам Ю.Никитин.*



*«Угра буендагы капма-каршы тору». Рус елъязмасыннан.*

«Торуның» нәтиҗәләре Урдада башка төрле кабул ителә. Дала буйлап Олуг Урда ханының уңышсызлыкка очравы турындагы хәбәр тарала.

«Угра буендагы капма-каршы тору» вакыйгасыннан соң, Рус олысы татар хакимлегеннән азат ителә. Әхмәт чигенә һәм гаскәрләрен кире Сарайга таба алып китә, ул инде көрәшне дәвам итә алмый.

Алтын Урданың төп варисы хокукына ия булу өчен Кырым ханлыгы белән ике арада барган көрәшкә Олуг Урда хакимнәре аеруча зур өмет баглыйлар. Нәтиҗәдә бу Олуг Урданың җимерелүенә китерә. XV гасыр азагы Олуг Урда өчен бик уңышлы булмый – ачлык еллары башлана. 1502 елның май башында Кырым ханы Миңлегәрәй гаскәрләре Олуг Урданың соңгы ханы Шәех-Әхмәткә каршы чыга. Моңа кадәр дә Шәех-Әхмәтнең бик күп халкы, шул исәптән хатыны да, Кырым ханы ягына чыккан була. Миңлегәрәй сугышсыз-нисез генә Шәех-Әхмәтнең ныгытмаларын юк итә һәм аның аз санлы гаскәрен куып тарата. Моннан соң Кырым ханы Шәех-Әхмәт биләмәләрен җимереп-яндырып, Олуг Урданың башкаласы Сарай шәһәренә юнәлә, аны талый һәм яндыра. Нәтиҗәдә Олуг Урда 1502 елда яшәүдән туктый. Иделнең аръягындагы җирләр Нугай Урдасы составына, ә Дон һәм Идел елгалары арасындагы җирләр Кырым ханлыгына кертелә. Олуг Урда халкы таланмый һәм юк ителми, ул бары тик Кырым ханына буйсындырыла. Олуг Урданың җимерелүе нигездә XV гасыр ахыры – XVI гасыр башындагы корылык һәм иген уңмау сәбәпле килеп чыккан хуҗалык кризисы белән бәйле була.

Олуг Урда җимерелгәннән соң, аның соңгы ханы Шәех-Әхмәт үзенең 300 җайдагы белән качып котыла ала. 1504 ел азагында хан һәм аның юлдашлары Киевка, Польша короле янына киләләр, биредә алар урындагы воевода тарафыннан кулга алыналар. 1505 елдан ханны Ковнода шәрәфле әсир итеп тоталар. Аңа барлык уңайлы шартлар тудырыла, әмма патшалыктан китү хокукы бирелми. 20 елга сузылган торкынлык дәвамында Нугай Урдасы тарафдарлары Шәех-Әхмәтне азат итү хакында король хакимиятенә күп тапкырлар мөрәҗәгать итәләр. 1527 елның язында инде картайган Шәех-Әхмәт

иреккә чыгарыла. Кайбер чыганаклар буенча, Шәех-Әхмәт 1527–1528 еллардан алып вафатына кадәр Әстерхан ханы булып торган.

**Әстерхан ханлыгы.** Алтын Урданың үз эчендә ваграк өлешләргә бүленүе XV гасыр буена дәвам итә. Башкаласы Хаҗитархан исеме белән аталган Әстерхан ханлыгы яңа татар дәүләтләренең берсе була. XVI гасыр урталарыннан Әстерхан ярым мөстәкыйль олыс булarak Олуг Урда составына керә, әлеге дәүләтнең бер шәһәре булып тора. Анда Олуг Урда ханнарының иң якын туганнары – аларның агалары һәм туганнан туганнары хакимлек итә. Якынча 1480 елдан Олуг Урданың башкаласы да Әстерханга күчерелә. Олуг Урданың әлеге олысыннан әкренләп яңа татар дәүләте – Әстерхан ханлыгы оеша башлый. Ә 1502 елда Олуг Урда тәмам тар-мар ителгәч, Хаҗитархан аның туры варисы рәвешендә аерым дәүләткә әверелә. Кырымга күченеп китәсе килмәгәннәр һәм Шәех-Әхмәт артыннан Польшага китәргә теләмәүчеләр – барысы да бирегә юл ала. Шулай итеп, Олуг Урда ханнары нәселен алар белән нәсел тамырлары бер үк булган Әстерхан ханнары алыштыра.

Әстерхан ханлыгы Түбән Иделдә нигезләнә. Башкаласы – Хаҗитархан шәһәре, Иделнең уңъяк ярында, хәзерге Әстерхан шәһәреннән 12 чакрым ераклыкта урнашкан була. Төп халкы дала күчмәләре – нугай җайдакларыннан һәм шәһәр тирәсендә күчмә тормыш белән яшәгән Әстерхан татарларыннан гыйбарәт була. Мәйданы буенча ханлык барлык татар ханлыклары – Алтын Урда варислары арасында иң кечкенәсе санала. Көнбатыштан ханлык җирләре Кубань елгасына һәм Донның түбән агымына ук килеп тоташа. Көнчыгыштан ханлык чикләре Бузан елгасына кадәр килеп




*Әстерхан күренеше. Я.Стрейс гравюрасыннан.*

җитә. Биредә ханлык Нугай Урдасы белән чикләшә. Ханлыкның көньяк чиге Терек елгасына килеп җитә, ә төньяктан Донның урта агымы киңлекләре белән тоташа. Дәүләт җирләренең бик күп өлешен тозлы туфраклы далалар алып тора. Ханлык халкы яшәү өчен, нигездә, Идел дельтасында урын ала.



*Әстерхан ханлыгы сугышчысы. Реконструкция.*

**Сәүдә үзәге.** Әстерхан ханлыгы гадәти феодаль дәүләт була. Ханлыкның башкаласы Хаҗитархан шәһәре транзит сәүдәсе үзәге булып торган. Венеция, Харәзем, Бохара, Кырым, Казан һәм рус сәүдәгәрләре биредә сәүдә иткәннәр яки шушы шәһәр аша үзләренең товарларнын башка илләргә чыгарганнар. Биредә тукымалар һәм ефәкләр белән сәүдә иткәннәр. Әстерханга Казан белән Мәскәүдән тиреләр, күн әйберләр һ.б. товарлар китерелгән. Халкы күчмә терлекчелек белән шөгыльләнгән; аучылык, балыкчылык һәм тоз табу эше дә зур роль уйнаган. Игенчелек киң таралыш алмый – бары тик Бузан елгасы буенда гына күзәтелә. Халык шулай ук бакчачылык белән дә шөгыльләнә. Олыстагы кара халык, ягъни гади халык, ясак түләгән.

Әстерхан ханлыгы һәрвакыт башка татар ханлыкларыннан – башта Олуг Урдадан, соңыннан, ул җимерелгәннән соң, Кырым ханлыгыннан һәм Нугай Урдасыннан күпмедер дәрәҗәдә бәйлелектә яшәгән.

**Ханлыкның җимерелүе**. 1547 елда Әстерханда Кырым тарафыннан билгеләнгән Ямгырчы би хан итеп куела. Ул Мәскәүгә каршы сәясәт алып барган. Бу вакыйга Кырым белән нугайлар арасындагы мөнәсәбәтләрне киеренкеләндерә, чөнки нугайлар Мәскәү яклы була. Нугайларның Әстерхан ханы итеп үз кешеләрен куясылары килә. Шуңа күрә 1548 елда алар Нугай Урдасына элеккеге Әстерхан патшасының улы, ул вакытта Мәскәүдә яшәгән Дәрвишгалине җибәрүләрен сорап, Мәскәүгә вәкилләр җибәрәләр. 1549 елның башында Дәрвишгали Мәскәү илчесе белән Нугай Урдасына килә, ләкин, нугайларда ул вакытта инде хаким алмашыну сәбәпле, дошманнарча каршы алына.

Казанны яулап алганнан соң, 1554 елның 2 июлендә Мәскәү патшасы гаскәрләре Әстерханга якын килә һәм шәһәрне басып ала, ә

Ямгырчы хан кача. Әстерхан тәхетенә әлеге татар ханлыгының соңгы ханы Дәрвишгали утыртыла. Әмма ләкин 1555 елда ул Мәскәү белән һәртөрле мөнәсәбәтләрне өзә һәм Кырым ягына күчә. Берничә тапкыр кабатланган сугышлардан соң, 1556 елның август башында Әстерхан янәдән рус гаскәрләре тарафыннан басып алына. Дәрвишгали Азакка, аннан соң Мәккәгә кача. Әстерхан патшасының уллары Бохарада Шәйбаниләр арасында сыенып урын табалар, соңыннан Бохара ханлыгында Әштарханилар дигән хан нәселенә нигез салалар.

**Нугай Урдасы.** Нугай Урдасы көнбатышта Иделдән алып, көнчыгышта һәм Иртыш елгасына кадәр, төньякта Камадан алып, көньякта Сырдәрья елгасына кадәр җәелә.

Бу күчмә дәүләттә Урал елгасының түбәнге агымында урнашкан, Алтын Урда заманнарыннан ук калган Сарайчык шәһәреннән тыш башка шәһәрләр булмый. Сарайчык (хәзерге Казакъстан территориясендә) нугайларның башкаласына әверелә. Шәһәргә XIII гасырда нигез салына. Алтын Урда заманнарында Сарайчык шәһәре аша Кырымнан һәм Кавказдан Каракорымга (монгол дәүләте башкаласы) һәм Кытайга илтүче юллар уза. XIII–XIV гасырлар шәһәрнең чәчәк аткан чоры була, әмма XV гасырда Сарайчык җимерелә. Нугай Урдасының башкаласына әверелгәч, шәһәр яңадан торгызыла башлый. Алтын Урда һәм Нугай Урдасының бик күп ханнары Сарайчыкта күмелә.



*Татар һәм нугай гаскәре яуда. Европа гравюрасыннан.*

**Нугай хакимнәре.** Нугай хакимнәренең нәсел башы Мангытлардан килә. Алтын Урда ханнарының уң кулы булган кайбер бәкләр дә Мангыт нәселеннән чыккан. Алтын Урданың төп хәрби башлыгы, гадәттә, әлеге нәселдән сайланган. Әмма Мангытлар үзләре Чыңгызхан нәселе варислары түгел, шуңа күрә хан тәхетенә ия була алмаган.

Мангыт нәселеннән килеп чыккан кодрәтле бәкләр бәге (бөек кенәз) Идегәй Нугай Урдасына нигез салучы дип санала.

Идегәй хакимлек иткәндә Нугай Урдасы Алтын Урдадан аерылып чыга башлый,

ә аның улы Нуретдин хакимлеге чорында Алтын Урдадан аерылган мөстәкыйль дәүләт булып җитешә.

Алтын Урда таркалганнан соң оешкан дәүләтләр арасында халык саны буенча иң зурысы Нугай Урдасы була. Хуҗалык итүнең төп нигезен терлекчелек (атлар, сарыклар, мөгезле эре терлек һәм дөяләр) һәм транзит сәүдәсе тәшкил итә. Башка татар ханлыклары утрак тормыш рәвешенә күчкән бу вакытта Нугай Урдасының икътисады элеккечә күчмә характерда була. Шуңа күрә сәяси яктан Нугай Урдасы көчсез була, чөнки хан хакимияте булмый, ә морзалар бигә (Урданың баш хакименә) еш кына буйсынмыйлар.



*Нугай җайдагы һәм Кырым татары.*

Нугай Урдасы Мәскәү дәүләте белән дуслык, кайвакытта хәтта союздашлык мөнәсәбәтләрендә була. XVI гасыр уртасында Казан басып алынганнан соң, Нугай Урдасы өч өлешкә бүленә. Зур Нугай белән Мәскәүгә юнәлеш тоткан Исмәгыйль би идарә итә. Өч еллык корылык һәм йогышлы чир нәтиҗәсендә XVI гасырның 50 елларында барлык терлекләр кырылып бетә, нугайлар арасында үзара бәрелешләр башлана, чума кизүеннән халыкның 80%ы вафат була, нугайлар Төньяк Кавказга күченеп китә башлыйлар.

Нугай Урдасындагы туктаусыз фетнә-чуалышлар аның мөстәкыйль дәүләт буларак юкка чыгуына сәбәп була. Дәүләтнең көчсезләнүеннән Нугай Урдасының көндәшләре файдаланып калырга ашыга. XVII гасыр башында Нугайның Җаектан алып Иделгә кадәр булган җирләренә калмыклар урнаша. Нәтиҗәдә нугайларның бер өлеше Госманлылар империясенә күченә, икенчесе Мәскәү патшалыгы составына кушыла, калган өлеше Казакъ ханлыгына күчеп китә.

Нугай Урдасы һәм Әстерхан ханлыгы элеккеге Олуг Урданың варислары була. Әмма аларның сәяси төзелеше һәм икътисади үсеше тотрыклы булмый, шуңа күрә күп тә үтми, алар үзара ызгыш-талашлар, сугышлар, басып алулар һәм низаглар корбанына әверелә. Шулай булуга карамастан, нәкъ менә әлеге дәүләтләрдә татар халкы тарихына һәм мәдәниятенә зур йогынты ясаган Әстерхан татарлары, нугайлар кебек этник төркемнәр барлыкка килә.

# КЫРЫМ ХАНЛЫГЫ

XV гасырның беренче яртысында үзәктән тайпылу көчәя. Кырым татар аксөякләренең Алтын Урдадан тулысынча аерымлану өчен көрәше башлана. Аның беренче этабында Җучиларның Тукатимериләр тармагы вәкилләреннән торган яңа – Гәрәйләр татар династиясе формалаша. Әлеге династиянең нәсел башы 1443 елда Кырым ханы итеп билгеләнгән Хаҗидәүләт Гәрәйдән башлана. XV гасыр азагында Миңлегәрәй хан үз биләмәләренең Алтын Урдадан бәйлелегенә чик куя.

Яңа оешкан ханлык составына Кырым ярымутравы, Дунай һәм Днепр, Азов буе һәм Кубань җирләренең бер өлеше керә.

Ханлыкның беренче башкаласы Кырым (Солхат) шәһәре була. Хаҗидәүләт Гәрәй Кырык Йир (Чефет Кала) шәһәрендә озаклап яши. Нәкъ менә ул Чурыксу елгасы ярларында Бакчасарай («Бакча эчендәге сарай») шәһәрен сала да инде. Бакчасарай аның улы Миңлегәрәй идарәсе вакытында ук Кырымның яңа башкаласына әверелә.

Кырым ханлыгы төньяктан Польша, Литва һәм Мәскәү дәүләте белән чиктәш. Ханлыкта яшәүчеләрнең күбесе татарлар була. Шулай ук Кырым ярымутрауында борынгыдан ук грек, гот, алан, әрмәннәр һәм караимнәр дә яшәгән. Ханлык белән хан һәм дәүләт советы – диван идарә иткән. Диван составына хан үзе, аның урынбасары һәм төп варисы – калга солтан, ханның өлкән хатыны яисә анасы – ханша валидә, ханлыктагы мөселман дин әһелләренең башлыгы – мөфти, төп бәкләр һәм угланнар кергән. Калга солтаннан кала ханның икенче варисын нуретдин солтан дип йөрткәннәр.

1475 елда Госманлы империясе Кырымдагы генуялылар колонияләрен, Феодоро кенәзлеген яулап ала. Кырымның таулы өлкәләрен тәшкил иткән бу территорияләр, шулай ук кайбер




*Миңлегәрәй хан.*
*Рәссам Ю.Никитин.*

Кара диңгез буендагы, Азов буендагы һәм Кубаньдагы кайбер эре шәһәрләр һәм кирмәннәр төрек администрациясе тарафыннан идарә ителгән. 1478 елдан Кырым ханлыгы рәсми рәвештә Госманлы империясенең вассалына әверелә, һәм бу хәл 1774 елга кадәр дәвам итә.

Гәрәйләр гаиләсе әгъзалары даими рәвештә Истамбулда яшәгән, солтан шулар арасыннан яңа ханны үзе билгеләп куйган. Кырым ханлыгына эчке сәяси автономия һәм чит ил дәүләтләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру хокукы калдырыла. Кырым ханлыгының үзенең сюзеренына карата төп вазыйфасы татар гаскәрләрен Госманлы дәүләтенең яулап алу походларында катнаштыру була.



*Миңлегәрәй хан улы белән. Хан каршыда солтан Баязид II. Төрек миниатюрасы. 1484 ел.*

**Икътисад.** Кырым ханлыгында бары тик көмеш («акча») һәм бакыр («бишлек») вак тәңкә генә сугылган. Перекоп, Каффа һәм Гезлев (Кизләү) төп сәүдә үзәкләре булып торган. Ярымутрауга тиреләр, тукымалар, күн, тимер, кораллар кертелгән. Кырымнан исә елына мең ярым олауга кадәр тоз читкә җибәрелгән.

XVI–XVIII гасырларда Кырым татарларында, бигрәк тә таулы Кырымда, күчмә терлекчелеккә алмашка әкренләп игенчелек килгән. Шулай булса да, терлекләр әле бик озак халыкның байлык дәрәҗәсен билгеләүче төп үлчәм булып калган. Бу өлкәләрдә яшәүчеләр ат, дөя, мөгезле эре терлек, сарык үрчетү белән дә шөгыльләнгән.

Татарлар тары, бодай, карабодай, арпа һәм солы чәчкәннәр. Кырым портларыннан ел саен Төркия өчен икмәк төялгән йөздән алып йөз иллегә кадәр кораб кузгалып киткән. Татарлар шулай ук умартачылык белән шөгыльләнгәннәр, йөзем, җиләк-җимеш агачлары, карбыз, кавын, яшелчәләр үстергәннәр. Кырымдагы башка халыклар, нигездә, йөзем үстерү, шулай ук бакчачылык белән шөгыльләнгәннәр. Ханлыкта күптөрле милләт вәкилләре яшәгән. Кырым шәһәрләрендә, татарлардан тыш, электән үк греклар, әрмәннәр, яһүдләр, сәүдә һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнүче күпсанлы төрекләр яшәгән.

Дала татарлары терлекчелек тармагын үстерүләрен дәвам иткәннәр. Буҗакта (Днестр һәм Днепр буйлары) халык утрак тормыш



*Кырым татарлары хуҗалыгы. Х.Гейслер гравюрасы.*

алып барган, игенчелектән тыш, терлекчелек һәм умартачылык белән дә шөгыльләнгән. Игенчелек белән шөгыльләнү Кырымның су чыганакларына бай урыннарында гына мөмкин булган. Бу исә эшкәртергә мөмкин булган җирләргә карата монополия барлыкка китергән.

Ханлык территориясендә җиргә ия булуның берничә төрле формасы күзәтелгән: хан җир биләмәләре, билекләр (аксөяк карачыбиләрнең җир биләмәләре), солтан карамагындагы җирләр, дин әһелләренә караган вакыф җирләре, морза җир биләмәләре, җәмәгать җирләре.

Кырым татарларында ыругларга бүленү традициясе урта гасырлар азагына кадәр сакланып килә. Ыруг башында би торган, алар җирне беренче эләктереп алу хокукына таянып, Гәрәйләр хакимияте урнашкан вакытка үзләренең җирләренә ия булалар, шул җирләрнең уртасындагы иң яхшы биләмәләр биләргә бирелгән, бу җирләр «билекләр» дип аталган. Билек эчендә аерым җирләр морзаларныкы – би нәселе әгъзаларыныкы булган. Морзалар социаль хәлләре буенча биләрдән түбәнрәк булганнар, шул рәвешчә, алар, җирдән һәм хәрби табышлардан керем алып, феодаллар сыйныфын тәшкил иткәннәр дә.

Гәрәйләр хезмәтләре өчен феодалларга җирләтә бүләкләр биргәннәр. Аларга сөрүлек җирләр, печәнлекләр, терлек өчен кышлау урыннары, бакчалар, тегермәнле җирләр тапшырылган. Шул рәвешчә акрынлап күп җирләр билгеле бер нәсел карамагына күчә барган. Әлеге җир өләшүләр биләрне эре җир биләүчеләргә һәм илнең


фактик хуҗаларына әверелдергән. Иң югары феодаль хакимияттә дә карачы-биләрнең – Ширин, Барын, Аргын, Сәджүт, Мансур һәм Яшлау нәселләрнең башлыклары торган. Илдә төп рольне башкарган Шириннар нәселе вәкилләре аеруча шөһрәтле һәм куәтле булган. Алар хан йортыннан булган патша кызларына өйләнә алганнар, дәүләттә иң дәрәҗәле урыннарны биләгәннәр, илдәге иң уңдырышлы җирләргә ия булганнар. Хуҗа үз билегендә, ул җир белән гомер буе файдалану хокукыннан тыш, шул җирләрдә яшәүче халык өстеннән дә тулысынча хакимлек иткән. Биләр җирле суд эшләрен дә күзәтеп торганнар, ризыклата алынган салым (рента), елына 8–10 көн тәшкил иткән барщина күләмен дә үзләре билгеләгәннәр. Документларда гомуми салым, уңыштан алынган салым, сату-алудан алынган җыем (пошлина), таможня җыемы, җан башыннан алына торган җыем, провиант һәм фураж, йөзем җимешләре сатудан алынган җыем, ындыр табагы өчен түләү, мөгезле эре терлектән алына торган салым һ.б. искә алына. Би хәрби походлар вакытында үз кул астындагы халыкны корал белән дә тәэмин итәргә тиеш була.

Карасудан алып Керчькә кадәр булган җирләргә хуҗа булган Ширин биләре башлыгының резиденциясе Карасу-Базарда урнашкан була. Бирелә билекнең бөтен эшләре белән аның шәхси диваны идарә иткән. Бинең үзенчәлекле байракка ия үз гаскәре дә булган. Ә Аргыннар билеге Кафа һәм Судак янында була.

Әлеге нәселләрнең вәкилләре арасында дәүләттә хакимлек итү, ханга йогынты ясау, диванда урын өчен туктаусыз көрәш барган.



*Кырым ханлыгында яшәүче төрле катлам вәкилләре.*
*Европа миниатюралары. XVII гасыр башы.*



*Морза йортында. XVIII гасыр гравюрасы.*

Хан, төп җир биләүче буларак, тоз күлләре һәм алар тирәсендәге авыллар, урманнар һәм буш җирләргә дә ия булган. Бу җирләргә яңа килеп урнашучылар да авыллар корган, алар әкренләп ханга гошер түләүче бәйле халыкка әверелгән. Үлгән вассалның турыдан-туры варисы булмаса, аның мирасына хан ия булган, би һәм морзаларның да варисы булып ханнар саналган. Хан биләмәләреннән калга солтанга да җир бүлеп бирелгән. Хан биләмәләре составында шулай ук берничә шәһәр, шул исәптән Солхат, Кырык Йир һәм Бакчасарай да була.

Ислам ханлыкның дәүләт дине булган. Ил тормышында гаять зур роль уйнаган руханилар вакыф җирләренә дә ия булганнар. Төп керемнәрен алар шушы җирләрдән алганнар. Дин әһелләре керемнәренең тагын бер өлешен хәрби табышлардан тотып калынган өлеш һәм барлык ил халкыннан җыелган салымнар тәшкил иткән. Ханнар, феодаль аксөякләр тарафыннан мәчетләр һәм мәдрәсәләр файдасына ясалган бүләкләр дә аз булмый. Мөселман руханилары башында мөфти торган. Ул Кырым мөселман шурасы башлыгы булган, хөкем иткәндә хата җибәргән казыйларны вазыйфаларыннан азат итә алган. Ханлык халкының төп өлешен терлекчеләр һәм игенчеләр тәшкил иткән. Аларны «кара халык» дип йөрткәннәр. Бу кешеләр ирекле булып, ыруглык традицияләрен саклап калганнар.

Җәмгыятьтәге төп социаль берәмлек булып патриархаль гаилә торган. Җиргә күмәк милек, уртак коелар булган. Күмәкләп җирләрне сөрүләр, печән чабулар – бу эшләрне башкару өчен берничә гаилә берләшкән. Җәмәгать җирләре пайлар нигезендә бүленгән.

Ханлыктагы иң түбән катлау булып коллар торган. Коллар саны күрше дәүләтләргә һөҗүмнәр вакытында һәм Кырым хакимлеге астындагы дәүләтләр башында торган вассал кенәзләрдән тереләтә ясак алган вакытта тулыландырылып торган. Коллар хезмәте хуҗалыкта киң кулланылган.

**Шәһәрләр – һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре**. XVI гасыр ахырында шәһәрләр сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләренә әверелгәннәр. Аларда һөнәрчеләр җыйналган. Базарларның әһәмияте бик зур булган. Һөнәрчеләр җирле халыкның көнкүреш һәм хуҗалык кирәк-яракларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндергәннәр. Һөнәрчелекнең алга китүе шәһәрләр үсешенә дә йогынты ясаган. Сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләрнең җитештерүне һәм бәяләрне җайга салучы цехлардан торган оешмалары – 32 цех корпорациясе була. Аның белән өлкән мастер (оста башы) һәм аның ике ярдәмчесе җитәкчелек иткән. Цехлар хан түрәләре тарафыннан даими рәвештә тикшерелеп торылган. Әлеге түрәләр төрле цехларда җитештерелгән товарларга бәяләр билгеләгәннәр, барлык сәүдә килешүләреннән җыем алганнар, казна файдасына күбрәк табыш китерергә тырышканнар. Татар шәһәрләрендә киез басканнар, тире иләп, күн, сәхтиян (сафьян) эшкәрткәннәр, ат дирбияләре, металл әйберләр әзерләгәннәр. Шулай ук корал, аяк киемнәре, кием-салым, келәмнәр, көнкүреш әйберләре җитештергәннәр. Базарларда авыл хуҗалыгы продуктлары: ит, сөт, бал, балавыз, йөзем, яшелчәләр, җиләк-җимешләр һ.б. тәкъдим ителгән. Ханлыкның акча системасы да нык үсеш алган. Ханнар сәүдә үсеше белән бик кызыксынган, чөнки ул казна керемен арттырган. Кырымнан читкә чыгарылган товарлар арасында чи күн, сарык йоны, сәхтиян, кайры туннар һ.б. була.

Шәһәрләрдә төзелгән биналар бер катлы була. Килгән кешеләр өчен кунак йортлары салынган. Шәһәрләр бер үк вакытта эре аксөяк вәкилләренең резиденцияләре дә булып торган. Мәсәлән, Бакчасарай – ханлыкның башкаласы, Ак-Мәчет – калга солтан резиденциясе, Карасубазар – Ширин бәйләре үзәге, Кафа – төрек солтаны вәкиле резиденциясе булган.

Хәрби хезмәт эре һәм вак феодаллар өчен мәҗбүри саналган. Кече яшьтән үк татарлар корал тотарга, атта йөрергә, салкынга, ачлыкка, ару-талуларга түзәргә өйрәнгәннәр. Татарлар, сугышка хәзерләнгәндә, төп урынны күзәтчелеккә (разведкага) биргәннәр. Алдан ук махсус шымчылар җибәрелгән, алар андагы хәлне белешкәннәр, шуннан соң һөҗүм итүче гаскәрнең юл күрсәтүчеләренә әверелгәннәр. Һәрвакытта да көтелмәгәнлек факторын кулланырга тырышканнар. Татарларның иң яраткан кораллары Бакчасарайда коелган кылычлар, ятаганнар һәм хәнҗәрләр булган. Ханлыктагы гаскәр



*Кырым гаскәре Дунай аша чыга. 1566 ел. Төрек миниатюрасы.*

саны 200 мең кешегә кадәр җиткән. Хәрби йөкләмәдән тыш, хан файдасына саугa салымы – табышның биштән бер өлеше түләнгән.


Дәүләтнең сәяси төзелеше ханлыкның халыкара вәзгыятьтә тоткан урынына бәйле булган. Ул үзәкләштерелгән дәүләт булмыйча, аерым территориаль берәмлекләрдән торган. Хан хакимияте төрек солтаны һәм ханның мәҗбүри киңәшчеләре – карачы биләр ихтыяры белән беркадәр чикләнгән була. Хан хакимлеге хокукын алган Гәрәйләр нәселе аксөякләрдән үз хакимлекләренең нәселдән-нәселгә күчүен һәм чикләнмәгән булуын таләп итәләр, әмма моңа ирешә алмыйлар. Кырым ханлыгында затлы татар аксөяк нәселләре, Буҗак (Бессарабия) татарлары һәм нугайлар арасында хакимлек итү өчен бертуктаусыз көрәш барган.

Дәүләт тормышында «кече» һәм «олуг» диваннар зур роль уйнаган. Тиз арада үтәлергә тиешле һәм конкрет чишелеш таләп иткән сорауларны хәл итүдә аксөякләрнең аз санлы төркеме катнашса,



*Дәүләт диваны утырышы. Реконструкция.*

аны «Кече диван» дип атаганнар. «Олуг диван» – «бөтен җир җыены», анда барлык морзалар һәм затлы нәселдән чыккан кешеләрнең дә вәкилләре катнашкан. Карачылар традиция буенча Гәрәйләр нәселеннән булган ханнарны солтан итеп билгеләү хокукын саклап кала алганнар. Бу хокук Бакчасарайда ханнарны тәхеткә утырту йоласында чагылыш тапкан.



*Хан мәчете. Бакчасарай.*

Ханнан соң икенче урында калга солтан булган. Бу вазыйфага хан нәселеннән булган ышанычлы кеше билгеләнгән. Хан үлгән очракта, тәхеткә яңа хан сайлаганчы, ил белән калга идарә иткән. Ул шулай ук, хан сугышка үзе бармаганда, гаскәр башлыгы (башкомандующий) ролен дә үтәгән. Әһәмияте ягыннан икенче баскычта торган нуретдин вазыйфасын үтәүче дә хан нәселе вәкилләре арасыннан сайланган. Ул кече һәм урындагы судларда рәис булган, яу вакытларында кече корпуслар белән җитәкчелек иткән.

Каймакам – хан үзе булмаган вакытта аның урынына калган вәкил, урынбасар, Ор-Капи кирмәне башлыгы. Бу вазыйфаны да күп очракта хан нәселенә караган кешеләр, яисә Ширин нәселе әгъзалары башкарган. Ул чик буйларын саклаган һәм Кырымнан тыш Нугай Урдасын да күзәткән. Казый, вәзир һәм башка министрлар вазыйфалары Госманлы дәүләтендәге шул ук түрәләр вазыйфалары белән туры килгән.

Алда санап үтелгәннәрдән тыш вәлидә солтанша яки олы солтанша вазыйфасы да булган. Бу вазыйфаны ханның анасы яки кыз туганы үтәгән. Дәүләттә тоткан урыны һәм мөһимлеге ягыннан ул калга солтаннан гына калышкан.

# Юмарт хан һәм Мостафа Мөҗаб (әкият)

Бервакыт Кырым-Гәрәй хан аудан кайтып килгәндә аның юлында кара ишәкка атланган Мостафа Мөҗаб очраган. Мостафа ханны туктаткан, әмма аның кем икәнлеген танымаган, сорау биргән:

– И мосафир, Кырым-Гәрәйнең сараена юлны күрсәтмәссеңме? Минем бер сәүдәгәргә 10 мең тәңкә бурычым бар иде, ул, әгәр хәзер үк кире кайтармасам, төрмәгә утыртам дип куркыта, – дигән.

– Син үзең кем буласың соң? – дип сораган хан.

– Минем кем икәнлегемне бары тик әнием генә белә, ул да күптән инде теге дөньяда, – дип җавап биргән Мостафа.

– Сиңа ни өчен кирәк соң ул хан?

– Мин аннан 10 мең тәңкә акча сорап карамакчы булам, бәлки бирер, – дип җавап кайтарган Мостафа.

– Әгәр дә ул сиңа аның кадәр акчаны бирмәсә?

– Алайса бер меңне бирсен!

– Әгәр дә меңне дә бирмәсә?

– Меңне бирмәсә, йөзне бирер!

– Йөз тәңкә дә бирмәсә, нишләрсең? – дип кызыксынган хан.

– Бик беләсең килсә, хөрмәтле әфәндем, хан дигән бай ишәк миңа шул акчасын да кызгана икән, кара ишәгемнең дүрт тоягы да аның хатынының корсагын ярсын, мин шул килеш аңа атланып өемә кайтып китәрмен.

Хан бер хезмәтчесенә Мостафаны үзенең сараена озатырга кушкан, үзе дә тиз генә башка юлдан шунда ашыккан. Мостафадан алданрак килеп, тәхетенә менеп утырган һәм юлдашын кабул итәргә әзерләнгән.

Мостафа ханны танып алган. Ханның:

– Кем син, мосафир? – дигән соравына:

– И, Кырым һәм Мәскәү хакиме, минем кем икәнлегемне Мөхәммәт пәйгамбәр янына оҗмаһка эләккәннән соң сорарсың, – дип җавап кайтарган.

– Сиңа миннән ни кирәк?

– Синең байлыгың, шөһрәтең турында күп ишеттем, – дигән Мостафа, – менә синнән бераз акча сорарга килдем. 10 мең тәңкә бирсәңче.

– Аллаһ бирсен, – дип җавап биргән хан.

– Йа хөрмәтле ханым, мескен бер хәерчегә ярдәм итмичә Аллаһ каршында гөнаһлы булма, меңне булса да бир.

– Аллаһ бирсен.

– Йөзне дә бирмисеңме? – дип гаҗәпләнгән Мостафа.

– Аллаһ бирсен, – дигән хан.

– Ярый алайса, сәламәт һәм имин бул, йа мәрхәмәтле хаким. Ләкин шуны онытма, кара ишәгем синең хәрәмеңнең ишек төбендә бәйләп куелган.

## СЕБЕР ХАНЛЫГЫ

Таркалган Алтын Урда варислары булган бөтен татар дәүләтләренең эчке төзелешендә охшашлыклар да, җирле үзенчәлекләр дә була. Шундый үзенчәлекле татар дәүләтләренең берсе – Себер ханлыгы – Көнбатыш Себердә XIV гасыр уртасында оеша.

Дәүләтнең беренче башкаласы Чыңгы Тура (соңрак Төмән) була. Башлангыч чорында аны Төмән ханлыгы дип атау дөресрәк булыр. XV гасыр ахыры – XVI гасыр башында башкаласы Искер (Себер) шәһәренә күчә. Татарлар үзләре дәүләтләрен «Себер йорты» дип атаганнар.

Ханлык территориясе зур була. Төньяктан ул Обь елгасының түбәнге агымына кадәр җитә. Төньяк-көнбатышта Казан ханлыгы белән чикләшсә, көнбатыш чикләре Урал таулары итәгенә җәелә. Көньяк–көнбатыштан Нугай Урдасы һәм Казакъ ханлыгы белән чикләшә, көньяк чикләре Себер далалары аша уза. Көнчыгыш чикләре Обь елгасының сул ярына кадәр җитә. Себер ханлыгы татар җирләрен генә түгел, Себер халыклары яшәгән башка төбәкләрне дә үз эченә ала. Себер ханнары Урал, Обь, Иртыштагы ханты-мансиларны һәм кайбер башкорт кабиләләрен дә үзенә буйсындара. Татар халкының төп өлеше Тубыл, Тура һәм Иртыш арасындагы җирләргә урнаша.

**Дәүләт төзелеше.** Дәүләт башында хан торган. Аны аксөякләр (биләр, морзалар, тарханнар) сайлаган. Башка ханлыклардагы кебек үк, хан каршындагы дәүләт диванына дүрт карачы би кергән. Ханга шулай ук карачылардан булган вәзир һәм киңәшчеләр ярдәм иткәннәр. Дәүләт аппараты зур булмаган, ул ясауллар, вәзирләр, карачылар, дарухачылар, салым җыючылардан гыйбарәт булган.

Дәүләт олысларга бүленгән, һәрберсенең башында феодаллар торган. Себер ханнары олыслардагы эшләргә бик үк катнашмаган-



*Искер – Себер дәүләтенең башкаласы. Рәссам А.Визель.*

нар, хакимиятне олыс морзаларына һәм олыс биләренә тапшырганнар. Солтаннар, биләр, морзалар һәм тарханнар үз олысларында тулы вәкаләтле хуҗалар булганнар.

Феодаль аксөякләр катламы солтаннар (хан варислары), дәүләт вазыйфалы затлары биләр һәм морзалардан (нәселдән килгән феодаллар) торган. Бинең олы улы – би, аның калган туганнары морзалар булган. Биләр һәм морзалар яулап алынган җирләрдә яшәүчеләрдән ясак җыйган һәм аның билгеле бер өлешен хан казнасына тапшырганнар. Феодалларның тагын бер катлавы – тарханнар. Бу исем би һәм морзаларга хан тарафыннан үзенә күрсәткән аеруча хезмәтләре өчен бирелгән. Тархан һәм аның милке кагылгысыз булган, ул ханга үз дружинасы белән хезмәт иткән.

Феодаль катлауга шулай ук җирле халык вәкилләренең бер өлеше – иштәк һәм вогул (манси) башлыклары кергән. Себернең башка халыклары (иштәк, вогул, югра һәм самоедлар) «кара халык» катлавына кертеп каралган.

Дәүләт белән идарә итү ярымхәрби характерда булган. Феодаллар үз сакчылары, хезмәтчеләре, һөнәрчеләре, эре сәүдәгәрләре белән бергә ныгытылган шәһәрләрдә яшәгәннәр. Һөҗүм куркынычы булганда яисә сугышлар вакытында олыс биләре хәрби көчләре белән аның янына тупланган.

Гаскәр кавалериядән һәм җәяүле сугышчылардан торган. Әмма таркау гаскәрне олыслардан тиз генә бер йодрыкка туплау кыен булган. Хан үзе даими хәрби дружина (нугай гвардиясе) тоткан.



*Ияр.*



*Ук кынысы.*

Сугыш кырында татар сугышчылары күчмәннәргә хас тактиканы кулланганнар: атлы укчылар дошманнар өстенә оста хәрәкәтләр белән ук яңгыры яудырганнар. Җәяүле гаскәрдә бик оста күзәтчеләр булган, алар тапкан мәгълүматка нигезләнеп, гаскәр дошманга искәрмәстән һөҗүм иткән. Сугышчыларның төп кораллары ук һәм җәя, сөңгеләр, кылычлар, хәнҗәрләр, сугыш балталары булган. Моннан тыш татарларда артиллерия дә булган. Сакланыр өчен көбә кием, очлымнар (шлем) кигәннәр.



*Себер татарларының кораллары һәм хәрби киемнәре.*

Аксөякләрдән тыш барлык халык – терлекчеләр, игенчеләр, аучылар һәм балыкчылар – олысның «кара халкы» дип аталган. Алар олыс бие отрядында хәрби хезмәт үтәргә, феодалга терлек бирергә яисә үзләре җитештергән башка ризыклата салым түләргә тиеш булганнар.

Буйсындырылган күрше кабиләләрнең кара халкы да, нигездә, җәнлек тиреләре белән ханга ясак түләргә һәм ханның хәрби яу чабулары өчен сугышчылар әзерләп

бирергә тиеш булган. Ханлыкның үзәк өлешләрендәге көтүлекләр, сөрүлек җирләр һәм су чыганаклары ханның, феодалларның шәхси милке булып саналган. Феодаль мөнәсәбәтләр патриархаль-ыруглык калдыклары белән үрелеп барган.

**Исламның роле.** Себер татарлары арасында ислам инде Үзбәк хан вакытында ук киң тарала башлый. Күчем хан идарә иткәндә дин үсешендә тагын бер күтәрелеш чоры күзәтелә. Себер ханлыгы җәмгыяте үсешендә исламның роле гаять зур. Ханнарның мөселман хокукы (шәригать) һәм традицион төрки хокук нормаларына нигезләнгән хокук институты булган. Мөселман руханилары (шәехләр, хаҗилар һ.б.) башында торган сәедләр дәүләттә аеруча зур йогынтыга ия булганнар һәм дәүләт эшләрендә дә зур роль уйнаганнар.

Исламны кабул иткәннән соң, гади халыкның рухи тормышында ислам мәдәнияте йогынтысы көчәя. Фольклорның төрле жанрлары үсеш ала. Халык арасында тарихи риваятьләр, әкиятләр, җырлар киң таралыш ала. Аларда Себердә яшәүче татар халкының тормышы чагылыш таба.

**Шәһәрләр**. Себер ханлыгында 20 гә якын кечерәк шәһәрләр булган: Искер, Кызыл Тура, Тон Тура, Яулы Тура, Тархан кала, Чыңгы Тура һ.б. Шәһәрләрдә җирле феодаллар, сәүдәгәрләр һәм һөнәрчеләр яшәгән. Шәһәрләр калку елга ярларында урнаша һәм туфрак өемләре белән ике яки өч рәт канаулар ярдәмендә ныгытылган була.

Ханлыкның башкаласы Искер әйбәт ныгытылган кирмән була. Иртышның текә ярлары аны саклап торган. Кирмән эчендәге корылмалар агачтан төзелгән була. Искернең мәйданы шулай ук зур булмый, анда хан сарае була, ханның якыннары, гаскәре, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр яши. Хан казнасы да биредә сакланган. Искер нык үскән сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге була.



*Себер татарлары.*

Татар кабиләләре утрак һәм ярымкүчмә тормыш рәвеше алып барганнар, аучылык һәм балык тоту белән беррәттән, терлек һәм ат көтүләре дә тотканнар. Терлекчелек татарларның төп шөгыльләре була. Чөнки киң далалар терлек үрчетү өчен бик уңайлы була. Татарлар ярымкүчмә һәм күчмә тер-

лекчелек белән шөгыльләнгәннәр, атлар, мөгезле эре терлек, сарыклар, кәҗәләр үрчеткәннәр. Тайгалы урманнар һәм сазлыклар булу күчмә терлекчелек өчен кайбер уңайсызлыклар тудырган, әлбәттә. Татарлар терлекчелектә җитештерелгән азык-төлек белән сату-алу иткәннәр. Тубыл, Иртыш һ.б. елгалар буйларында борай, арпа, солы, тары игүче зур булмаган игенчелек үзәкләре дә булган.

Аучылар кеш һәм кара төлке, тиен, куян һәм сусар, поши, кабан, кыр тәкәләрен, кыр казлары һәм үрдәкләрен һәм көртлекләр аулаганнар. Кыйммәтле җәнлек тиреләреннән киемнәр теккәннәр, моннан тыш аларны алмашу һәм сату өчен дә кулланганнар. Аучылык җәяүле булган, кышын исә ауга чаңгыларда чыкканнар. Эре елга һәм күлләр тирәсендә яшәүче татарлар өчен, аучылык белән беррәттән, балыкчылык та зур роль уйнаган. Археологлар тимер кармаклар, чиерткечләр, ятьмә калдыкларын, шулай ук чуртан, кәрәкә, мәрсин балыгы сөякләрен еш табалар. Төрле үлән һәм кыргый җиләк–җимешләр җыю да киң таралган була.

**Көнкүреш**. Себер татарларының көнкүреше күрше халыкларның көнкүрешеннән күпкә аерылып торган. Татарлар төрле торакларда яшәгән, бу, беренче чиратта, табигать шартларына, утраклык дәрәҗәсенә бәйле булган. Агач бүрәнәдән өелгән, яссы түбәле йортлар белән беррәттән, балчык белән сыланган, диварлары читәннән үрелгән ярым җир өйләр дә булган. Шәһәрләрдә йортларны ылыслы агачлар бүрәнәсеннән салганнар. Искернең кайбер йортлары кирпечтән төзелгән (шәһәрдә кирпеч сугу җайга салынган була). Күчмә татарлар даладагы кебек киез юрталар корганнар.




*Искер XVI гасырда. А.Зыков реконструкциясе.*

**Һөнәрчелек.** Утрак тормыш алып барган шәһәр һәм авыл халкы һөнәрчелек белән шөгыльләнгән: чүлмәкләр, бакыр савыт-саба ясау, металл кою һәм эшкәртү, тукучылык киң таралыш ала. Зәркәнчеләр пыяла һәм асылташ мәрҗән бөртекләреннән муенсалар, алкалар, кашлы йөзекләр, бакыр һәм көмеш беләзекләр ясаганнар.

**Кием-салым.** Сәяхәтчеләр татарларның кыйммәтле җәнлек туннардан йөрүләре турында язалар. Кием-салым тегү өчен шулай ук кычыткannан эрләнгән җепләрне һәм кыргый җитен кулланганнар. Аяк киемен мехтан һәм тиредән әзерләгәннәр. Кышын сарык тиресеннән эшләнгән итекләрдән йөргәннәр.



*Хатын-кызларның бизәнү әйберләре.*



Себер татарлары, нигездә, йорт хайваннары – ат, сыер, сарык, шулай ук кыргый хайваннар һәм кошкорт ите белән тукланганнар. Кыргый үсемлекләр, аларның тамырларын һәм җимешләрен дә яратып кулланганнар.

Хуҗалык итүнең төрле формалары үсеш алу татарларда башка халыклар белән сәүдә итү һәм товар алмашуга этәргеч ясый. Дәүләттә нык үскән сәүдә мөнәсәбәтләре урнашкан. Ханлык Европадан Кытайга таба барган борынгы кәрван юлында урнашкан. Шулай ук Себер елгалары – Иртыш, Тубыл, Тура буйлап та сәүдә юллары уза. Ханлык Кытай, Урта Азия, Казан ханлыгы, Нугай Урдасы белән дә сәүдә мөнәсәбәтләрендә тора. Себер белән Урта Иделне тоташтырган сәүдә юлы Кама буйлап Пермьгә, Сылва һәм Чусовая буйлап Урал таулары аша сузыл-

ган. Ханлык эчендә ашамлыклар, мех, тире, һөнәрчелек эшләнмәләре белән алмашу һәм сәүдә итү дә яшәп килә.

Урта Азиядән килгән сәүдә кәрваннары ефәк һәм киҗе-мамык тукымалар, келәмнәр, кипкән җимешләр, савыт-саба белән сәүдә иткәннәр. Кытайлар ефәк, фарфор савыт-саба, бизәнү әйберләре китергәннәр. Себер татарлары үзләре дә Кытайда һәм Урта Азия базарларында сәүдә иткәннәр. Себердән кыйммәтле җәнлек (кеш, төлке) тиреләрен, ау кошларын алып барганнар. Мәсәлән, Бохара әмире Габдулланың Себер ханы Күчемнән үзенә ау лачыннары җибәрүен сораганлыгы мәгълүм.


*Урта Азиядән кайтарылган комган.*

Себер ханлыгының сәяси тарихы тулысынча өйрәнелмәгән, чөнки сакланып калган тарихи чыганаклар күп түгел. Дәүләт 1420–1450 елларда Себер билеге буларак формалаша дип санала. Аның тарихы Шәйбаниләр дәүләте һәм Бохара ханлыгы белән тыгыз бәйләнештә булган. Соңрак ханлыкка әйләнгән дәүләт 1505–1506 елларда гына берникадәр мөстәкыйль була. Әмма ул һаман да Бохара хакимнәренә бәйле булган.

Ибакъ хакимлек иткән чорда (1464–1495) ханлык шактый ныгый, халыкара эшләрдә дә җитәрлек көчкә ия була, танылу казана.

Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, 1555 елда Себер морзасы Ядегәр, Мәскәү кулы астына алуын сорап, Явыз Иванга үз илчелеген җибәрә. Себер йорты Мәскәү вассалына әверелә. 1563 елда тәхеткә Себернең соңгы ханы Күчем менә. Чыңгыз нәселеннән булган Күчем ханлыкның халыкара абруен ныгыту өчен хәрби хезмәткә нугайларны чакыра. Шул максатларны күздә тотып, ул үзенең улы Галине нугай морзасы Тинәзмәтнең кызына өйләндерә, үз кызын исә нугай хакиме Акморзага бирә. Күчем дәүләттә исламны ныгытырга омтыла, моның өчен Бохарага махсус илчеләр җибәрә, Себергә мөселман динен таратучыларны чакырта.

Күчем Мәскәүдән бәйсез сәясәт алып барырга тырыша. Әмма көчләре җитәрлек булмый. Бохара ханы Габдулла да үз эчке эшләре белән мәшгуль була һәм аңа ярдәм күрсәтә алмый. Мәскәү дә, элеккегечә вассал бәйлелек белән генә чикләнмичә, ханлыкны тулысынча үз кулларына алырга тырыша.

**Ермак явы.** Патша Иван IV, Себер ханлыгын яулап алу өчен, Уралда зур биләмәләре булган Строгановлар ярдәменә таянырга ниятли. 1574 елның 30 маенда бирелгән патша грамотасы белән аларга вотчина җирләре бүләк итә. Бу җирләр чит мәмләкәт җирләре – Лозьва, Тавда һәм Тубыл елгасы буйларындагы барлык җирләр була. Бер үк вакытта Строгановларга патша казнасына 20 ел буена салым түләүдә өстенлекләр дә бирелә. Бу аларга Себер җирләрен яулап алуны җиңеләйтү өчен эшләнә.

Строгановлар үзләренә ярдәмгә бу вакытта Идел буенда юлбасарлык иткән Идел казакларын чакыралар. Казаклар һәм аларның атаманнары Ермак 1582 елда яуга күтәрелә.

Тура елгасын кичкәндә, казакларга Япанча җитәкчелегендәге татар отряды һөҗүм итә, әмма Япанча тар-мар ителә. Ермак яу вакытында татар авылларын талый, анда яшәүчеләрне үтерә. Рәхимсез сугышлардан соң, казаклар Чыңгы Тура шәһәрен басып алалар, халыкның бик күп икмәген, терлекләрен, җәнлек тиреләрен талыйлар.

Күчем отрядлары бик еш һәм сиздермәстән Ермакка һөҗүм итеп тора. 1582 елның 23 октябрендә Иртыш елгасы буенда хәлиткеч сугыш була. Иң авыр һәм иң кирәкле вакытта Күчемне иштәкләр һәм вогуллар ташлап китә. Татарларның Мәмәткул җитәкчелегендәге гаскәренең бер өлеше тар-мар ителә. Хәлнең котылгысызлыгын аңлап алган Күчем башкалага кайта, казна һәм байлыкларны алып, Искер шәһәреннән китеп бара. Казаклар зур тантана белән башкалага керәләр. Алар биредә шулай ук бай гына табышка, бигрәк тә кеш һәм кара төлке, тиен һәм сусар тиреләренә, ия булалар.

Әмма Искер шәһәренең казаклар тарафыннан алынуы Себер ханлыгы яшәүдән туктавын белдерми. Күчем үзенең кешеләре белән Бараба далаларына күчеп китә һәм анда хакимлек итә, көньяк олысларда ясак җыя башлый. 1585 елның 5 август төнендә Күчем Искердән хәйлә белән казакларны чакырып чыгара һәм аларга искәрмәстән һөҗүм итә. Иртыш буендагы көтелмәгән бу төнге һөҗүм вакытында казаклар кырып салына, ә Ермак үтерелә. Ул үлгәннән соң, Искердә калган казаклар тиз арада Себер ханлыгының башкаласыннан чыгалар һәм Мәскәүгә кайтып китәләр. Ә Искердә яңадан татар дәүләтчелеге урнаша, башкалада Күчем үзенең улы Галине калдыра. Әмма ләкин бу вакытта Тайбугалар нәселенең абруйлы олыс биләре үзара сугыша башлыйлар. Халык көчләре бүленә.

Ермакның хәрби походы Себер ханлыгын көчсезләндерә, шулай итеп, аны моннан соң яулап алуларны җиңеләйтә.

1586 елда Мәскәү яңадан Себер ханлыгына каршы гаскәр туплый. Бу юлы ул стрелецлар отрядыннан гыйбарәт була. Сәйдәк



Күчем хан.
Рәссам
Р.Әминев.

Ермак.



җитәкчелегендәге Тайбугалар басып алучыларга каршы бернинди каршылык та күрсәтмиләр. Күчем бу вакытта далада була. Рус елъязмалары язганча, 1588 елның җәендә Сәйдәк һәм аның яраннары руслар тарафыннан сый мәҗлесенә чакырылган була, биредә аларны бәйләп салалар, күпләрен үтерәләр.

Тайбугалар арасындагы үзара ызгыш-талашлар Себер татарларын буйсындыру эшен бермә-бер җиңеләйтә. Әмма әле ханлыкның бер өлеше һаман да рус басып алуларына каршы торган Күчем тарафыннан идарә ителә. 1598 елда руслар зур гаскәр белән Күчемгә һөҗүм итәләр. Канкойгыч сугыштан соң Күчем җиңелә. Аның уллары, туганнары, оныклары, бик күп биләр һәм морзалар юк ителә. Күчемнең гаиләсе әсир ителә. Күчем үзе һәм аның улы Гали качып котылалар. Мәскәү Күчемне дипломатик юл белән буйсындырырга тырышып карый, әмма хан риза булмый. Руслар да тулысынча җиңүгә ирешә алмыйлар. Күчем моннан соң да әле Тубыл далаларында һәм Урал таулары тирәсендә русларга каршылык күрсәтүен дәвам итә. Яшәвенең соңгы елларында Күчем хан сукырая һәм 1601 елда вафат була.

Себер ханлыгы XVI гасыр буена яшәвен дәвам итә. 1598 елда рус патшасы үзен «Себер патшасы» дип игълан итә. Себер Мәскәү патшылыгының бер өлешенә әйләнә. Әмма Күчемнең уллары һәм оныклары XVII гасыр буена Себер ханлыгын торгызу өчен көрәшәләр.

Себер ханлыгы җимерелүнең төп сәбәбе русларның техник яктан өстенлегендә генә түгел, ә бәлки ханлыкның үз эчендәге таркаулыкта да була. Һәрбер татар биенең үзенең хәрби отряды булган, ул, шулай итеп, ярыммөстәкыйль хаким ролен дә үтәгән. Иштәк һәм во-

гул кабиләләре Үзәк хан хакимиятенә тугры булмыйлар. Сугыш вакытында татар халкының иң күренекле вәкилләре, рухани җитәкчеләр, гади кешеләр күпләп һәлак була. Матди һәм мәдәни кыйммәтләр, архивлар һәм китапханәләр юк ителә, шәһәрләр җимерелә.

Үзәк хан хакимиятенең көчсезлеге, эре феодалларның – олыс кенәзләренең һәм биләрнең үзәктән тайпылулары Себер татар дәүләтенә яный һәм аның һәлакәтен якынайта.

## Әхмәтгәрәй хан (риваять)

Борынгы заманда Әхмәтгәрәй хан булган. Ул үзенең хатынын сатып алган колына биргән. Гәрәй ханның атасы моны ишеткәч, бик ачуланган. Киявен исертеп, ат койрыгына салган. Өч көн ат койрыгында йөргән Гәрәй хан исән калган, әмма аны кайнатасы, улының кинәше белән башын чаптырып үтертте. Гәрәй хан урынына унике яшьлек Күчем хан булып калды. Вакыт җиткәнче аның урынында Богай Солтан халыкны тотып торды.

Күчем хан Том җирен яратмады:

– Монда оро-чокыр күп, мал егылса үләр, бала егылса үләр, аннан күчик, – диде.

Җәмәгать белән мәслихәт кылып күчтеләр. Томнан Тубылга күчкәндә Күчем хан Барабада торган кешеләргә әйтте:

– Җирегез яман монда. Безнең белән кушылып китегез! Тубылга барып торыйк.

Барабада торган халык аның сүзенә күнмәде:

– Күчегез, без артыгыздан җитәрбез. Безнең монда көтә торган йезе – ау калды, аны аласыбыз бар, – диде.

Күчем хан:

– Тиз җитегез! – дип чыгып китте, алар калдылар. Тубылга барып, шәһәр кылып торды. Бараба халкының үз җирендә калганын белеп, Күчем хан әйтте: «Килең!» Халык бармады. «Алар бараба булсын», – дип ат куып китте. Ул чактан халкыбызның аты бараба булды.

Күчем хан Тубылда берничә вакыт торды. Урыс җиреннән, патшадан качып, өч угры килде. Аларның башлап йөргән кешесенең аты Ярмак булган. Ул Ярмак Күчем ханга килде. Боларның телен һичкем белмәде, урыслар аларның телен белмәде. Алар күп торганмы, аз торганмы – телне аңлап белделәр.

Ярмак ханга килде, әйтте:

– Күчем хан, миңа бер бога тиресе зурлыгы җир бир, – диде.

Күчем хан солтаннарын, яхшыларын җыйды, алардан мәслихәт сорады. Яхшылары әйтте:

– Бер бога тиресе киңлеге җир күп булмас, анча җир бирик! – диде.

Ярмак бер бога тиресе алды, аны нечкә җептәй телде, түгәрәк сызды, алдап-ялдап, күп җир алды.

Ханның боерыгы белән кешеләр чыгып карадылар:

– Кяфер, – диделәр, – күп җир алды.

Хан әйтте:

– Ул җир күп түгел, җиребез монда күп, үзебез бирдек, инде тавыш булмасын.

Ярмак сука ясады, җирне сөрде, арыш чәчте. Чәчкәч, урыслар китте. Икенче елда урыс килеп, арышын урып алды, урын алып, клад куйды. Өченче ел да килде.


## Күчем һәм Ермак турында риваять (Төмән өлкәсе Вагай районы татарларыннан язып алынган)

Әйе, Күчем патша картларны тыңларга теләмәгән, шуның белән үзенең патшалыгын харап иткән. Аңа рус патшасыннан качып Ермак килгән. Ул анда бик күп кешеләрне үтергән, рус патшасы аны асып куярга теләгән, ул безнең патшага качкан да инде. Күчем аны каршы алган. Ермак бик яхшы тимерче булган, акыллы кеше, яраткан аны безнең патшабыз. Картлар әйтәләр: Ермакка ышанма, [әмма] Күчем аларны тыңламаган, аны кая теләсә, шунда җибәргән. Ермак анда бер ел яшәгән, бар нәрсәне күзәткән һәм качкан. Аннан соң, бераз үткәч, патша янына безнең [картлар] килгәннәр һәм әйткәннәр: хәлләр начар, патша, Тубыл буйлап йомычка йөзә, бик күп йомычка, яхшы булмас, гаскәреңне җыйна! Тагын тыңламаган Күчем картларны. Ә анда руслар Тубылда үзләренә кораблар төзиләр, төзеп бетерәләр, аларга кереп утыралар, киләләр һәм Күчемнән патшалыкны тартып алалар да, бу шулай була да, бездә бу барлык китапларда да язылган.

# ТАТАР ХАНЛЫКЛАРЫ АРХИТЕКТУРАСЫ

Алтын Урда мәмләкәте таркалгач оешкан Казан, Касыйм, Себер, Әстерхан, Кырым йортлары, Нугай Урдасы, Олуг Урда дәүләтләрнең архитектурасы Алтын Урданың гомум мәдәнияте җирлегендә һәм кайвакыт (мәсәлән, Кырымдагы кебек) зур үсеш алган борынгы җирле төзелеш традицияләренә нигезләнгән.

Татарлар төрле табигый-географик (урманнар, таулар, тау итәкләре, далалар, диңгез яр буйлары) һәм климатик зоналарда яшәгәннәр, ә аларның мәдәнияте төрле урыннарда төрле халыкларның йогынтысын кичергән. Шуңа күрә төрле илләрдәге шәһәр һәм авыллар, мәчетләр, торак һәм хуҗалык корылмаларының үзенчәлекле сыйфат-билгеләре була, төзелеш конструкцияләре һәм аларны бизәү ысулларында да төрлелек күзәтелә. Әмма шул аерымлыкларга карамастан, аларны теләсә кайсы татар торулыгына хас төгәл планнар булмау, бер-ике мәчет тоту, мәхәлләләргә бүленеш кебек уртак билгеләр берләштерә. Кырым татарлары өчен каһвәханәләр дә булу мөһим. Алар бер үк вакытта кунакханә һәм ир-атлар клубы хезмәтен дә үтәгәннәр. Ә хатын-кызлар өчен аралашу урыны булып зиннәтле мунчалар хезмәт иткән. Шәһәр яки авыл читендә каберлекләр урнашкан. Кабер өстенә мәрмәр һәм таш плитәләр (баш таш, кабер ташы) куелган, ә кайчакта төрбәләр корылган.



*Алупкада татар йорты. К.Боссоли гравюрасы.*

Утарлар, гадәттә, таш, балчык, бүрәнә дивар яки үрмә читән белән әйләндереп алынган. Каралты-куралар иркен урнашкан, бер-берсе белән тоташмаган. Халыкның нинди климатик шартларда яшәвенә бәйле рәвештә йортлар агачтан, таштан, саманнан салынган. Аларның эчке төзелеше шәригать кагыйдәләренә һәм теге яки бу дәрәҗәдә күчмә торак традицияләренә нигезләнеп корылган. Мәсәлән, йорт хатын-кыз һәм ир-ат өлешләренә бүленгән, тәрәзәләр урам ягына түгел, ишегалдына караган. Күчмә архитектура формалары саналган чатырлар, тирмәләр, көймәле арбалар да сакланып калган.



*Борынгы Казан. Рәссам Р.Заһидуллин.*

**Йортларның эчке төзелеше.** Эчке яктан барлык татар торак йортлары да, нигездә, бертөрле эшләнгән. Мәсәлән, ачык төстәге келәмнәр, идәнгә җәелгән бизәкле киезләр, дивар буйлап урнаштырылган киң һәм тәбәнәк сәкеләр татарлар яшәгән барлык урыннарда да очрый. Юрганнар һәм мендәрләр сандык өстенә өеп куелган яки махсус куышка урнаштырылган. Күренә торган урынга, ачык шүрлекләргә җиз һәм балчыктан ясалган савыт-саба куелган, сөлгеләр эленгән. Өй җиһазларыннан тәбәнәк өстәлләр, урындыклар, көзгеләр, шәмдәлләр, ашъяулыклар, тастымаллар, пәрдәләр булган. Әгәр дә өйдә кунаклар өчен аерым түр бүлмә булса, иң яхшы әйберләр (келәмнәр, савыт-сабалар) шунда тупланган.

**Хан сарае.** Гадәттә, манаралы диварлар белән уратып алынган хан сарайларында хан гаиләсе яши торган пулатлар, Дәүләт диваны бинасы, сарай мәчете, хан каберлекләре, бакчалар, сак хезмәте өчен урыннар, хуҗалык корылмалары булган. Бөтен хан сарайларына да диярлек хас элемент – хан яши торган пулат янәшәсендәге биек күзәтү манарасы. Мөгаен, боларның нигезендә Алтын Урда



*Бакчасарайдагы хан сарае.*



ханы сараеның, Сарайдагы Чыңгызиларның нәсел резиденциясенең беренче үрнәге ятадыр.

**Мәчетләр.** Бөтен мөселман дөньясындагы кебек, татарларда да мәхәллә, җәмигъ мәчетләре, мәчет-мәдрәсә, базар мәчете, хәрбиләр мәчете, зират мәчете һ.б. төрдәге мәчетләр булган. Йортлар кебек үк, алар кирпечтән, таштан, агачтан, балчыктан (салам яки чыбык катнаштырылып) салынган. Тирмә кебек үк тиз сүтеп-җыела торган конструкцияле күчмә мәчетләр дә булган. Мәчет бинасыннан күпкә биегрәк торган очлы башлы нечкә манарасы аны аеруча тәэсирле иткән. Кырым һәм Казан ханлыкларында атаклы итальян архитекторларның эшләве мәгълүм. Бакчасарайда Алевиз (Алоизио да Милано) капкасы бүгенгә кадәр сакланган.

Татар шәһәрләренең архитектура стиле җирле традицияләр юнәлешендә, шулай ук XV йөзнең беренче яртысында алга киткән ислам дәүләтләрендә таралган госманлы стиле йогынтысында үскән. Ул вакытларда төзелеш сәнгатенә Көнбатыш Европа йогынтысы да үтеп керә башлаган. Мәсәлән, Кырым һәм Төркиядә XV–XVI гасырның башында ук француз һәм итальян архитектурасы йогынтысы күзәтелгән. Бакчасарайда һәм Казанда Италия архитекторларының булуы да билгеле. Алар Европадан яисә Мәскәү аркылы да килә алганнар.



*Алевиз капкасы*



*Казан кирмәнендә Нургали мәчете. Н.Халит реконструкциясе.*



*Кырымдагы Мимар Синан мәчете.*

Мөселман дөньясы чикләрендә үскән татар архитектурасы урта гасыр мөселман төзелеш сәнгатенең төньяк тармагын тәшкил иткән. Вакыт Урта гасыр татар корылмаларын аямаган: йөзләрчә шәһәрләр, шул исәптән Биләр, Сувар, Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Болгар кебек калалар тулысынча җир йөзеннән юк ителгән.

Алтын Урда архитектурасын хаклы рәвештә Иран, Урта Азия, Төркия төзелеш сәнгате белән тиңләштереп була. Ул заманнарның төзелеш үзенчәлекләре Казан һәм башка татар шәһәрләренең хәзерге архитектурасында яши, яңадан торгызыла.

# ТАТАР МИЛЛИ КИЕМЕ ТАРИХЫ (XIII–XVI ГАСЫРЛАР)

Алтын Урда чорында кием үз эченә төрки-монгол һәм кыпчак элементларын берләштергән. Бигрәк тә шәһәр халкы киемендә Урта гасыр Кытай сәнгатенә нигезләнгән Үзәк Азия формалары чагылыш тапкан. Шартлы рәвештә бу дәвер кием тарихын ике өлешкә бүлергә мөмкин. Беренчесе – монгол мәдәниятенең үтеп керүе һәм барлык өлкәләрдә дә аның өстенлек итүе; икенчесе – ислам диненең ныклап таралуы белән бергәттән җирле халык йолаларының, гадәтләренең өстенлек итүе.

Алтын Урда дәверендә дә, элекке чорлардагы кебек үк, кием ыштан, күлмәк һәм халаттан гыйбарәт булган.

Төрки-монгол йолаларына туры китереп тегелгән халат киң җиңле, тезгә кадәр озынлыкта булган һәм уңнан сулга каплатып киелгән. XIV гасыр урталарында исә халат итәкләре озынайган һәм ул, уртадан киселеп, төймәләр белән каптырылган, яисә бернәрсә белән дә беркетелмәгән. Бай кешеләрнең халаты ефәктән тегелгән. Кыш көне халат өстеннән киң һәм кыска җиңле, тезгә кадәр озынлыкта кафтан кигәннәр.

Халат астыннан күлмәк кигәннәр. Кечкенә балаларның күлмәген тулы бер тукымадан теккәннәр. Өлкән кешеләрнекерә өстәмә ялгаулар тегелгән. Күлмәккә басма яка куелган. Яшь хатын-кызның бәйрәм



*Аксөякләр киеме. З.Доде реконструкциясе.*



Хан белән ханбикә тәхеттә.



күлмәге матурлыгы белән аерылып тора. Ул киң җиңле, басма якалы булган.

Хан күлмәгенең җиң очлары энҗе-мәрҗән, кыйммәтле ташлар, алтын җепләр белән чигелгән.

Күлмәк өстеннән киелгән җиңсез күлмәк хатын-кыз киеменең аерылгысыз бер өлеше булып торган. Аны парча яки кыйммәтле ефәк тукымадан теккәннәр, чит-читләренә ефәк тасмалардан кайма тотканнар.

Ыштанның беренчеләрдән булып төркилар тарафыннан кулланыла башлавы һәм әкренләп башка халыкларга үтеп керүе билгеле. Галимнәр фаразлавынча, Алтын Урдада ыштанның ике төре кулланылган. Беренчесенең киң балагы югары өлешендә бергә тегелеп, бил өлешендә бау белән бәйләп куелган. Икенче төр ыштанның ике балагы арасына турыпочмак сыман өстәмә тукыма тегелгән. Мондый ыштан формасы белән «п» хәрефен хәтерләткән. Аны киеп, ат өстендә җилдерү бик уңайлы булган. Ыштан балаклары балтырга яисә тубык сөягенә кадәр озынлыкта булган.

**Хәрби кием.** Яугирләр (сугышчылар) башларына очлым (шлем) һәм түгәрәк тимер такыяләр кигәннәр; бу такыяның артыннан салынып төшкән каплавыч яугирләрнең муеннарын саклаган. Алар өсләренә дә көбәкүз кием кигәннәр, чалбарлары көбәкүздән яки калын тиредән тегелгән. Сул кулларына түгәрәк тимер калкан тотканнар. Байларның бу калканнары төрле язулар һәм рәсемнәр, асылташлар белән бизәлгән булган. Гади сугышчылар калканының уртасы гына

тимердән ясалган була, читләре исә камыш яки чыбыктан үрелә һәм төсле җепләр белән бизәлә. Калкан сугышчыны ук һәм кылычтан саклаган.

Сул якка кәкре кылыч асканнар, яннарына садак (җәя һәм ук кынысы) такканнар. Кулларына озын, нәзек сөңге тотканнар. Татарларның гаскәре күбесенчә атлы булган, ягъни җайдаклардан торган. Иярнең артына сарык тиресеннән тегелгән капчык асканнар, әгәр су аркылы чыгарга туры килсә, шуны өреп тутырып, башын бәйләп, өстенә утырып йөзеп чыкканнар. Иярләренә эремчектән кайнатып ясалган корт тутырылган капчык асканнар; ашыйсылары килгәндә, шуны суга яисә шулпага катып эчкәннәр.

Сугышта көбәкүз күлмәкләрдән тыш, күкрәкне саклар өчен ка-



Калкан.



Көбәкүз күлмәк.



Көбә кием.

лын тире күкрәкчәләр дә кигәннәр. Аларны җилкәгә каешлар белән беркеткәннәр һәм тимер пластиналар белән ныгытканнар. Мондый сугыш киемнәре эшкәртелгән калын тиредән һәм сырган киездән эшләнгән.

**Баш киеме**. Алтын Урда чорында ир-ат баш киеме очлым формасында (артында озын колакчынлы) булган. Төрки-монголлар арасында әлеге баш киеме Урта гасыр башынларында ук кулланылган. Аны чөйгә охшатып киселгән дүрт киез кисәгеннән башын бераз очлайтып теккәннәр.

Баш киеме кызыл киездән үрелгән яки тукымадан киселгән кәйтән (тасма) белән бизәлгән. «Бәхет төене» дип атап йөртелгән әлеге тасма Алтын Урда чоры татар киемендә киң таралыш тапкан. Кәйтән Евразиядә яшәүче төрки-монгол халыкларында, шул исәптән Идел-Урал татарларында әле бүген дә сакланып калган.

Ханбикәләр монголлардан килгән биек һәм катлаулы формалы «бокка» дип аталган баш киеме кигәннәр. Аның очын тавис кошы каурыйлары белән бизәгәннәр. Бай кешеләр башларына кыйммәтле тиреләрдән тегелгән очлы, ике чите кайтармалы бүрек кигәннәр. Гади халыкның бүреге киездән һәм сарык тиресеннән тегелгән.

Борынгы татарларда ирләр чәчләрен алдан колакка кадәрен кырып алдырганнар, артта калган чәчләрен кытайлар шикелле берничә толымлап үргәннәр, толымнарны салындырып яисә җыеп йөргәннәр. Хатын-кызлар чәчләрен кырмаганнар, ә берничә толым итеп үреп, төрле якка салындырып йөргәннәр.

Хатын-кыз баш киеме тукымадан эшләнгән, баш түбәсе ачык яки ябык булган, төрле сәйләннәр, җиз тәңкәләр һ.б. бизәлгән. Чигә





*Монгол баш киеме.*

*Бокка кигән ханбикә.*




*Очлым.*

өлешендә асылмалы сыргалар булган. Алар да кыйммәтле ташлар, тәңкәләр белән бизәлгән.

XVI гасырда бай татар хатын-кызлары күп төрле тәңкәләр, ташлар белән бизәлгән конуссыман баш киеме кигәннәр. Гасырлар дәвамында ул барыбызга да мәгълүм калфакка әверелгән.

Билбау бу чорда да өс киеменең мөһим бер өлеше булып торган. Билбауга төрле символик, йола һәм тылсым мәгънәләре салынуы билгеле. Күн яки хәтфәдән тегелгән, төрле каптырмалар, алтын-көмеш тәңкәләр белән бизәлгән билбау ир-ат һәм хатын-кыз киемендә киң кулланылган.

Билбауга кылыч, кечкенә калта (букча), су эчәр өчен зиннәтле касәләр тагылган. Букчаларга төрле кирәк-яраклар, акчалар салганнар. Казан татарлары аңа бөтиләр дә салганнар, һәм бу очракта ул хәситә функциясен үтәгән. Хәситә тәңкәләр белән бизәлгән яисә алтын җепләр белән чигелгән.





*Алтын Урда һәм ханлыклар чоры читекләре.*

Ир-атларның түгәрәк яки сорау билгесе формасында алка тагуы бу чорның тагын бер үзенчәлеге булып тора, гадәттә, алканы бер генә колакка такканнар. Соңрак мондый гадәт Дон казакларына күчеп, аларда сакланып калган. Йөзек формасында эшләнгән мөһерләр дә булган. Болар Алтын Урда чорында гына түгел, соңрак чорларда да очрый.



*Ефәк ирләр халаты. Алтын Урда.*

Аяк киемнәре арасында һәр чорда төп урынны читек алып тора. Бу чорда да читекләр элеккеге рәвешләрен саклап калган. Читекнең кунычы һәм балтыры ике бертөрле кисәктән тегелгән. Читек балтырны тулысынча каплап торган. Кунычының өске һәм аскы өлешләре бертигез киңлектә булган. Читекнең табаны – калын, ә очлары өскә каратып бөгеп тегелгән, үкчәсез булган. Читеккә киез олтан салынган. Мондый читекне утрак тормышта яшәүчеләр бик яратып киеп йөргән. Аяк киеменә, элеккеге чорлардагы кебек үк, тире аппликацияләр каелган, байларның читек балтыры ефәк һәм парча белән бизәлгән.

**Ислам чоры.** Алтын Урдада исламның дәүләт дине буларак кабул итүе һәм таралуы тормыш–көнкүрешнең бөтен якларына да, шул исәптән киемгә дә йогынты ясаган. Әмма эссе чүлләрдә яшәүгә җайлашкан гарәпләрнең киенү рәвешенә сукырларча иярү булмаган. Чөнки һәр халыкның киеме шул төбәкнең климат һәм географик үзенчәлекләренә яраклаша. Болгар һәм Алтын Урда җирләренә килгән гарәп сәяхәтчеләре мондагы «түзеп булмаслык» үтә салкын кышларны искә алганнар. Җылыныр өчен алар кат-кат оек, киез итек һәм тун кияргә мәҗбүр булганнар.

Урда халкының бер өлеше инде рәсми төстә ислам дине кабул ителгәнче үк ислам кануннары нигезендә яшәгән. Аларның киемнәре дә ислам дине таләпләренә туры килгән.

Бу чорда дәүләт башлыкларының бер-берсенә илчеләр аркылы зинәтле киемнәр бүләк итү гадәте яшәгән. Аксөякләр арасында бигрәк тә фарсы киемнәре мактала. Бу чорда төймәле озын халатлар еш очрый.



Казан ханлыгы бикәсе киеме. Реконструкция.

Тун кигән татар аксөяге. XVII гасыр төрек рәсеме.



«Хан җилкәсеннән» зиннәтле ефәк, парча чапаннар яисә кеш, сусар, кондыз, төлке һ.б. кыйммәтле мехлардан тегелгән тунга ия булу иң дәрәҗәле бүләк саналган. Кайбер хөкемдарларның олы бәйрәмнәрдә аксөякләргә һәм гади халыкларга таратыр өчен «бүләк чапаннар» тегү остаханәләре булуы билгеле. Шулай итеп, аксөякләрнең кием модасы (фасоннар, төрле төсле тукымалар кулла-



Кырым татарлары киеме.

ну) башта зур шәһәрләрдә аксөяк һәм сәүдәгәрләр арасында ныгып, соңрак ул ерак төбәкләргә, авыл халкы көнкүрешенә дә үтеп керә.

Урдада үзәк хакимият көчсезләнү белән, киемдәге җирле традицияләр йогынтысы арта бара. Алтын Урда Аксак Тимер тарафыннан җимерелгәч, сәүдә юллары үзгәреп, базарларда кытай-монгол товарларын Урта Азия тукымалары һәм киемнәре алмаштыра. XV гасырга монгол модасын җирле традицияләр тулысынча кысрыклап чыгара.

Ислам йогынтысы белән ирләрдә башларны такыр итеп кыру, сакал-мыекларны китәрү, чит-читләрен кыру гадәте ныгып урнаша. Хатын-кызлар чәчләрен, баш түбәсендә туры юл калдырып, ике толымга үргәннәр, аларны аркага салындырып йөрткәннәр. Чәч йөртү рәвешенә карап, баш киемнәренең яңа төрләрен тегә башлаганнар. Ирләр чигүле һәм түбәсе чачаклы-чуклы түбәтәйләр кигән. Чалма, чапаннар ешрак очрый башлый. Өске кием астыннан җылылык өчен күлмәкләр кигәннәр. Кайвакытта озын җилән өстеннән кыска җиңле чикмән кигәннәр.

Хатын-кызлар чәчләрен төрле япмалар белән каплый башлыйлар. Алар төрле формаларда булган («тастар», «өрпәк», «кашпау») һәм башны катлаулы итер ураганнар. Әмма татарлар арасында пәрәнҗә белән йөзне каплау булмаган. Моны Алтын Урдага һәм татар ханлыкларына килгән чит ил сәяхәтчеләре еш искә алалар. Япмалар өстеннән түгәрәк яки конус рәвешендәге бүрекләр кигәнәр. XVI гасырда аксөяк хатын-кызларның мондый баш киемнәре биек һәм очлы калпакларга әверелә. Аларны каты каркаслы итеп эшлиләр, тәңкәләр



*XVI гасыр Казан урамында. Рәссам Р.Заһидуллин.*

һәм асылташлар белән бизиләр. Алар хатын-кыз киеменең аерылгысыз өлешенә әверелә.

Хатын-кыз күлмәкләре озыная һәм төрле бала итәк, чигешләр, чачаклар, чуклар һ.б. ысуллар белән бизәлә. Хатын-кызларны төрле алкалар, йөзекләр, чулпылар, чигә алкалары, беләзекләр, яка каптырмалары һ.б. бизәнү әйберләреннән башка күз алдына китерү авыр. Ир-ат киемендә бизәнү әйберләре алай киң кулланылмаган. Әмма зиннәтле перәшкәләр белән бизәлгән билбаулар элеккечә ир-ат киеменең аерылгысыз бер өлеше булган. Гади халык биленә кун яки тукыма билбау ураган.

Алтын Урда шәһәрләрендә меңләгән бронза көзгеләр һәм аларны саклау өчен махсус тартмалар табыла. Бизәкле көзгеләр аксөяк хатын-кызлары киеменең аерылгысыз бер өлеше булган.

Кием кешенең җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге урынын, яшен, байлыгын, кайсы дин тарафдары булуын, һөнәрен һ.б. үзенчәлекләрне чагылдырган. Урта гасырларда ул кешенең үзенә күрә бер паспорты ролен уйнаган.

**Бөек ефәк юлын үз кулында тоткан Алтын Урда халкы киемендә кытай, монгол, фарсы, Урта Азия йогынтысы чагылыш тапкан. Татар ханлыклары чоры киеменә җирле халыкларның гореф-гадәтләре һәм ислам йогынтысы гаять көчле була. Ханлыклар чорында татар халкының төрле этник төркемнәренең милли киемнәренә нигез салына.**

## XIII–XVI ГАСЫРЛАРДА ТАТАР МУЗЫКАСЫ

Татарларның һун, скиф-сармат, Идел Болгары дәвереннән калган музыкаль традицияләре Алтын Урда чорында да дәвам иткән. Алтын Урда төбәкләрендә үзенчәлекле музыкаль сәнгать төрләре үсеш алган. Алтын Урда төркиләре музыкасы Алтай, Себер, Урал, Идел-Кама, Урта Азия, Дәшти Кыпчак, Кырым төбәкләрендәге җирле фин-угыр, фарсы, монгол халыклары көйләре белән мәдәни бәйләнештә үскән.

Аксөякләр, хан, морза сарайларында башкарылган көйләр, кулланылган уен кораллары, көйләү алымнары, башкару рәвешләре профессиональ дәрәҗәдә югары зәвыклы булган. Гади халык көйләре исә күп вариантлы булып, һәр төбәккә хас башкару алымнары белән аерылып торган.

Сарай музыкантлары. Фарсы миниатюрасы.



**Алтын Урда музыкасы тарихы** ике зур дәвергә бүленә. Беренчесе – исламга кадәрге һәм икенчесе – ислам дине рәсми дәүләт диненә әверелгәннән соңгы чор.

Алтын Урда дәүләте тарихының беренче дәверендә җәмгыять тормышында ырулар берләшмәсен тәшкил иткән җыеннар эчендәге тәртип төп роль уйнаган. Борынгы төркиләрнең елның төрле фасылларына багышланган келәү итү йолалары, җыеннарда борынгы җыру-дастаннар көйләп башкару, кунак сыйлаганда кара-каршы җыр әйтешү тәртипләре элеккечә дәвам иткән. Тәңрегә, җир-су, йорт ияләренә корбан китерү йолаларын имчеләр, күрәзәче-багучылар башкарган. Имчеләр, дөңгер кагып, кешеләрне, мал-туарларны имләгәннәр, яңа эшләрне махсус ырым йолалары белән башлап җибәргәннәр.

Нәкъ Алтын Урда дәверендә «Алпамыш», «Идегәй» һәм башка күптөрле эпик дастаннар формалашкан. Ул заманда думбыра, сызгычлы кылкубыз уйнап, борынгы бабаларның батырлыклары турында тарихи җырлар сузу популяр булган.

**Сарай музыкасы.** Төркиләрнең хан сарайларында монгол, кытай традицияләре йогынтысы бик көчле була. Бу дәвердә ятаган, шыдыргы дигән борынгы элитар музыка кораллары кулланылган. Татар халкының борынгы фольклор һәм кульязма үрнәкләрендә генә телгә

*Ятаган – борынгы татар күпкыллы уен коралының гомуми күренеше. Г.М.Макаров рәсеме.*





*Кылкубызда уйнаучы.*



*Жетыгендә (казахларның уен коралында) уйнаучы.*



*Шыдыргы – борынгы татар мәдәниятендә кулланылган кыллы-чиртмәле уен коралының гомуми күренеше.*

алынган бу уен кораллары хакас, тыва, алтай, монгол халыклары сәнгатендә бүгенге көндә дә саклана. Татар халкы музыкасының төп сыйфатын чагылдырган биш тавышка корылган музыка-көй нигезе (пентатоника) шушы дәвердә ныгып кала.

**Чичән һәм җыраулар.** Төрки халыкларның музыкаль-шигъри сәнгатьләренә хас эпик дастаннар башкаручы җырчыларны белдергән иң киң таралган атамаларның берсе – җырау. Төрки халыклардан казакъ, кыргыз, каракалпак, башкорт, нугай, Кырым, Себер, Идел-Урал буе татарлары, кумык, карачай, балкар мәдәниятләренең үсеш тарихында Урта гасыр дәверендәге сәнгатькә нисбәтле күп кенә танылган җырау-әйтемчеләр исемнәре һәм аларның иҗади мираслары уртак рухи казаныш тәшкил итә. Татар халык иҗаты һәйкәле «Идегәй» дастанында Субра-җырау башка каһарманнар белән чагыштырганда үзенең колоритлыгы белән аерылып тора. Бу күрәзәче картка, кодрәтле акыл

иясенә йөз туксан биш яшь. Ул Алтын Урданың утыз ханы хакимлек иткән дәверләрдә яшәгән. Үзенең кыяфәте һәм зирәклеге белән Субра-җырау мифик персонажларны хәтерләтә. Әлеге образ Алтын Урданың табигый бер өлешен тәшкил иткән татар җәмгыяте өчен гомумиләштерелгән профессиональ бер шагыйрь-әйтемче, көйче, уенчы тибын чагылдыра.

Халык җырчыларын шулай ук чичәннәр дә дип йөрткәннәр. «Чичән» һәм «җырау» атамалары вазыйфалары буенча бик якын булганнар, әмма соңга таба «җырау» сүзе киңрәк тарала. Моны аңлап та була, чөнки «җырау» атамасы конкрет рәвештә көй һәм җыр шигърияте белән бәйле. Чичәннәрнең иң атаклысы – Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә Җанибәк хан сараенда 1350 елларда яшәгән Җирән чичән. Әлеге халык җырчысы исеме татар фольклорында киң чагылган. Җирән чичән халык әкиятләрендә, сөйләкләрдә тапкыр сүзле тел остасы буларак исә алына. Төрле әйтешләрдә, бәхәсләрдә, сүз көрәштерүләрдә җиңүче булып чыгучы әлеге шәхес ханнан да курыкмый һәм, үзенең фикер бәйсезлеген, мөстәкыйльлеген саклар өчен, зиннәтле бүләкләрдән баш тарта. Җирән чичәннең шәхесе һәм иҗаты Н.Исәнбәтнең «Җирән чичән һәм Карачәч сылу» пьесасында чагылыш таба.

**Ислам чоры.** Алтын Урда тарихының икенче дәверендә төркиләр сәнгатенә караган кытай-монгол мәдәнияте йогынтысы кими бара. Бу дәвердә Алтын Урдада христианлык тәгълиматының урыны да шактый зур була, христианлык белән бәйле мәдәният, сәнгать формалары да дәүләт эчендә нығырга тырыша, әмма Алтын Урдада төрле цивилизация типлары арасындагы бәйгедә ислам юлы җиңеп чыга. Гарәп-фарсы телендә үсеш алган дин-ислам тәгълиматы, музыка сәнгате, шигърият үрнәкләре киң тарала. Бу процесс беренче чиратта Алтын Урда шәһәрләрендә, хан, морза сарайларында үсеш алган сәнгатькә карый. Сарай музыкасында клас-



*Канун һәм дәфтә уйнаучылар. Шәрык миниатюрасы.*



*Гыйжжык һәм танбурда уйнаучылар. Г.М.Макаров фотосы.*

сик шәркый уен коралларыннан танбур, гыйжжык, дәф, канун кебек уен кораллары кулланыла, сарай җырчылары тарафыннан касыйдә, газәл, робагый (әрбагый) жанрларында язылган классик әсәрләр җырлана.

Ислам тәгълиматы белән Алтын Урдада суфичылык һәм дәрвишлек хәрәкәте киң тарала. Дәрвишләрнең үзенчәлекле шигъри-музыкаль һәм инструменталь сәнгатенә, бергәләп зикер әйтүләренә, дини эчтәлекле мөнәҗәт-робагыйларга гади халык та, аксөякләр дә битараф булмый. Идел буе суфилары арасында Ясәвия тарикате (XII йөздә яшәгән Әхмәт хуҗа Ясәви исеме белән бәйле) киң танылу таба. Суфичылыкның бу тармагы Идел буенда бик күптән билгеле. Нәкышбәндия юнәлеше XIV йөздә барлыкка килә. Әлеге юнәлешне Баһаветдин Нәкышбәнди (1318–1389) башлап җибәрә.

**Хәрби музыка.** Урта гасырлардагы төрки Идел буе мәдәнияте үсешендә иң мөһим күренешләрнең берсе – хәрби-церемониаль оркестрлар куллану.



*«Мехтер» хәрби оркестры. Төркия.*

Хәрби оркестрлар дәүләткүләм тантаналы бәйрәмнәрдә, зур кунаклар каршылаганда, хан гаскәрләре сәфәргә чыкканда, хан һәм аның яраннары чыгышы вакытларында яңгыраган. Болгар һәм Казан каласының хан кирмәннәрендә төрки-татар илләренә хас булган һәм дәүләт хезмәте дәрәҗәсендәге даими хәрби оркестрлар эшләгән. Татар хәрби уен коралларының оригиналь тасвирламалары «Идегәй» дастанында бар.



*Хәрби оркестр. Шәрык миниатюрасы.*

Алтын Урда мәдәнияте варислары Урта Азия, Әстерхан, Кырым, Себер ханлыкларында классик шигърият, элитар сарай музыкасы яшәвен һәм үсешен дәвам итә.

**Ханлыклар чоры**. Алтын Урда таркалганнан соң бу дәүләттә яшәгән гади халкының этник фольклоры һәм хан-морза сарайларындагы классик музыка сәнгате Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Нугай ханлыкларында дәвам итә. Төрки-татарларның уртак музыкаль мираслары яңа тарихи шартларда яңа үзгәрешләр кичерә.

Казан ханлыгында музыкаль тормыш бигрәк тә Мөхәммәд Әмин заманында актив була. Хан сараенда җырчылыр, уенчылар шактый күп була. Хәтта Шәрык дөньясында шөһрәт казанган күренекле музыка белгечләре Хан саренда яшәп иҗат итә. Мәсәлән, Урта гасырларда Заһретдин Мөхәммәд Бабур (1583–1530) тарафыннан иҗат ителгән «Бабурнамә» әсәрендә остазлар Дәрвиш Шадый Хабәши һәм аның улы Гөләм Шадый Хабәши искә алына. Дәрвиш Шадый Хабәшинең иҗаты Һират шәһәрендәге солтан Хөсәен Байкара сараенда җырчы буларак башланып китә. Сарайда аның иҗатын бөек шагыйрь Алишер Нәвои югары бәяли. 1502–1503 еллар тирәсендә Дәрвиш Шадыйны язмыш Казан ханы сараена алып килә. Казанга, хан кирмәнендә урнашкан Мөхәммәд Әмин сараена күчеп килгәннән соң, Остаз Шадый башка уенчылар белән классик уен коралларында



*Кырым татарлары бәйрәмдә.*



*Чәң.*

мәшһүр шагыйрьләр сүзләренә иҗат ителгән нәкыш һәм сәвет жанрларындагы әсәрләрне көйләп укый.

Дәрвиш Шадыйның Мөхәммәд Әмин хозурындагы беренче чыгышы гыйбрәтле була. Ул Һират һәм Бохарада киң танылган әсәрләрне башкара. Хан сараенда танбур, гыйжжык, дәф, нәй һ.б. классик кораллар кулланыла. Хан уенчыларны кыйммәтле бүләкләр белән бүләкли.

Урта гасыр татар мәдәнияте тарихында үсеш алган элитар музыка сәнгате Казан ханлыгы дәверендә чәчәк ата, аны классик чор дип атап була.

## ТАТАР ТАРИХЫНДА ХАТЫН-КЫЗЛАР (XIII–XVI ГАСЫРЛАР)

**Алтын Урда чорында хатын-кызлар.** Кешелек дөньясының барлыкка килүендә һәм үсешендә хатын-кыз – гүзәл зат – һәрвакыт аерым бер урын алып тора. Бу аңлашыла да. Чөнки кеше Ана карынында ярала, Ана аны дөньяга тудыра, үстерә, тәрбияли. Шуңа күрә дә татар халкының борынгы заман тарихына күз салсак, аның нигезендә хатын-кызга, бигрәк тә аналарга тирән хөрмәт ята. Гаиләдә



*Хан һәм ханбикә тәхеттә. Шәрык миниатюрасы.*

Ана – изге зат, аның сүзе – күп вакыт соңгы сүз, төп нәтиҗә. Ананы рәнҗетүдән, хәтерен калдырудан балалар бик нык сакланганнар; эш башлаганда, юлга чыкканда һәркем ата-анасының хәер-фатихасын алырга тырышкан.

Башка халыклар мәдәниятен өйрәнгәндә дә, аналар культының тамыры бик тирәндә икәнлегенә төшенәсең. Йөз мең елларга сузылган матриархат, ягъни аналар хакимлеген ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Белгәнебезчә, борынгы төркиләрдә дә хатын-кызлар гаиләдә дә, дәүләттә дә гаять әһәмиятле роль уйнаганнар, ирләре белән бертигез хуҗалык алып барганнар, хәтта сугышларда катнашып, батырлык үрнәкләре күрсәткәннәр. Күптән түгел археологлар беләзекләр һәм алкалар белән бизәндерелгән һәм тулысынча коралландырылган (хәнҗәр һәм ярты метр сөңге), ат дирбияләре белән күмелгән Алтын Урда бикәсе каберен тапканнар.



*Бозок шәһәрендә табылган Алтын Урда хатын-кызы баш сөяге буенча реконструкция.*

Алтын Урда дәүләтендә хакимият төзелешендә хан гаиләсенең төп әгъзалары: хатыннары, угланнары һәм солтаннар (уллары һәм кызлары) мөһим роль уйнаганнар. Кайбер ханбикәләрнең, ирләре мәрхүм булганнан соң, илбашы булып утырулары, шулай ук патша, патша хатыны вазыйфала-

рыннан файдаланып, ташлама һәм хокук ярлыклары бирүләре, чит ил патшалары белән дипломатик сөйләшүләр алып барулары билгеле. Алтын Урда менә шундый тарихи традицияләр дәвамчысы ул.

**Ханбикәләр.** Мәгълүм булганча, хатын-кызларның хокук һәм мөмкинлек дәрәҗәләре, беренчедән, аларның шәхси сыйфатлары белән билгеләнсә, икенчедән, сәяси хәл торышына да бәйле булган. Алтын Урдада асыл затларны махсус «хатын» (катун) сүзе белән олылаганнар. Бу борынгы төрки атама «ханым», «бикә» яки «патшабикә» (хан хатыны) дигәнне аңлаткан. «Ханым», «ханбикә», хәтта «бикәм» сүзләре соңрак татар ханлыкларында аеруча күп кулланылган. Җучи Олысының кайбер өлкәләрендә «алтын ханым» дигән мөрәҗәгать тә булган.

Ханның хатыны дәүләттә аеруча әһәмиятле урын алып торган. Мәсәлән, Алтын Урда ханы Үзбәкнең хатыны Тайдула үзенең чибәрлеге өстенә искиткеч акыллы да булуы белән танылган. Ул, Европа патшабикәләре кебек үк, ире белән янәшә утырган, илчеләрне кабул иткән. Аның рус руханиларына, Италия сәүдәгәрләренә бирелгән ярлыклары сакланган. Улы Җанибәк, оныгы Бирдебәк ханлык иткән чорларда да ул дәүләт идарәсендә, сәясәтендә актив катнашкан. Мәсәлән, аның Урда сәүдәгәрләрен талап, аларны әсирлеккә алган венециялеләрне хөкем итүе, казыя ролен башкаруы билгеле.

Ханбикәләр мәҗлес әңгәмәләрендә дә катнашканнар һәм аларның фикерләре бик мөһим, ә кайбер мәсьәләләрдә хәлиткеч булган. Хан нәселенең ир-атлары кебек үк, хатын-кызлар да үз



*Туктамыш хан кызы Җаникә ханым төрбәсе. Кырым.*



*Җаникә ханым. Рәссам Ю.Никитин.*

биләмәсенә ия булганнар һәм анда мөстәкыйль идарә иткәннәр. Мәсәлән, Тайдулага биләмә итеп Тула шәһәре бирелгән була.

Алтын Урда тарихында ханбикә исеме белән сугылган акчалар да билгеле. Тәңкәләрдә Туктамыш хан хатыны Толунбәк ханым исеме бар, аны «камил хакимә» дип тәрҗемә итеп була.

Дәүләттәге мөһим эшләрне хәл итү өчен җыелган корылтайда аксөяк нәселләреннән булган ирләр генә түгел, хатын-кызлар да катнашканнар.

Алтын Урдада хатын-кызларга булган олы ихтирам хакында бу дәүләттә булган чит ил сәяхәтчеләре таң калып сөйли. Гарәп сәяхәтчеләрен татар хатыннарының йөзләрен капламыйча горур йөрүе аеруча гаҗәпләндергән. Бу күренеш хан һәм аксөяк хатыннарында гына түгел, гади халык арасында да күзәтелгән.

Хатын-кызларга ихтирам татар әдәбиятында да бай чагыла. Бу чорда иҗат ителеп, гүзәл затларга дан җырлаган дастаннар, эпослар безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмасында да хатын-кызга олы ихтирам чагыла. Котб чордашы Харәзминең «Мәхәббәтнамә» әсәрендә дә хатын-кызга мәхәббәт иң олы, изге хис итеп күрсәтелә.

Ни кызганыч, Алтын Урда чорында яшәгән, аның иҗтимагыйсәяси тормышында зур роль уйнаган ханымнар, ханбикәләр хакында чыганыклар бик аз сакланган. Кайберләренең без бары тик исемнәрен генә беләбез. Мәсәлән, 1297 елда Кабан күле буенда күмелгән Алтын Бөртеккә куелган кабер ташы сакланган.

**Казан ханлыгы чоры ханбикәләре.** Җучи Олысы таркалса да, аның тарихи язмышы тукталмый. Яңа оешкан Казан, Себер, Кырым һ.б. ханлыкларда бай мәдәният үзәкләре, күркәм традицияләр саклана.

Әлеге чор безгә вакыт ягыннан да якынрак тора, язма чыганакларда да киңрәк яктыртыла. Бу – рус дәүләте белән ике арада барган сәяси элемтәләрнең бик тыгыз, бик актив чоры, ифрат та катлаулы, фаҗигале һәм гыйбрәтле заманы.

Бу чорда зирәк дәүләт башлыклары, зур сәяси эшлеклеләр, дипломатлар булган кайбер каһарман кызларга аерым тукталып үтик.

**Нурсолтан (1451–1519)**. Казан, соңрак Кырым ханбикәсе булган Нурсолтан ханнарның иң якын киңәшчесе, дәүләт эшләрендә ярдәмчесе була. Ул ярты гасырдан артык Мәскәү, Кырым һәм Казан арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрнең үзәгендә торган, Мәскәү һәм Казанга илчелекләр җитәкләп, дипломат вазыйфасын үтәгән, илләр арасында тынычлык урнаштырырга тырышкан. Иван III һәм Василий III белән хатлар алышкан. 1487 елда Иван III Казанны ала. Шәһәрне алса да, ханлык бетерелми, аның мөстәкыйльлеген саклау-



*Нурсолтан.*
*Рәссам Н.Хаҗиәхмәтов.*

да Нурсолтан зур көч куя. Аның Мәккәгә хаҗ кылган вакытында Мисыр хөкемдары белән очрашуы да мәгълүм.

Соңрак аның кызы Гәүһәршад (1481–1546) да Казан ханлыгында сәяси эшләр алып бара. Яшь Җангали идарәсе вакытында (1532–1535) ил белән Гәүһәршад һәм карачы би Булат Ширин җитәкчелегендәге хөкүмәт идарә итә. Җангали балигълык яшенә җитеп, 16 яшенә кадәр нугай далаларында яшәгән гүзәл Сөембикәгә өйләнгәч, Гәүһәршадның регентлыгы тәмамлана. Әмма ул әле тагын 12 ел буена дәүләт эшләренә үз йогынтысын югалтмый.

**Сөембикә ханбикә.** Сөембикә – халкыбыз күңеленә, хәтеренә уелып калган изге бер исем. Ул татар халкының гүзәл манарасында гәүдәләнгән олуг бер маягы гына түгел, безнең милли аңыбыз, аңлы бер халәтебез сагында торган якты бер нур да, гомерлек сагышыбыз да кебек.

Сөембикә Казанга килгәнче үк фарсы, гарәп, рус телләрендә камил сөйләшкән һәм, атасы Йосыф морзаның яраткан кызы буларак, гаилә табыннарында ил-халыклар арасында барган сәяси бәхәсләрдә катнашкан.

Сөембикә – татар халкының соңгы ханбикәсе. Казан шәһәренә ул 30 меңгә якын гаскәри белән килә. Ил картлары аларны Арча төбәгенә урнаштыралар. Җангали фетнә нәтиҗәсендә үтерелгәч, Сөембикәне тәхеткә утырган Сафагәрәйгә димлиләр. Аларның Үтәмеш исемле уллары туа.

1549 елда Сафагәрәй үлгәч, Казан бәкләре, аксакаллары һәм имамнары дүртенче яшенә аяк баскан Үтәмешгәрәйне Казан ханы итеп тәхеткә күтәрәләр. Улы исеменнән ил белән Сөембикә ханбикә идарә итә. Нәкъ шушы чорда Сөембикә Казан каласының кирмән-кальгаларын ныгыта һәм ире Сафагәрәйнең кабере өстенә төрбә салдыра, Европа һәм Шәрык илләреннән китаплар кайтартып, бай китапханә туплый. Бу чорда Казан чәчәк ата. Илдә тынычлык, муллык, иминлек урнаша, Казан сәүдәгәрләре дөнья халыклары белән гөрләтеп сәүдә итәләр.



*Сөембикә илчеләр кабул итә. Рәссам И.Фәйзуллин.*

Казанның шулай көчәеп китүе Мәскәү патшасы Явыз Иванга тынгылык бирми. Ул Казанга биш тапкыр яу белән килә, биш тапкыр кан коеп кайта.

Сөембикә халкын, каласын саклап калу өчен барысын да эшли. Явыз Иванга шартнамә – солых төзү өчен илчеләр җибәрә. 1551 елда Иван Казан түрәләренә шарт куя: «Тыныч яшик дисәгез, ханбикәне һәм аның угылын Мәскәүгә озатыгыз».

Каһарман ханбикә тагын бер сәяси адым ясый. Улы белән Казаннан китәргә ризалык бирә. Чорына күрә искиткеч зур батырлык бу. Иле-халкы һәм башкаласы исән-имин яшәсен өчен, улын һәм үз-үзен корбан итә.

Сөембикәне һәм сабый Үтәмешне алырга кенәз Серебряный килә. Сөембикәне озатырга урамнарны тутырып халык агылганын күреп, ул ханбикәгә ире Сафагәрәй каберенә туктарга, мәрхүм белән саубуллашырга рөхсәт бирә. Сөембикә ире каберенә капланып елый, аның белән саубуллаша. Аннары баскынчылар ханбикәнең бөтен байлыгын һәм китапханәсен талыйлар һәм корабка төяп алып китәләр. Мәскәүгә килгәч, Үтәмеш чукындырыла, аңа Александр исеме бирелә. Ул 1556 елда Мәскәүдә үлә һәм Кремльнең Архангельский соборында рус патшалары арасында күмелә.

Сөембикәне Иванның ышанычлы яраны Шаһгалигә көчләп кияүгә бирәләр. Яраткан газиз баласыннан аерылып, җаны сөймәгән бер адәмгә насыйп булган Сөембикәнең соңгы көннәре Касыйм шәһәрендә уза.

**Сүзге – Себер ханбикәсе.** Татар тарихында онытылмаслык эз калдырган гүзәл шәхесләрнең тагын берсе – Себер ханы Кучемнең сөекле хатыны, иле, халкы өчен җанын фида кылган Сүзге. Ермак яулары заманындагы канкойгыч вакыйгалар белән бәйле легендар Сүзге образы күпләргә мәгълүм.

1581 елның 1 октябрендә атаман Ермак һәм Кучем хан гаскәрләре арасында канлы сугыш башлана. Кучем хан исән калган гаскәре белән чигенергә мәҗбүр була. Дошман Сүзгенең ныгытылган сараен өч атна буе камалышта тота. Сарай сакчылары казакларга каршы җаннарын аямыйча көрәшәләр. Аларны буйсындыру өчен өстәмә көчләр кирәк була. Әмма Сүзгенең дә хәле авырая. Тигезсез көрәшнең ни белән бетәчәген аңлап, ул казак атаманы Гроза белән сөйләшүләр башлый. Баласының, халкының гомерен саклап калыр өчен, Сүзге өч шарт куя: исән калган татарларга ныгытмадан чыгып китәргә мөмкинлек бирергә; аларны елганы кичеп чыгу өчен көймәләр белән тәэмин итәргә; татарларны башка рәнҗетмәскә, кысрыкламаска.

Ханбикә илчесен тыңлагач, атаман Сүзге куйган таләпләргә ризалыгын белдерә, әмма Сүзгенең үзенә тотык булу таләбен куя. Илче кайтып бу таләпне җиткергәч, Сүзге, әсирлектән башка мөмкинлек калмаганын аңлап, хезмәтчеләренә сарайдагы барлык әйберләрне, казнадагы бөтен акчаны бүлеп бирергә боерык бирә. Үзе иң затлы киемнәрен кия, Кучемнең бүләге – энҗе муенсасын тага.

Таң белән Иртеш суы буена зур көймә килеп туктый. Халык, күз яшьләрен тыя алмыйча, ханбикә белән саубуллаша һәм көймәгә төялә. Тиздән көймә күздән югала. Чал Иртеш ярында басып калган Сүзге очлы хәнҗәрен гайрәт белән күкрәгенә кадый, йөрәгенә кадәр батыра. Казаклар татар ханбикәсенең милли горурлыгына, каһарманлыгына таң калалар. Батырлыкка хөрмәт йөзеннән Сүзге ханбикәне мөселман гадәтләрен саклап җирлиләр.



*Кучем хан яраткан хатыны Сүзге белән. Рәссам М.Знаменский.*

Аның гүзәллеге, уңганлыгы, батырлыгы хакында хәзер дә төрле риваятьләр сөйләнә, җырлар җырлана, сәхнә әсәрләре языла. «Конек-горбунок»

авторы Петр Ершов аның турында «Сүзге – Себер легендасы» дигән әсәр яза.

Алтын Урда һәм ханлыклар тарихында тирән эз калдырган мәшһүр хатын-кызларның якты истәлеге күп кенә әдәбият-сәнгать әсәрләрендә чагылыш таба.

## Сөембикә бәете

Мең биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен,
Ата-ана дәүләтен китмәс диеп белгәнмен.
Ата-ана кулында бер кайгы да күрмәдем,
Бу кайгылар күрермен дип, исәпләп тә йөрмәдем.
Сөембикә атым, нугай затым,
Кайда минем яшь дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем,
Морза кызы булган вакытым.
Унсигез яшьләрем тулган чакларымда
Хан хатыны булдым мин ата-ана хакларында.
Кырымнан Казанга китерде тәкъдирем,
Казанның яшь ханы Җангали булды ирем.
Җангали хан мәгъкуль бер залим кулыннан,
Бәндәгә казалар очрыйдыр юлыннан.
Ханбикә булгачдин ике ел торгачдин,
Тол калдым кайгылы, хан дөнья куйгачдин.
Кырымлы Сафагәрәй Казанга хан булды,
Өч хатыны булса да, дүртенчегә мине алды.
Дөньялар хафалы, замана буталды,
Казанга күрше падишаһлар күз салды.
Сафагәрәй вакытында бик күп булды сугышлар,
Һәркайдан яу килгәчдин авыр булды сулышлар.
Гомерем үтте ундүрт ел Сафагәрәй хан белән,
Казан шәһәре күңелсез юлда түккән кан белән.
Шәһәр тышында сугыш, эчендә афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат
Ике яшьлек угылым, күзем нуры, колыным,
Үтәмешгәрәем калды ятим, былбылым.
Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,
Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүзенә.
Мәскәү ханы үгетли картны, яшьне, егетне,
«Бирелегез миңа, – ди, – тотармын җәбер итми».
Морзалар сүз аңламый, көчләре аз сугышка,

Ничә кабат сүз бозып, барды алар солыхка.
Солых шартын тагын да бу морзалар боздылар,
Нугай, Кырым, казанлылар төрле җиргә туздылар.
Хан урынына хан булып торалмадым пан булып,
Гаҗизләндем морзаларга, йөрәгем, бәгърем кан булып.
Хан кабере өстенә кордырдым таш манара,
Дидем: «Үзем үлсәм, исемем күп елга бара».
Манараны коргачтын көнләштеләр хәлемә,
Казандагы кенәзләр үзе тыныч булырга,
Һәр каюсы кул куйганнар мине әсир кылырга.
Әмер булды китәргә, көймәләргә җитәргә,
Күзләремдин нур китте, белмим нихәл итәргә.
Мине тотып ике адәм утырттылар арбага,
Тәхет, бәхет калдырып көймә янына бармага.
Күзем салдым халыкка, күбе җылап озата,
Кайсылары «Мәскәү ханы рәхимле», дип озата.
Иделләргә чыкканда карадым мин калага,
Калды җылап Казаным, охшап үксез балага.
Дидем: «Мескен Казаным, төште таҗың башыңнан,
Калдың бүген дәүләтсез, чишмә агар яшеңнән.
Кайда калды шатлыгың, кайда синең байлыгың?
Күрер күзгә билгеле хәзер кол, гидайлыгың.
Бушап калды сараең, нурың китте үзеңдин», –
Дип җылап Казанны югалттым мин күземдин.
Күп заманнар баргачдин, Мәскәүгә барып җиттек.
Бу бәхетсез башларга ни була дип, без көттек.
Барып кердек зур йортка, эчендә аның хансарай,
Күп кешеләр җыелган, барысы да безне карый.
Ишеттем мин баламны поплар алганнар диеп,
Гакылы да юк сабыйны диннән чыгарганнар дип.
Мин киткәчтен көндәшем, китте инде, дип, Сөембикә,
Үзенә ир кайгыртып, булмак булган ханбикә.
Халык белән киңәшеп, Астарханнан хан алган,
Яшь кенә кенәз икән, исеме Ядегәр хан булган.
Көндәшем ханга барган, Казанны һәм тотам дип,
Дөнья әйткән: «Ашыкма әле, сәни дә утка атам», – дип.
Шул елны мине дә падишаһ бирде бер ханга,
Касыймдагы Шаехгали, Казанга дошман җанга.
Мине алгач, сугышка әмер булды барырга,
Мәскәүлеләр белән бергә Казанны һәм алырга.
Шаехгалиләр барганнар, Казанны һәм алганнар,
Мине саткан морзаларның башын җиргә салганнар.

Ядегәр белән көндәшем тагы да кулга төшкән,
Мине яндырган утта үзе дә яхшы пешкән.
Гарип балам Үтәмеш тә алты яшенә җитте,
Фани дөньядан үтте, андин бер кайгым бетте.
Сөембикә атым, нугай затым, күзем яшьле, юк рәхәтем,
Күрдем михнәт, чиктем газап, онытылмый һич хәсрәтем.

## Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәяте

Яңа Үзи авылы янындагы кырда, урман эчендә Хуҗалар тавы дигән тау бар. Шул тауда борынгы заманнарда Мәрҗән исемле болгар шәһәре булган. Мәрҗән шәһәрендә Тырышмал Хуҗа хөкем сөргән. Хуҗаның унике кызы булган. Аталары аларны Буләр шәһәренә Рабига остабикә мәдрәсәсенә укырга җибәргән. Бу мәдрәсә Буләрдәге Хуҗалар тавы итәгендәге бик зур чишмә янына урнашкан була. Рабига көн саен Шәһре Болгардан Буләргә җир асты юлы аша 66 шәкертен укытырга килеп йөргән.

Бервакыт Болгар илен яу баскан. Ул Буләр шәһәрен дә камап алган. Башка батырлар белән бергә Иштирәк батыр да, сугыша-сугыша, Хуҗалар тавына менгән, туган илләре өчен соңгы тамчы каннарына кадәр сугышырга ант эчкәннәр. Әмма тигезсез сугышта һәлак булганнар. Аларны тау башында җирләгәннәр. Унике кыз, мәдрәсәдә алган гыйлемнәре белән, үзләрен куа килүче дошманнарга каршы ау корганнар. Әмма Мәрҗән шәһәренә җиткәч, дошман кызларны тотып алып, Хуҗалар тавы янына китергәннәр. Аларны яланаяк килеш көне-төне туфрак ташып, яңа бер тау өйдергәннәр. Тау өелеп беткәч, дошманнар кызларны тереләй килеш шул тау башында күмәргә теләгән. Шулчак кызлар унике йолыз булып күккә күтәрелгәннәр, аталары, таудан сикереп, елга суына әйләнеп, агып киткән. Халык, шул елга башланган чишмәне изге санап, аңа табынган, ә кызлар өйгән тауны «Кыз тавы» дип атаганнар.

# ЭЧТӘЛЕК


Кереш ........ 3
Азия һәм Европада һуннар (гуннар) ........ 4
*Ашын нәселенең килеп чыгышы (миф)* ........ 6
Төрки каганлык ........ 6
Бөек Болгар иле ........ 9
Хәзәр каганлыгы ........ 10
Тәңречелек – борынгы төрки бабаларыбыз дине ........ 13
*Җир ничек яралган (легенда)* ........ 17
Төрки-татарларда гаилә ........ 18
*Йосыф Баласагунлы «Котадгу белек» (Бәхеткә илтүче белем). XI гасыр* ........ 23
*Сак-сок бәете (өзекләр)* ........ 23
Төрки-татарларда ашамлыклар ........ 24
Болгар дәүләтенең барлыкка килүе ........ 28
*Болгар каласының корылуы турында риваять* ........ 31
*Айдархан һәм сәхабәләр (риваять)* ........ 33
Болгар дәүләтенең хуҗалыгы ........ 35
Бай шәһәрләр патшалыгы ........ 38
*Шәһәр нигә Казан дип аталган? (риваять)* ........ 40
*Казан кайнаган урын (риваять)* ........ 40
*Минем шәһәрем этләргә эләгер (риваять)* ........ 41
Болгар дәүләтенең башка халыклар һәм илләр белән бәйләнеше ........ 42
*Белемле кеше (риваять)* ........ 45
Идел-Чулман Болгары халкының мәдәнияте ........ 46
*Кол Гали (XII гасыр ахыры – XIII гасыр). Кыйссаи Йосыф* ........ 49
*Туйбикә мәдрәсәсе (риваять)* ........ 49
Торак һәм көнкүреш ........ 50
Архитектура ........ 56
Милли кием тарихы ........ 63
Борынгы монголлар һәм татарлар. Монголларның Идел-Чулман Болгарын яулап алуы. Җучи Олысы төзелү ........ 68

Алтын Урда чәчәк ату чорында .......... 74
Алтын Урдада мәдәният, мәгариф һәм фән үсеше .......... 81
*Котб (XIII – XIV гасырның уртасы).*
*Хосрәү вә Ширин (1342)* .......... 86
Алтын Урдада тормыш-көнкүреш һәм архитектура үсеше .......... 87
Алтын Урдада ислам һәм дини вәзгыять .......... 97
Урта гасырларда татарлар һәм Евразия
халыклары арасындагы мәдәни багланышлар .......... 101
*«Кодекс Куманикус» (XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башы)* .......... 112
Алтын Урданың таркалуы һәм татар ханлыклары оешу .......... 113
*Кунак бабай риваяте* .......... 117
*«Кунак бабай җыруы»* .......... 117
*Янмый торган кыз (легенда)* .......... 118
Казан ханлыгы – Урта Иделдә яңа дәүләт .......... 119
Казан ханлыгы мәдәнияте һәм мәгарифе .......... 125
*Кол Шәриф (XVI гасыр башы – 2.10.1552) иҗатыннан* .......... 131
Казан ханлыгы: мөстәкыйльлектән һәлакәткә таба .......... 132
*Патша хәйләсе (риваять)* .......... 139
Олуг Урда, Әстерхан ханлыгы, Нугай Урдасы .......... 139
Кырым ханлыгы .......... 146
*Юмарт хан һәм Мостафа Мөҗәб (әкият)* .......... 154
Себер ханлыгы .......... 155
*Әхмәтгәрәй хан (риваять)* .......... 164
*Күчем һәм Ермак турында риваять (Төмән өлкәсе*
*Вагай районы татарларыннан язып алынган)* .......... 165
Татар ханлыклары архитектурасы .......... 166
Татар милли киеме тарихы (XIII–XVI гасырлар) .......... 170
XIII–XVI гасырларда татар музыкасы .......... 178
Татар тарихында хатын-кызлар (XIII–XVI гасырлар) .......... 184
*Сөембикә бәете* .......... 191
*Мәрҗән каласы һәм унике кыз хикәяте* .......... 193

**Татар халкы тарихы һәм мәдәнияте:**
**урта гасырлар**
**(фәнни-популяр басма)**

Төзүчеләре: Гибатдинов М.М., Мортазина Л.Р.

Компьютерга салучы: Җиһангәрәева Л.М.

Басмага кул куелды: 29.08.2013
Кәгазь форматы $60 \times 84\ ^{1}/_{16}$
Офсет басма. Шартлы басма табагы 12,25
Тиражы 500 данә

Басылды

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
www.tataroved.ru